ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

№ 11 (346)
НОЯБРЬ 2020

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ISSN 0130-2418

БРАЙТОН-БИЧНЫҢ АЯЗ КӨННӘРЕ

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Олеся Бондаревская, Ольга Туманская, Руфия Фазылова
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Илдус Заһидуллин, Ксения Сёмина,
Фаяз Хуҗин
Фотографлар: Александр Ефремов, Лилиана Вәлитова
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыкта: Америкада яшәүче ватандашыбыз
Наилә Бикчәнтәева. Захар Левентул фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә
күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
1 880 данә

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан»
журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела.
Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү
мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры
килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге
өчен редакция җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә
басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № А-3015
Басарга кул куелды: 18.11.2020
Басмадан чыкты: 23.11.2020

БӨЕК
ҺӘМ КОТОЧКЫЧНЫҢ
ИКЕНЧЕ ЯГЫ

Дөньяда нидер бара, сизәсезме? Юк, әлеге дә баягы ковид турында әйтүебез түгел, ә бәлки, аннан да зуррак, ихтимал, шул бөек һәм коточкыч авыру аркасында барлыкка килгән һәм безне игелеклерәк, ярдәмчелрәк булырга этәргән нәрсә турында.

Бәлки, ул бу авыруны йоктырып терелгәннәрдән башлангандыр. Һәм менә икенче дулкынга эләгүчеләрнең ишек катында, дарулар һәм азык-төлектән тыш, чәчәкләр һәм башка шундый күңел күтәрә торган әйберләр пәйда була башлады – бүләкләр «беренчеләрдән» һәм авыруны яңа гына үткәреп җибәргәннәрдән. Авыру вакытында кешене гаҗизлек, курку хисе биләп ала, «беренчеләр» моны хәтерле әле, «икенчеләр» – белә.

Без бер-беребезгә игътибарлырак була башладык – хәйриячелектә теләп катнашабыз, чит кеше баласына да, бакчачылык ширкәтенең бер башында йорты янган бөтенләй таныш булмаган кешегә дә, ялгыз яшәүче әби-бабайларга да, йортсыз-җирсез калган кешеләргә дә, гомумән ярдәмгә мохтаҗларга булышабыз... Мондый хәлләр бик еш очрый хәзер, бу турыда матбугатта да языла, кешеләр дә сөйли. Берәү дә санап бармый аларны. Санау кирәкмидер дә. Исәп өчен эшләмибез бит, бары тик игелеклерәк кенә була башладык. Бәлки, ул җиргә шуның өчен җибәрелгәндер дә?

Авырудан читтә кала алмаган редакциягез.

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com

Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая, alsu_1970@list.ru
тел.: (843) 222-09-79

Коммерция директоры:
Юлия Фәсәхова, 89272483384_pr@mail.ru
тел.: (843) 222-09-76, +7-9272-483-384

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә
2350 данә тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4230 данә
Реклама 16+

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рафкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла
Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә
Ярты елга язылу бәясе: **942 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

100 яшь «ТАТАРСТАН» журналына

#татарстанның 100 җәүһәре

#бары тик татарстанда

МИЛЛИОНЛЫК СӘНГАТЬ

Питтсбургның Карнеги институтында уза торган халыкара күргәзмәдә Клод Монэ һәм Ренуар эшләре тора, әмма матбугатның игътибарын Надежда Сапожникова портреты җәлеп итә. Картинаның авторы – Казан рәссамы Николай Фешин шул вакытта халыкара танылу ала. Бер гасырдан соң, Фешин «иң кыйммәтле» модернист буларак танылa – 2010 елда MacDougall`s аукционында аның «Бәләкәй ковбой» картинасы якынча 11 млн долларга сатып җибәрелә!

Фешин Казанның сәнгать мәктәбендә укыткан һәм, иң яхшы елларым туган ягымда узды дип, еш әйтә торган булган. Инкыйлабтан соң, ул АКШта яшәгән, уңышка ирешкән, танылу алган, әмма үзен туган шәһәре – Казанда җирләргә васыять иткән.

WWW.PROTATARSTAN.RU

© «Татарстан» журналы

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

4. Бөтендөнья татар теле марафоны
Безгә кайсы кыйтгалардан сәламнәр килде

6. Телне берничә сәгатьтә өйрәнү... Бу мөмкинме?
Лингвист-полиглот Дмитрий Петров киңәшләре

10. Телләр өйрәнү
Нинди методикалар чит телне дә үзеңнеке итәргә сәләтле

14. Татар мәктәпләре
БДИны кайсы мәктәптә 100 баллга бирәләр

20. Казансу ярлары
Шәһәрлеләр өчен ярларны ничек ачарга һәм табигатьне саклап калырга

30. COVID-19 авыруыннан вакцина. Безнең версия
Коронавирус белән очрашудан нәрсә коткарыр

игелекле эшләр

42. Коткар Россияне, Америка!
Чит ил ярдәме бабаларыбызны ничек ачлыктан алып калган

46. Руфина Фәттахованың тормыш линиясе
Хөрмәт ничек мәхәббәткә әйләнә

49. Аналар көненә багышлап
Салавычның кендек әбисе

52. Буа – талантларга бай төбәк
Дөньядагы иң шәп урынны кайда таптык

мәңгелек кыйммәтләр

66. Татарларның яңарыш идеологы
Исмәгыйль Гаспралы язмышы

70. Яхшы һәм яман көчләр
Кайсы музейда геройлар һәм явызлар турында сөйләнә

82. Татар авыллары
Акбүре авылы нинди тарихка ия

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: protatarstan.ru

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

27.10

Айрат ФӘРРАХОВ, Татарстаннан РФ Дәүләт Думасы депутаты:

– Бу көннәрдә без федераль бюджет турындагы закон проектын карауны тәгәллибез. Әлбәттә, ел чиктән тыш аңлаешсыз һәм катлаулы. Гомумән алганда, бу – чикләүләргә дучар ителгән бюджет, һәм ул һич кенә дә без аны бер ел элек формалаштырганда төзегән пландагы чыгымнар һәм керемнәр түгел. Икенче яктан караганда, дәүләтнең барлык социаль бурычларын, шулай ук стратегик максатларны һәм милли проектларны тулысынча тормышка ашыруны да күздә тота.

19.10

Владимир БУРМАТОВ, РФ Дәүләт Думасының Экология һәм әйләнә-тирә мохитне саклау комитеты башлыгы:

– Хәзер проблема калдыкларны эшкәртү өчен башка төбәккә илтү белән бәйле. Күз алдына гына китерегез, Татарстанда аерым җыелган пластикны Минеральные Водыга илтәләр. Бу, әлбәттә инде, отышсыз ысул. Аларны эшкәртү заводы янәшәдә булырга тиеш. Ә ни өчен ул анда юк? Чөнки кемдер аны анда төземәгән.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

24.10

Константин КОЛПАКОВ, Россия МИДының Яшь дипломатлар советы рәисе, – Казанда БРИКС илләре яшь дипломатларының V форумында:

– Казан РФнең Европа өлешендә һәм нәкъ үзәктә урнашкан, ул халыкара үзара ярдәмләшүнең зур тәҗрибәсенә ия. Республика үзе төрле милләтләр, диннәр һәм мәдәниятләрнең үзара ярашып яшәвенә яхшы мисал булып тора. Бу бик күркәм. Мин үзем Казанда тудым һәм кече ватанымны бик яратам. Россия – зур ил, без төрле, әмма безне һәрвакыт әйдәп баручы дөнья позицияләренә чыгаручы синергияне бергә генә бирә алабыз.

акыллы гамәлләр

Акыллы гамәлләр

Мәңгелек кыйммәтләр

Игелекле эшләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Безгә кайсы кыйтгалардан сәламнәр килде

Татар телен ничек «тәмләп» өйрәнергә

Җыр ничек тел өйрәнергә булыша

БДИны кайсы мәктәптә 100 баллга бирәләр

Ковидны ничек йоктырмаска була

ҺӘР КЫЙТГАДАН КИЛӘ ТАТАР СӘЛАМЕ

Фото: «Татарстан» журналы инстаграмы

Киләсе елның Татарстанда Туган телләр һәм халык бердәмлеге елы дип игълан ителүе турындагы хәбәрне «Татарстан» бик дәртләнеп кабул итте һәм социаль челтәрләрдәге сәхифәләрендә «Татарстан» журналы белән бергә Бөтендөнья татар теле марафоны игълан итте. Проектның идеясе – дөньяда таралып яшәгән татарларны берләштерү һәм туган телне популярлаштыру.

Марафонга башка тел вәкилләре дә кушылды, алар журналда телләрне җиңел һәм күңелле итеп өйрәнүнең ысул-алымнарын уртаклашты. Проектның нәтиҗәсе турында журналда укыгыз. Сүз уңаеннан, инстаграмдагы protatarstan аккаунты аудиториясе бу теманы аеруча актив күтәреп алды.

БЕЛЬГИЯДӘН «ТУГАН ТЕЛ»

Бүген Татарстан белән элемтәдә – Бельгия татарлары. «Туган тел» җыры һәм ватандашларга теләкләр белән Бөтендөнья марафонын башлыйбыз.

Роза апа Абазова – Бельгия татар җәмгыятенең рухи лидеры. Ул Татарстанның Сарман районыннан, быел җәй инде 83 яшь тулса да, туган ягына еш кайтып йөри. Аның 8 оныгы һәм 12 оныкчыгы бар.

Роза апаның бар гомере әдәбият белән бәйле: ул Кабардино-Балкариядәге бер фәнни институтның зур китапханәсендә күзәтүче булып эшли, Нальчиктагы җәмәгать китапханәсе мөдире була. Өстәвенә, нәкъ менә Нальчикта ул татар төркеме оештыру эшен дә башлап йөри, күп еллар җәмгыятьнең лидеры һәм рухи нигезе булып тора.

Туган телне һәм мәдәниятне тарихи ватаннан читтә дә саклап калу эшендә Роза апаның тәҗрибәсе бик бай, ул хәзер дә милли мәсьәләләрне хәл итүдә булышырга атлыгып тора.

15 елдан артык Бельгиядә яши, биредә аның 2 кызы бар. Бер улы Нальчикта гомер кичерә.

Ә сез туган телегездә сөйләшәсезме? Сезнеңчә, туган телне ни өчен сакларга кирәк һәм теге яки бу телләрнең юкка чыгуы нинди нәтиҗәгә китерергә мөмкин?

СЕРБИЯДӘН «ҖИДЕГӘН ЧИШМӘ»

Гүзәл Перович инде 10 ел Белградта яши, Казанын, татар телен яратып искә ала. Ул «Җидегән чишмә» дип аталган татар җырын башкарды.

– Татар җырларын җырлыйм, үзем яраткан татар ашларын пешерәм, туган шәһәремне, күңелгә якын урамнарны, балачагым һәм яшьлегем узган урыннарны сагынам. Әле мәдәни төрлелекне дә юксынам. Сербия – православиеле христианнар иле, монда мөселманнар бергә тупланыбрак яши, анысы да Белградтан ерак берничә шәһәрдә генә. Калган калаларда күпчелек – православие динендә. Безнең Татарстандагы кебек, халыклар, милләтләр һәм диннәрнең бер-берсе белән керешеп-кушылып китүе Сербиягә хас түгел. Кабатланмас үзенчәлек өсти торган бергәлек – Европа белән Азия, Көнчыгыш белән Көнбатыш кушылмасы юк, Татарстандагы кебекне мин беркайда да очратмадым. Әлбәттә, католиклар, мөселманнар, православие динендәгеләр яши торган Сараево бар, анда өч мәдәният янәшә тора. Әмма шәһәр үзе дә шартлы рәвештә өч өлешкә бүленгән. Ә Казанда барысы да буталган, катнаш, берәү дә синең чыгышыңны төртеп күрсәтми. Ничек кенә сәер тоелмасын, мин менә шул төрлелекне бик юксынам. Бәйрәмнәрне бик сагынам! Монысы – аерым тема. Сабантуй һәм Яңа ел – иң мөһиме. Биредә Яңа ел рухы бөтенләй башка. Сербләр аны әллә ни билгеләп үтми дә. Алар өчен Раштуа бәйрәме мөһимрәк.

Ә сез туган телдәге җырларны сагынасызмы?

НЬЮ-ЙОРКТАН ВИДЕОСӘЛАМ!

Ватандашыбыз, КДУны тәмамлаган Наилә Бикчәнтәева @jasminelya Нью-Йоркта яши. Ул безгә хезмәттәшләре белән бергәләп көтелмәгән видеосәлам әзерләгән иде.

– Кайвакыт бездә искиткеч очрашулар уза. Бервакыт Бруклинда велосипедта йөри идем, Эммонс-авенюга юл тоттым, каналда ял итәргә утырдым. Шулчак бер ханым белән яулыклы әби килде дә, «Экскьюз ми» дип, эскәмиядә янәшәмә утырды. Шунда әби телефоннан татарча сөйләшә башлады. Тегесен-монысын, хәл-әхвәлен, нишләгәнен, ниләр күргәнен, монда кызы Наилә белән ял итеп йөрүләрен сөйли бу. Мин моны тыныч кына тыңлап тора алмадым, ахыр чиктә, түзмичә, сүз каттым: «Сезнең исемегез Наиләме? Мин дә Наилә бит!»

Соравымны ишеткәч, әби, шаккатып, чак кына телефонын төшереп җибәрмәде. Күз алдына китерә аласызмы, Америкада татарча сөйләшә торган адашыңны очрат әле!



КИЕВ ТАТАРЛАРЫ БЕЛӘН ТУРЫ ЭФИР

Аерым алганда, туры эфирда тумышы белән Лениногорскидан булган Киев кызы, сценарист, «СтарЛайтМедиа» медиагруппасының сериал департаменты мөхәррире Диләрә Шкурко катнашты. Ул безнең журнал белән хезмәттәшлек итә, Украинадагы татар ансамбле уңышлары, Украина татарлары үткәрә торган бәйрәмнәр турында яза. Һәм аның текстларында һәрвакыт туган ягы – Лениногорск шәһәрен сагыну сизелеп тора.

Кызганыч, тәмамланырга 15 минут калгач, туры эфир техник сәбәпләр аркасында өзелде һәм без видеоны саклый алмадык. Бу эфирны карап, үз фикерен белдерүчеләр күп булды. Милләттәшләребез белән туры элемтә бик хисле үтте. Анда 6 кеше катнашты, алар безгә татарча, украинча җырлады, үзләренә Сабантуйга чакырды.

Ә сезнең Украина Сабантуенда булганыгыз бармы?

«ТЕЛ УЛ – МИСТИК СУБСТАНЦИЯ»

Лингвист-полиглот Дмитрий Петров телләрне саклау өчен көрәшү зарурмы, ни өчен укырга кирәк һәм татар телен ничек «тәмле» итеп өйрәнеп була кебек сорауларга җавап бирә.

Әңгәмәдәш:
Ксения Сёмина

– Дмитрий Юрьевич, сезнең лингвист портфолиогызда берничә дистә чит тел бар. Алар сезнең өчен нинди әһәмияткә ия?

– Алар – минем дусларым. Әле берсе, әле икенчесе белән аралашасы килә. Мин күңелем яткан телләрне генә өйрәнәм.

– Оригинал телендә укырга яраткан китапларыгыз бармы соң?

– Ричард Бахның «Иллюзии»ләре – минем өчен төп әсәр, бу китап бераз гына булса да дөньяга һәм чынбарлыкка мөнәсәбәтемне чагылдыра. Рус язучыларыннан Михаил Булгаковны яратам. Поэзиягә мөкиббән китәм. Минем өчен шигырь – тел дәрьясына керер өчен кирәкле әфсен ул. Итальян теле өчен – Дантеның «Божественная комедия», француз теле өчен – Вийон балладалары һ.б.

– Ә татар теле өчен?..

– Тапшыруга әзерләнгәндә, мин Габдулла Тукай һәм Муса Җәлил әсәрләрен укып карадым. Татар теленең көен тотмакчы булдым.

– Һәр телнең үз ритмы бармыни?

Фото: Эдуард Хәйруллин

ДОСЬЕ:

Дмитрий Петров – психолингвист, полиглот, тәрҗемәче, телевидение алып баручысы, чит телләрне өйрәнү буенча уникаль система төзүче, Мәскәү дәүләт лингвистика университеты мөгаллиме, «Культура» телеканалындагы «Полиглот» программасы һәм «Базовый татарский с Дмитрием Петровым» программасы авторы. Төрле дәрәҗәдә 40 тел белә, шулардан сигезен актив файдалана.



– Әлбәттә. Татар телендә, мәсәлән, бу бик моңлы мелодика. Ул телнең структурасын, әлеге телнең һәм, димәк, халыкның әйләнә-тирә мохитне шигъри тоемлавын чагылдыра.

– Сезнең методиканың үзенчәлеге нидә?

– Беренчедән, өйрәнүнең җыйнаклыгында. Мин атнасына бер тапкыр гына шөгыльләнеп нинди дә булса уңышка ирешүгә ышанмыйм. Хәзерге заманда кеше мәгълүматны җыйнак, кыска, тыгыз формада һәм чикләнгән вакыт эчендә генә кабул итә. Мәсәлән, берничә атна буе көн саен шөгыльләнеп. Икенчедән, образлар системасыннан файдалану мәҗбүри. Тел дәреслекләр белән түгел, бәлки, тере образлар белән ассоциациядә булырга тиеш. Өченчедән, шәхси фактор мөһим. Беренче көннән үк нәкъ менә сезнең өчен кирәкле темаларга сөйләшү. Дүртенчедән, грамматиканың база алгоритмнарын, спортның нинди дә булса төрен яки музыка уен коралын үзләштергәндәге кебек үк, тулысынча автоматлаштыру зарур.

– Кешенең күңеленә ятышлы нindидер мәдәни код телне өйрәнүгә ачкыч була алайса? Мисаллар китерә аласызмы?

– Бу теләсә нәрсә була ала. Мәсәлән, минем өчен татар теле, шигърияттән тыш, әле кулинария дә. Без программаны төшергәндә, мине төрле деликатеслар белән сыйладылар, һәм шуннан бирле мин һәркемгә татар халык ашларын татып карарга киңәш итәм. Гаҗәеп Казанга барырга өндим. Һәм бик күпләр бара да.

– Ә нинди дә булса ерактагы, мәсәлән, япон телен, алсак?

– Япон архитектурасы, сынлы сәнгать. Яшьләр хәзер анимега мөкиббән. Бу да үзенә бер төрле ачкычка әйләнә ала.

– Чыннан да телне берничә сәгать эчендә өйрәнеп буламы?

> “
> – Мин атнасына бер тапкыр гына шөгыльләнеп нинди дә булса уңышка ирешүгә ышанмыйм. Хәзерге заманда кеше мәгълүматны җыйнак, кыска, тыгыз формада һәм чикләнгән вакыт эчендә генә кабул итә.

– Өйрәнеп булмый инде, ә менә аның мантыйгына төшенеп һәм элементар дәрәҗәдә сөйләшә башлап була. Бирედә төп сүз – мотивация. Әгәр кешедә мотивация һәм бераз тәртип бар икән, аңа яңа тел мохитенә күнегү өчен махсус сәләтләр, күп вакыт һәм энергия таләп ителмәячәк. Безнең программалардан соң, мәсәлән, актерларның шактые телләрне өйрәнүләрен дәвам итә, кайвакыт бу аларның яңа рольләре белән бәйле була.

– Хәзер кайсы телләрне өйрәнү популяр?

– Беренче урындагы инглиз теленнән тыш – испан, кытай һәм гарәп телләре. Аларның популярлыгы арту бу телләрдә сөйләшкән илләрнең үзләренең икътисадый, сәяси йогынтысын куәтләндерүенә бәйле. Демографик фактор да мөһим. Мәсәлән, испан телендә сөйләшүчеләр саны теләсә кайсы башка телдә сөйләшүчеләр саныннан тизрәк арта.

– Аларны өйрәтүдә нәрсә дә булса үзгәрдеме?

– Һәркемгә аңлаешлы сәбәп буенча, хәзер төп тренд – онлайн-өйрәтү.

– Ул нәтиҗәлеме?

– Аудиториядә өйрәтүдән күпкә нәтиҗәсезрәк әлбәттә. Гәрчә пандемия вакытында аның әһәмияте артса да, ул мөгаллим белән күзгә-күз карап шөгыльләнүне алыштыра алмый.

– Сез үзегез укытырга яратканга шулай уйлыйсызмы?

– Мин чагыштыра алганга күрә шулай уйлыйм, чөнки тегеләй дә, болай да укытам, шул исәптән, университетта төрле онлайн-платформалар ярдәмендә дә. Онлайн-төркемнәрдә нәтиҗәлелек кимрәк. Тик бернишләп тә булмый, чынбарлык шундый, күнегергә туры килә.

– Сез ясалма интеллектның кеше-мөгаллимне алыштыра алуына ышанасызмы?

– Тулы кыйммәтле ясалма интеллект әле уйлап табылмаган. Әгәр шундыйны уйлап тапсалар, әйе, алыштырачагына ышанам. Әмма инде бүген үк нейрочелтәрләр ярдәмче роль уйный, мәсәлән, телләрне өйрәнү өчен кушымталар сыйфатында. Язма һәм телдән тылмачлык итүче электрон тәрҗемәчеләрнең һаман саен камилрәк версияләре булдырыла. Алар тизлек кирәк булган очракларда бик файдалы. Гомумән, киләчәктә лингвистика күпмедер бер дәрәҗәдә ясалма интеллект үсешенә бәйле булачак, аның төп бурычларыннан берсе – кешеләр белән аралашу бит.

– Әлеге дәвер килеп җиткәнче, яшьләрне татарчага өйрәтүне нинди ысуллар белән яхшыртып була?

– Без күп вакытыбызны виртуаль киңлектә – социаль челтәрләрдә, мессенджерларда үткәрәбез. Һәм бүген мәдәни продукт еш кына нәкъ менә шул виртуаль дөньяда пәйда була. Шуңа күрә кайбер телләр сакланып кала. Мәсәлән, веб-сериаллар ярдәмендә. Алар бик популяр, төшерү гаять күп акча да, камил техника да таләп итми. Аларны телефонга төшереп була. Менә шул юнәлештә кызыклы, актуаль, ә иң мөһиме уникаль продукт булдырырга мөмкин. Пресса белән дә шул ук хәл. Күпсанлы татар телле басмалар, тәрҗемәдән азрак файдаланып, үз контентларын күбрәк тудырса, бик шәп булыр иде.

> – Иң башта ук үзегез өйрәнә торган тел мантыйгының сезнең ана телегездән ни белән аерылуын аңлау мөһим. Әйтик, төрки телләрдә тартым кушымчалары бар, ә славян һәм башка һинд-европа телләрендә алар юк.

– Безнең блогерлар эзләгечләрдә тел продуктын үстерүнең кыенлыгына зарлана.

– Кайбер илләрдә дәүләт теле булмаган кече телләр нейрочелтәрләр, социаль челтәрләр ярдәмендә үстерелә. Мәсәлән, Испаниядә, дәүләт теле саналган испан теленнән тыш, каталон, баск, галисия телләре дә үсештә. Әлеге телләрдә сөйләшүчеләр үз телләрен саклау һәм үстерү бурычын хәл иткән. Халыкара тәҗрибәгә таянырга кирәк. Анда менә шул баланс игътибарга лаек: күп илләрдә – Һиндстан, Швейцария, Бельгиядә, бер яктан, тел мирасын саклау һәм үстерү, икенче яктан, телләрнең бер-берсе белән конфликтын киметү мөмкинлеген тапканнар. Милли телне торгызуга акыл белән керешкәндә, ул һәрвакыт уңай нәтиҗә бирә. Шул ук вакытта элекке СССРның кайбер республикаларындагы кебек аяныч тәҗрибә дә күз алдында: тел сәясәте административ ысуллар белән гамәлгә кертелгәндә, бу яхшыга алып бармый.

– Өйрәнү өчен катлаулы яки җиңел телләр булуы дөресме?

– Бу – уйдырма. Безгә үз туган телебездән ерак тел катлаулы булып тоела. Иң башта ук үзегез өйрәнә торган тел мантыйгының сезнең ана телегездән ни белән аерылуын аңлау мөһим. Әйтик, төрки телләрдә тартым кушымчалары бар, ә славян һәм башка һинд-европа телләрендә алар юк. Төрки телләрдә алар тартым алмашлыкларын алыштыра. Төрки телләрдәге,



шул исәптән татар телендәге дә, килеш кушымчалары системасы кирәкмәгән бәйлекләрне алыштыра. Ягъни бер урындагы катлаулылык икенче урында җиңеллек китерә. Мәсәлән, бик күп дөрес булмаган фигыльләрне ятлау таләп ителгән инглиз теленнән аермалы буларак, татар фигыльләре системасында чыгармалар юк диярлек. Татар телендә, тамырын белсәң, син үзең сүзнең, шул исәптән фигыльнең, бөтен формаларын ясый аласың. Мондый әйберләрне иң башта ук төшендерү кирәк.

– Дәреслекләр еш кына артык катлаулы язылган, дигән фикер бар.

– Бу шулай. Кызганыч ки, тел дәреслекләренең күпчелеге филологлар өчен филологлар язган кебек төзелгән. Ә бит телне өйрәнергә теләгән һәркемгә аңлаешлы дәреслекләр кирәк.

– Телне өйрәнергә тагын нәрсә булыша?

– Уку. Бу сүзлек запасының табигый рәвештә артуына китерә, чөнки сүзләрне контексттан башка ятлаудан мәгънә юк диярлек.

– Әмма хәзер укуга күп вакыт бирү каралмаган.

– Бу – безнең мәгълүмат кабул итү системабызны деградациягә китерә торган аяныч тенденция. Кеше тәфсилле озын текстларны укудан туктый икән, аңа, беренчедән, башкалар әйткән фикерне аңлау, икенчедән, үз фикерен әйтү кыенлаша.

– Сез ничек уйлыйсыз, игътибарны туплау сәләте югалу эволюция процессын чагылдырамы, әллә бу кире элекке хәленә кайтырлык нәрсәме?

– Төгәл генә әйтә алмыйм. Мөгаен, кеше электрон җайланмаларга һаман саен күбрәк бәйле була барадыр. Хәзер нәрсәнедер – нинди дә булса адрес яки телефонны – истә калдыру өчен хәтерне туплау кирәкми, чөнки барысы да смартфонда бар бит. Һәм боларның барысы да когнитив сәләтләрне шактый зәгыйфьләндерә. Шунлыктан баш миен, хәтерне күнектерүгә үзеңне формада тоту өчен спорт белән шөгыльләнүгә караган кебек әһәмият бирергә кирәк.

– Мәсәлән, лонгридлар уку сәләтен югалтмау өчен, укуга көненә күпме вакыт бүләргә кирәк?

– Биредә мөмкин кадәр уңайлы юлны сайлау зарур. Бүген – биш минут, иртәгә – ун, аннары – унбиш. Әкренләп үзегезгә укыр өчен иң уңайлы вакыт күләмен табачаксыз.

– Сез хәзер нәрсә дә булса укыйсызмы?

– Гадәттә мин берничә китапны берьюлы укыйм. Хәзер бу санскрит мисалында һинд-европа телләре эволюциясе турында текст һәм оригиналда Марсель Прустның «Югалган вакытны эзләгәндә» романы. Классик әдәбият уку бераз тырышлык һәм түземлек таләп итә, әмма мин әлеге күнекмәне югалтмаска тырышам.

– Без тикшергән тенденцияләрне исәпкә алганда, телләрне саклауга куелган көчнең мәгънәсе бар, дип саныйсызмы?

– Мин, артык телләр булмый, дип уйлыйм, тик бу процесс тулысынча табигый һәм уңайлы булырга тиеш. Һиндстанны позитив мисал сыйфатында китереп була. Анда бизнеста, фәндә, технологияләрдә инглиз теле өстенлек итә. Ә милли хинди мәдәният, болливуд теле, кешеләрнең үзара аралашу теле булып кала. Әле тагын һәр штатта җирле телләр бар. Мондый табигый бүленеш әллә ни көч түгүне таләп итми, шул ук вакытта телләрнең һәркайсына гаять зур ресурслар бирә.

– Фантастик «Килү» фильмында төп герой килмешәкләрнең катлаулы телен үзләштерә, һәм ул үткән һәм киләчәкнең теләсә кайсы мизгеленә сәяхәт өчен инструмент булып чыга. Чынбарлыкта моңа охшаш хәлләр булгалыймы?

– Әлбәттә. Тел – мистик субстанция. Ул нибары сүзлек һәм грамматика белешмәләре генә түгел, бәлки күңел халәте, билгеле бер үлчәнеш, киңлек. Тел һәрвакыт халыкның менталитетын һәм шул халык туплаган тарихи тәҗрибәне чагылдыра. Нинди дә булса бер яңа тел өйрәнә башласагыз, моны шунда ук тоячаксыз.

“

– Тел – мистик субстанция. Ул нибары сүзлек һәм грамматика белешмәләре генә түгел, бәлки күңел халәте, билгеле бер үлчәнеш, киңлек.

УЙНАП ӨЙРӘТЕРГӘ КИРӘК

Кеше, бигрәк тә кечкенә бала, теше-тырнагы белән барысына каршы тора... Аны мәҗбүриләп нәрсәгә дә булса да өйрәтергә тырышканда, әйтик... Мәҗбүриләү – ул тупикка илтә торган юл, дип саный татар теле буенча 30 дан артык дәреслек һәм методик әсбап авторы, филология фәннәре кандидаты, 40 елга якын эш стажы булган педагог Николай Максимов. Башка күпчелек авторлардан – чиста теоретиклардан аермалы буларак, ул татар теленә өйрәтү буенча сөйләм модельләренә нигезләнгән технологиясен Казанда үзе эшләгән 41 нче урта гомуми белем бирү мәктәбендә гамәлдә куллана. Аның сүзләренә караганда, мисалга, хәтта рус телле балаларны да татарча сөйләм теленә өйрәтү өчен бер ел вакыт җитә:

natalya_.fomina Это абсолютная правда. Я брала у Николая Максимова уроки татарского. Это потрясающий учитель, педагог и человек.

– Мәнә сезне мәктәптә татар теленә ничек өйрәттеләр? Мөгаен, кирәкмәгән мәгълүмат, аерым алганда, грамматик төшенчәләр белән башыгызны катырганнардыр... Моның белән күп кенә балаларда предметка карата нәфрәт кенә тәрбиялиләр. Үзегез уйлап карагыз. Кеше дөньяга килә, яшь ярымнар тирәсендә ул сөйләшә башлый. Һәм мәктәпкә кадәр аның тирәсендәге бер генә олы кешенең дә башына баланы грамматикага өйрәтү уе керми. Һәм бу дөрес тә! Иң мөһиме – ул сөйләшә, әйләнә-тирә дөньяны өйрәнә, шул исәптән тел ярдәмендә дә. Баланы грамматика нигезендә телгә өйрәтеп булмый. Сез бит сөйләшкәндә җөмләнең иясе белән хәбәре кайда дип анализлап тормыйсыз. Сөйләм теленә өйрәтү – теләсә кайсы телдә – сөйләм модельләренә таянып башкарылырга тиеш.

Аңлаешлы, матур, кыска, мәгънәле итеп сөйләшү өчен сөйләм теле төзелешенең үзенчәлекләрен белергә кирәк. Яхшы сөйләм теле күнекмәләре үз-үзең белән сөйләшүдән барлыкка килә алмый. Бала башкаларны тыңлый-тыңлый, әйтелгәннәрне аңлап өйрәнергә, сорауларны аңлы рәвештә бирергә һәм үзе дә шулай ук җавап бирә белергә тиеш. Мисалга, татар телендә андый сораулар 15ләп кенә: кем? нәрсә? кайсы? нинди? ничә? кайчан? кая? кайдан? кайда? кем белән? кем турында? кичек? h.б. Асылда телне өйрәнә башлаганда барысы да шушы сорауларга җавап бирү тирәсендә бөтерелә.

Татар теленә өйрәткәндә укучыларга телгә кагылышлы барлык төшенчәләрне бирергә кирәкме? Күпьеллык тәҗрибәмә таянып, шуны әйтә алам: татар телен өйрәнүче рус телле балаларга телгә караган фактларны зур күләмдә белү бөтенләй кирәкми. Уен элементларын кулланып, сөйләм телен язма телдә кулланырга өйрәтергә кирәк – җиңелрәкләрен, актив кулланыштагы сөйләм теле формаларын. Бары тик шулай гына телне өйрәнүдә һәм өйрәтүдә зур уңышларга ирешеп була.

eugenlic Я бы с удовольствием поучилась у него. Как это возможно сделать?

gulnazkaakhmetzianovp Какой хороший учитель 👍 мы б такому учителю бежали бы на уроки 😊

kamillasakh Николай Валентинович был моим преподавателем в университете. Мы с одногруппниками до сих пор вспоминаем его занятия с большим удовольствием! Даже те, кто приехали из других регионов и татарские слова слышали впервые, уже через несколько занятий с лёгкостью составляли диалоги. 😊 Бик зур рәхмәт сезгә, Николай Валентинович!

alionazhilkina 👍👍👍

gelnur_akhmadullina Мой дорогой одногруппник Николай! Пять лет вместе учились и все пять лет он удивлял нас своими идеями! Обязательно прочитаю о нем... Благодарю вас!

Фото: Ната Смирнова, Алсу Троицкая

МИЛЛӘТНЕҢ ЯШӘЕШЕ ТЕЛ АРКЫЛЫ БЕЛЕНӘ

1989 елның 21 октябрендә Үзбәкстан Республикасында «Дәүләт теле турында» Закон кабул ителә. 31 елдан соң диярлек, 2020 елның 23 сентябрендә Үзбәкстан Президенты Шәүкәт Мирзиёевның чыгышы БМО Генераль Ассамблеясе тарихында беренче мәртәбә үзбәк телендә яңгырый. Туган тел аша кешенең милли үзтәңгәллеген ничек саклап калып була, – бу хакта Үзбәкстан Республикасының Казандагы Генераль консулы Фәриддин Насриев сөйли:

– Без Татарстан Республикасы башкаласы Казанда яшибез. Бәхеткә, телләребез охшаш. Янәшәдә татарча сөйләшкәндә мин бу телне тулысынча аңлыйм. Безнең Казандагы Генераль консуллык Россиянең 14 төбәген үз эченә ала, шул исәптән – Идел буе федераль округын тулысынча. Әлеге төбәкләрдә даими һәм вакытлыча яшәүче Үзбәкстан Республикасы гражданнарының барысы да безгә консультация һәм консул ярдәме сорап мөрәҗәгать итә. Консуллыкка килгәч, шулай ук аларның күбесе үзбәк телендә сөйли. Әгәр телефон буенча яисә турыдан-туры сөйләшкәндә без: «Сезгә уңайлырак икән, рус телендә сөйли аласыз», – дип әйтәбез икән, күпләр: «Юк, минем үзбәк телендә сөйлисем килә. Телне искә төшерергә, онытмаска», – дип җавап бирәләр. Кайберәүләр өчен бу – туган якны сагыну хисләре дә.

Теләсә кайсы тел үссен өчен, бу телдә сөйләшергә генә түгел, бу телне өйрәтергә кирәк. Халыклар дуслыгы йортында милли мәдәни үзбәк үзәге эшли. Аның каршында – балалар өчен ял мәктәбе. Узган елда Казан кооперация институты каршында тагын бер үзбәк мәдәни милли үзәген ачтык. Үзәкләр буш тормый – анда олылар да, балалар да йөри. Бу туган телне өйрәнүгә ихтыяҗ бар дигән сүз. Мәскәү һәм Санкт-Петербург университетлары каршында үзбәк телен өйрәнү буенча курслар ачуга да ихтыяҗ шактый зур.

Глобальләшү безнең телгә йогынты ясыймы? Әлбәттә. Ләкин һәр дәүләт үзенең милли мәнфәгатьләрен кайгыртуга игътибар итәргә тиеш. Беренче чиратта, бу мәдәниятне, борынгы мирасны, әлбәттә, туган телне саклау һәм үстерү иканлегенә иманым камил. Минемчә, һәр милләтнең яшәеше күп яктан тел һәм әдәбият аша чагылыш таба.

УКЫТУЧЫ ТРЕНДТА БУЛЫРГА ТИЕШ

Ике ел элек Казандагы, мөгаен, иң популяр радиостанциядән тәкъдим килгәч, ул ризалык бирә. Прайм-таймда – кичке якта, бөтен кеше эштән кайта торган вакытта, ашыкмыйча, үзеңне мәҗбүриләмичә татар теле дәресен тыңларга мөмкин икән. Бердәнбер һәм төп шарт – бернәрсәгә дә мәҗбүриләми торган мондый онлайн-дәрес үзенә җәлеп итәргә тиеш! Эльза Нәбиуллина, филолог, татар теле укытучысы, тәрҗемәче, беркайчан да гомуми кабул ителгән тенденцияләргә карап кына эшләмәүче кеше, әлбәттә, бу тәкъдимне кабул итә, ризалаша. Ни өчен?

– Әгәр җентекләбрәк карасак, сүз бөтенләй укыту турында бармый. Кыска гына вакыт эчендә тыңлаучыны кызыксындыра белергә тиешсең. Һәм шул ук вакытта бу күңелле булсын, уңай мөнәсәбәт калсын. Асылда бүгенге көндә гадәти дәресләр алып баручы укытучылардан да шул ук нәрсә таләп ителә. Тел өйрәтүче укытучының төп бурычы – укучыны белемгә тарту. Һәм укытучы трендта булырга тиеш. Әгәр элек ул мәгълүмат чыганагы булса, хәзер вазгыять үзгәрде – укучы бүген үзе теләсә кайсы мәгълүматны теләсә кайсы чыганактан таба ала. Шуңа күрә дә актуаль, кирәкле булу өчен әлеге рольне кабул итәргә һәм үзенчәлекле формаларны эзләргә кирәк. Әйе, тел – белемнең шактый статик формасы, моны исәпкә алганда, бу бик җиңел эш түгел. Ләкин башка вариантлар юк.

Татар теле актуаль булсын өчен нишләргә? Аны җәмгыять өчен заманчалаштырырга кирәк. Сүз уңаеннан, башка телләргә өйрәтүчеләр дә шул ук фикердә тора. Татар теле һәркемнең йөрәк түрендә була алмый, әлбәттә, әмма шул ук вакытта «ул дәүләт теле булганга, гражданин буларак, мин аны белергә тиеш» дигән фикерне сендерергә мөмкин, дип уйлыйм.

СЫЙФАТЛЫ МУЗЫКА АША КЕШЕНЕ ТЕЛ ӨЙРӘНҮГӘ ҖӘЛЕП ИТӘРГӘ БУЛА

– Музыка асылда – тел булмаган мохит, ә андагы тел – гитара яисә синтезатор кебек корал, – дип саный «Taraf» төркемен оештыручы һәм аның катнашучысы, татар телендә заманча җырлар башкаручы Нияз Мөбәрәкҗанов. – Текстны үзен генә ишеткәннән соң тумаган хисләрне, ихтимал, музыка аша уятырга мөмкиндер. Хиссез, коры, начар башкарылган партияне беркемнең дә тыңлыйсы килми. Тел белән дә шулай ук – бары тик намус белән, кыланмыйча, үз юнәлешеңне тоеп башкару могҗиза тудырырга сәләтле. Күптән түгел генә дөнья күргән «Unsigez» дип аталган мини-альбомыбызда без моңа ирешкәнбездер, дип ышанам. Без аны яңа жанрда һәм, әлбәттә, татар телендә чыгардык.

– «Саклап калу» дигән сүзләр үзләре үк артка тарта кебек, үлеп баруны аңлата кебек тоела, – дип дәвам итә сөйләшүне аның «Taraf» төркеме буенча коллегасы **Булат Шәймиев.** – Бернәрсәне дә сакларга кирәкми – аны актив кулланырга кирәк! Телебезне, мәдәниятебезне миңа тапшырган бабаларыбыз каршында җаваплылык тоям, мин боларның барысын да үз балаларыма тапшырырга тиеш. Татар телен «кухня» теле дип уйлаучыларны, масштабы буенча зуррак булган рус мохитендә яшәүче мейнстримга бирелеп, «җиңел» юл белән китүчеләр, дип саныйм.

Татар теле шактый уңышлы кулланыла торган өлкәләрнең берсе – музыка. Нияз әйткәнчә, сыйфатлы, чын музыка аша кешене кызыксындырырга мөмкин, ул үзеннән-үзе телгә тартыла башлый.

Күбрәк популярлык казану өчен, без үзебезнең проектларыбызны киңрәк таралган телдә башкара алыр идек, тик бу очракта без үзебез булып кала алабызмы соң? Берничә ел элек мин үземнең YouTube-каналымны булдырдым, анда татар телендәге видеолар урнаштырам. Әйе, әлегә минем язылучыларым миллион түгел, әмма үземә тугрылыклы аудиториям бар. Гомумиләштереп әйткәндә, без «телне саклау» темасына бертуктаусыз сөйләшүләр алып бармыйбыз, ә нәрсәдер эшлибез. Һәм бүген мин татар телен өйрәнергә телäгe туган яшьләрне күбрәк очратам, хәтта рус мохитендә дә. Аны куллануның заманча мәйданчыклары бүген юк түгел – ел саен «Печән базары», Tat Cult Fest кебек фестивальләр оештырыла. Ләкин әгәр һәркем үзенең яраткан шөгыле белән туган телендә шөгыльләнсә, алар күбрәк тә булыр иде.

ТӨШЕНКЕЛЕККӘ БИРЕЛМӘСКӘ! УҢЫШТАН КОТЫЛЫП БУЛМАЯЧАК!

– Shoner Paul татар теленә үзсүзле, туры сүзле Павел дип тәрҗемә ителә. Бу минем бабамнардан килгән кушамат, – дип сөйли **Павел Александров** (Shoner Paul), удмурт телендә җырлар башкаручы, «Liet International – 2017» конкурсы призеры (кече халыклар өчен «Евровидение» – ред. иск.). – Һөнәрем буенча мин этномузыколог һәм фольклорның чиста килеш кешеләрнең күбесенә аңлашылып бетмәгәнлеген яхшы аңлыйм. Музыка популяр булсын өчен, аны үзенең асылын югалтмаслык итеп заманчалаштырырга кирәк. Үземнең жанрны мин төгәл билгели алмыйм – мөгаен, world music дип атарга буладыр. Мин милли музыканы алам, аңа бүген актуаль булган битлар һәм удмурт текстларын, мисалга, йола җырларын тоташтырам. Минә шундый композицияләрнең берсе күптән түгел генә интернетта 27 меңгә якын тыңлау җыйды. Сүз дә юк, беренче чиратта минем музыканы текстларны аңлаган удмуртлар тыңлый, ләкин соңгы өч елда мин чит илләрдә яшәүче кешеләр дә кызыксынуын күрәм – бу күрсәткеч саннар мәйданчыгындагы мәгълүматлардан күренә. Өстәвенә, кызыксыну тел буенча «туганнар» – фин, эстоннар ягыннан гына түгел, бәлки перулылар, итальяннар, испаннар тарафыннан да сизелә... Һәм бу куаныдыра, чөнки Европа публикасына ошау шактый катлаулы. Кызганычка каршы, күп кенә халыклар (мәсәлән, корсикалылар, эльзаслылар, бретонлылар) үз мәдәниятләрен инде югалткан – мин моны алар үзләренең милли көйләрен түгел, бәлки күбрәк католик традицияләр белән тыгыз бәйләнгән урта гасыр музыкасын яңгыраткан Европа фестивальләре буенча да күрәм. Һәм менә бу кешеләрнең тирәндәге халык традицияләренә һәм телләргә карата кызыксынулары искиткеч зур! Бәхеткә, бездә вазгыять әлегә башкачарак – без барысын да җуеп бетермәдек әле.

Җырлар аша халыкларның телләрен саклап калу өчен нишләргә? Күңелне төшермәскә, төшенкелеккә бирелмәскә! Сыйфат өчен тырышып эшләгәндә һәм көндәшлекле мохиттә этник музыка да популяр була ала. Һәм иң мөһиме – тыңлаучылар аларны «попса» белән бер рәткә куймый. Юк, мин попмузыканы начар димим, тик барыбыз да аның кыска гомерле икәнлеген белә. Быел Татарстанда «Таба» дип аталган яшьләр этнопроекты оештырылды, аның кысаларында заманча этник музыка фестивале үтте. Анда катнашучылар – Идел буе милли коллективлары – кырыс сайлау узды. Нәтиҗәдә әлеге яшьләр безне, ягъни оештыручыларны һәм профессионалларны гына түгел, төрле халыклар телендә яңгыраган этник музыканы тыңлау яисә, Валерий Сюткин, Niletto һәм башка поп-культура йолдызлары чыгыш ясаган күрше мәйданчыкка барып, үзләре теләгән көйләрне тыңлау ирекe булган гади тамашачыларны да шаккатырды. Кешеләрнең китәсе килми һәм шул чакта мин бер нәрсәне аңладым: әгәр һәр башкаручы бу юнәлештә дәвам итсә, уңыштан котылып булмаячак, телгә музыка аша игътибарны җәлеп итү мөмкин хәл!

Хәзерге вакытта туган телдә текә этник проектлар төзү буенча Россия регионнары арасында Башкортостан флагман булып санала. Әлеге республика беренчелекне бирми – нәкъ менә анда киләсе елда Бөтендөнья Фольклориадасы оештырылачак. Әмма күп кенә этник коллективлар өчен үсеш ноктасы була барып, Татарстан да үз позицияләрен бирми. Безнең төбәкнең этник төрлелеген һәм шундый потенциал исәпкә алып, безгә дә үзебезнең эре милли фестивалебезне булдырырга кирәк. Туристларны җәлеп итү ягыннан да, ләкин иң әһәмиятлесе – үзебез өчен, үзебезнең этник музыканы һәм туган телләрне үстерү максатында.

ХАЛЫК ҖЫРЛАРЫ АША ТЕЛӘСӘ КАЙСЫ ТЕЛНЕ САКЛАП КАЛЫРГА МӨМКИН

– Халык җырлары аша теләсә кайсы телне саклап калырга мөмкин, – дип саный «Верес» рус халык җыры ансамбле һәм Александр Пушкин исемендәге мәдәни үзәгенең фольклор коллективы җитәкчесе **Денис Денисов.** – Шул ук вакытта матур җыр әлеге телдә сөйләшкәннәрне генә түгел, башка милләт вәкилләрен дә кызыксындырырга мөмкин. Син әлеге җырны ишетәсең, әчтәлеге белән кызыксынасың, сүзләрен беләсең килә, ниндидер сүзләр башыңа кереп кала, шулардан әкренләп сүзлек запасы туплана. Яңа сүзләр җыр аша тизрәк истә кала дигән фикергә килдем. Балаларның да башта дәрестә җырлый башлаулары, аннан соң гына грамматикага керешүләр юкка гына түгелдер. Мин рус халык җырларын гына түгел, татар һәм удмурт җырларын да башкарам. Һәм менә инде аралашканда бу телләрдә очраган таныш сүзләрне отып алам һәм әйтелгәннәрнең мәгънәсенә төшенә башлыйм.

Без еш кына Татарстан авыллары буйлап экспедицияләргә йөрибез, фольклор туплыйбыз, әбиләрдән халык җырларын җырлап күрсәтүләрен үтенәбез. Алар буыннан-буынга тапшырыла, шуңа күрә дә бу җырлар безнең көннәргә кадәр килеп җиткән. Без аларны теркәргә, сүзләрен истә калдырырга тырышабыз, кайберләренең мәгънәләрен төгәлләштерәбез. Әлбәттә, рус теленә карата телне саклап калу мәсьәләсе бүген әле актуаль түгел. Шулай да ниндидер дәрәҗәдә ул да чисталыгын югалта, үзгәрә. Бөек классиклар тарафыннан мәдхия җырланган рус теле бүгенге көндә яшьләргә бик аңлашылып бетмәскә мөмкин. Сүзләр чит телдәге аналогларга алыштырыла, кыскартыла, башка мәгънә аңлата башлый. Мәсәлән, «косарь» сүзе кебек, бүген ул сленгка әйләнде, ә кайчандыр печән чабучы кешене аңлаткан. Яисә хуҗабикәләр идәннәрне чистартканда куллана торган киң йөзле пычакны – бу турыда «Подай, матерь, косаря!» шаян җырыннан ишетеп беләбез. Шул рәвешле халык иҗаты, бүгенге көндә ниндидер сәбәпләр аркасында сөйләм теленнән төшеп калган кызыклы сүзләрне, гыйбарәләрне, эндәшләрне саклап калып, телне вакыт кысаларында «беркетеп калдырырга» ярдәм итә.

ТАТАРЧА УКУ – ЗАМАНЧА УКУ

Автор: Руфия Фазылова

Кичке сәгать ун. Математика укытучысы (ә ул директор да) телефонына укучысыннан смс-хәбәр килеп төшә: «Абый, 49 нчы биттәге мәсьәләнең җавабын таба алмыйм». Укытучы аңлатып җибәрә. Иртән инде телефонына бүтән укучыдан башка сорау килгән була...

Кукмара районының Ядегәр урта мәктәбендә укытучылар белән укучылар мөнәсәбәте әнә шулай корылган: тәнәфесме, дәреслърдән соңмы, кичме, иртәме – укучының соравы бар икән, укытучыга мөрәҗәгать итә.

ДҮРТ ФӘННӘН – 393 БАЛЛ!

Җәй айларында бу мәктәп турында күп сөйләделәр. Шулай булмый ни, Ядегәр урта мәктәбе укучысы Инсаф Фәйзрахманов, дүрт фән буенча БДИ тапшырып, 393 балл җыйды (рус теле һәм информатикадан 100 әр балл, физикадан 99 балл, математикадан 94 балл). Инсафның уңышына милли җанлы кешеләр аеруча сөенде – татарча укыган бала бит! Егетнең тырышлыгын ул вакыттагы ТР мәгариф һәм фән министры Рафис Борһанов та билгеләп үткән иде. Башка җитәкчеләр дә Инсафның ана телендә белем алып, әнә шундый югары нәтиҗәләргә ирешүен ассызыклады. Ядегәр урта мәктәбен данга күмгән укучы бүген КФУның Мәгълүмати технологияләр һәм интеллектуаль системалар югары мәктәбендә белем ала. Бюджет урынга керүчеләр исемлегендә беренче булган ул.

Әлбәттә, Ядегәр урта мәктәбен тәмамлаучылар ел саен мондый нәтиҗәләргә ирешми. Шулай да укучылар башка елларда да сер бирмәгән. Гадәттә БДИ нәтиҗәләре район, республика күрсәткечләреннән югары була икән. Әлбәттә, моның сәбәбен беләсе килде. Югыйсә, аларда да – шул ук укучылар, укытучылар.

– Имтиханнардагы яхшы нәтиҗәләрне бер яклы гына итеп аңлатып булмыйдыр, – диде Ядегәр урта мәктәбенең директоры Рәмис Нуриев. (Сүз уңаеннан, җитәкче бу вазыйфага әле бер ай элек кенә билгеләнгән. Моңа кадәр эшләгән директор Илфат Әхмәдуллинны Кукмара районы мәгариф бүлеге җитәкчесе итеп күчергәннәр. – Авт.) Берсүзсез, укытучылар коллективы көчле. Мин үзем дә шушы мәктәп укучысы. 2010 елда КДПУны тәмамлап, дүрт ел Казанда сәүдә өлкәсендә эшләдем. Сабантуйга кайткач, мәктәпнең укыту эшләре буенча директор урынбасары авылга кайтырга өндәде. «Безгә тагын бер математика укытучысы кирәк», – диде. Шуннан ничектер тәвәккәлләдем. Балалар белән эшлисе килде. Мәктәпне тәмамлаганда үземне сынап карау өчен БДИ ны биргән идем. Ул чакта районда иң югары баллны җыйдым.

Алты ел укытучы булып эшләү дәверендә Рәмис Нуриев үзе өчен нәтиҗәләр ясаган. Беренчесе, әгәр укучының соравы була икән, аны беркайчан да җавапсыз калдырмаска! Югыйсә бала бүтән сиңа мөрәҗәгать итмәячәк, димәк, фәнгә булган кызыксынуы да кимеячәк. Икенчесе – бала белән гел элемтәдә булу. Мисал өчен, директорга укучылары кичке унда да вотсап аша сорау юллыйлар икән, иренмичә җавап бирергә. Хәер, ул гына түгел, башка укытучылар да укучылар белән даими элемтәдә, һәрхәлдә, чыгарылыш сыйныф укучылары белән бик күп эшлиләр.

Ядегәр урта мәктәбен быел 4 укучы – 2 кыз, 2 малай тәмамлый икән. Тугызынчы сыйныфка кадәр тугыз бала укыганнар.

Фото: Лилиана Вәлитова

– Быел да Инсаф кебек БДИны югары баллга бирерлек укучыларыгыз бармы? – дип сорыйм директордан.

– Алдан кычкырып куясы килми, әлбәттә. Инсаф кадәр үк җыймасалар да, Алла боерса, һичшиксез, югары балларга өметләнәбез. Математика, физика буенча район олимпиадаларында гел җиңүче, республика олимпиадаларында призлы урыннар яулаучы егетебез Дәниф Миңнебаев бар. Үземнең укучым, бишенчедән алып укыттым. Ул һич кенә дә түбән балл җыярга тиеш түгел. Хәер, калганнар да тырыш, өметле укучылар.

«АНА ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ АЛСА ЯХШЫРАК»

Ядегәр урта мәктәбендә бүген 96 бала укый, узган ел 99 булган. Тик бу әлегә генә шулай, балалар саны кимүгә түгел, ә артуга бара икән – мәктәпкәчә яшьтәге 103 бала бар. Җирлеккә дүрт авыл керә – Тарлау, Югары Шәмәрдән, Түбән Шәмәрдән һәм Ядегәр. Иң күп балалар Ядегәрдән. Ул иң зур авыл да. Бу авыллар бер-берсеннән ерак урнашмаган – 1, 3, 4 чакрым арада гына. Балаларны автобус йөртә.

Ядегәр урта мәктәбенең төп фәннәр укытучылары белән аерым бер кабинетта очраштык. Ана телендә укыту, БДИны югары балларга бирү өчен укучыларны ничек әзерләргә – сөйләшүебез шактый җитди булды.

Шулай да иң беренче укытучылардан:

– Баламны татарча укытмагыз, дип килгән ата-аналар юкмы? – дип сорадым.

– Ике ел элек, татар теле укыту белән катлаулы вазгыять башлангач, мәктәпкә ата-аналарны җыйдык, – дип сүзен башлады Ядегәр урта мәктәбенең уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары Гамилә Габбасова. – Хәзер рус телендә дә укыту мөмкинлеге бар. Кирәк дип табасыз икән, балаларны рус телендә укытырга мөмкин, дидек. Җитмештән артык гаиләнең ник берсе: «Баламны рус телендә укытыгыз», – дип гариза язсын! Әле киресенчә: «Гомер буе татарча укыдык, ни сөйлисез?» – диючеләр булды. Безнең җирлектә бик милли җанлы кешеләр яши. Балалар да үзара татарча сөйләшә. Әмма рус телен дә, инглиз телен дә яхшы беләләр. Мисал өчен, рус теле дәресендә – бары русча, инглиз теле дәресендә инглизчә генә аралашалар. Хәзер бит интернет заманы, рус телен белмәү проблемасы юк.

Тик укытучылар шуны да искәртте: барлык фәннәрне татарча укытсалар да, терминнарны рус телендә аңлаталар. Өлкәнрәк сыйныфларга күчкән саен бу күренеш арта гына икән.

– 9 сыйныфтан соң Төп дәүләт имтиханын балалар татарча бирә әле, – диде Гамилә Габбасова. – Ә менә БДИны фәкать рус телендә генә биреп була. Әлбәттә, бу татар балалары өчен яхшы түгел. Нәрсә дисәң дә, алар бит татарча уйлый.

Мәктәпнең унберенче сыйныф укучылары белән дә аралаштык. Ике егет, ике кыз инде төгәл кайсы югары уку йортына барасын беләләр.

Шул ук мәсьәләне русча укып, укучы аны башта татарчага тәрҗемә итә, аннан чишә. Дөресен генә әйткәндә, БДИ ул бала ана телендә укымасын өчен бер дигән форсат булды. Милли мәктәпләрнең елдан-ел кимүе дә, иң беренче чиратта, БДИ белән бәйле, дип уйлыйм.

Бу фикерне бүтән укытучылар да куәтләде. Алай гына да түгел, Ядегәр урта мәктәбенең мөгаллимнәре яшерми: дәресне татар телендә алып бару аларга җиңелрәк. Ә терминнарны рус телендә аңлату, кем әйтмешли, ничарадан бичара. Зуррак классларга барган саен, мөстәкыйль эшләрне рус телендә бирергә мәҗбүр алар. Әлеге дә баягы, укучыларны БДИга әзерли торалар.

«ЙОТЫП БАРАЛАР...»

Мәктәпнең укытучылары көчле, монысын укучыларның өлгереш нәтиҗәсеннән күрергә була. Тагын алар фикерле дә, ни уйлаганнарын курыкмыйча раслап та бирәләр. (Еш кына укытучылар үз фикерләрен белдерергә курка, дибез.)

Ризидә Шәрәфиева – мәктәпнең физика укытучысы. Кайчандыр үзе дә шушы парталар артында утырып белем алган. «Иң көчле укытучыларыбызның берсе», – дип таныштырды директор.

– Узган ел ике укучым физика фәненнән профильле БДИ сайлады, быел тагын ике бала бирә, – диде укытучы.

Бер кызык факт: узган ел Инсаф физикадан 99 балл җыйса, икенче укучысы 70 балл җыйган.

Укучыларның иҗат эшләре.

– Икесе дә сез әзерләгән укучылар, нәтиҗәләр ничек шулай төрле? – дим.

– Инсаф бит кечкенәдән олимпиадаларда катнашкан, җиңгән укучы. Җиденче сыйныфтан бирле физикадан олимпиадада район буенча беренчелекне бирмәде. Икенчесе, югары уку йортына керергә кирәк булганга, физиканы сайлаган укучы. Аның да баллары начар түгел. Шуңа күрә нәтиҗәләр дә төрле булды.

Мәктәпнең тагын бер математика укытучысы – Гөлсинә Фәйзрахманова (дүрт фәннән 393 балл җыйган Инсафның әнисе дә). Егерме елдан артык эшләү дәверендә дистәләгән медалист әзерләгән тәҗрибәле укытучыларның берсе икән.

– Гуманитар фикер йөртүче баладан математика буенча БДИны югары балларга бирүне өмет итеп буламы? – дидем Гөлсинә Фәйзрахмановага.

– Була. Моның өчен мәктәптә яхшы укытучы булу һәм баланың тырышлыгы гына кирәк. Безнең мәктәптә гуманитар фикер йөртүче укучыларның күбесе профильле математиканы сайлый. Кайбер очракта ул аларга кирәк тә булмый. Бирәләр бит, 80 баллап җыялар. Сүз дә юк, безнең балалар бик тырыш. Шуңа да андый укучылар белән эшләү бик рәхәт. Ата-аналар да җайлы, укытучыга хөрмәт белән карыйлар.

Башка җирләрдәге кебек үк, Ядегәр урта мәктәбендә дә тугызынчыдан соң ярты сыйныф китә икән. Дөрес, аларга унынчыга килмәгез, дип әйтүче юк. Бу фәкать укучыларның, ата-аналарның теләге була.

– Әле киресенчә, унынчыга калыгыз, дип үгетлибез, – диде мәктәп директоры Рәмис Нуриев. – Уналты яшьлек баланы шәһәргә чыгарып җибәрмәгез, дибез. Ләкин шулай да китәләр, имтиханнан куркалар. Югыйсә, БДИның база өлешен күп укучы уртача балларга бирә ала.

– Начар укучы да бирә аламы?

– Әйе, ала. Бездә андый мисаллар күп. Ятлап булса да бирәләр. Гомумән, БДИның база өлеше бик катлаулы түгел, дип саныйм.

Ядегәрдә һөнәр училищесы бар, шуңа да укучылар тугыздан соң китү ягын карый икән. Ә нәрсә, начар түгел ләбаса: әти-әнисе яныннан чыгып китми генә үз авылында һөнәр үзләштерә. Теләге булганнар махсус һөнәри белем алганнан соң да югары уку йортына керә ала.

АК АЛЪЯПКЫЧЛАРДА АК КАНАТ...

Укучылар турында сүз башлаганчы, мәктәп турында әйтергә кирәктер. Бәхетле бу балалар: яхшы укытучылары булган заманча белем бирү үзәгендә укыйлар. Мәктәпкә кергәндә үк игътибар иттек: биредә хәтта уен мәйданчыгы бар. Дөресрәге, шәһәр паркларыннан калышмый торган заманча мәйдан ул. Анда спорт белән шөгыльләнү өчен барлык җиһазлар, кечкенәләргә таганда атыну өчен әллә ничә төрле җайланмалар бар. (Бу мәктәпкә бүләк икән. Тамырлары шушы авылдан булган эшкуар бүләге.)

Биредә укучы кызлар ак алъяпкычтан, элеккеге мәктәп формасыннан йөри. Мондый форманы ата-аналар сайлаган. Дөресен әйтим, әлеге күренеш йөрәкләргә май булып ятты – үзебезнең мәктәп елларына кайткан кебек булдык.

Ядегәр урта мәктәбенең унберенче сыйныф укучылары быел математикадан профильле БДИ тапшырачак. Узган елгы унберләр профильле физика тапшырганнар. Бу урында аңлатып узарга кирәктер: кайсы фәнне профильле укырга икәнен укучылар үзләре хәл итә. Мондый очракта фән атнага биш тапкыр керә һәм махсус программа белән укыйлар.

– Быелгы унберләрем физиканы атнасына өч сәгать кенә укый, – диде мәктәпнең физика укытучысы Ризидә Шәрәфиева. – Чөнки профильле физиканы сайламадылар. Шулай да ике егет физикадан профильле БДИ тапшыра. Шуңа күрә, дәресләрдән соң калып, профильле сыйныфлар өчен булган программадан мәсьәләләр чишәбез.

Ядегәр мәктәбендә репетитор дигән сүзне белмиләр. Укытучының кайчан буш вакыты бар, шунда шөгыльләнәләр.

– Районның башка мәктәпләреннән: «Безнең баланы БДИга әзерләгез әле», – дип сорап мөрәҗәгать итәләр. Тик без алынмыйбыз, юкса үзебезнең балалар белән эшләргә вакыт калмый, – ди укытучылар.

Мәктәпнең унберенче сыйныф укучылары белән дә аралаштык. Ике егет, ике кыз инде төгәл кайсы югары уку йортына барасын беләләр. КФУ, Казан дәүләт медицина университеты...

Укучылар бертавыштан:

– БДИ дан курыкмыйбыз, – диде.

...Ядегәрдә тагын бер үзенчәлеккә игътибар иттек – коллективта эшләүче укытучыларның күбесе шушы мәктәпне тәмамлаган. Алар барысы да, безнең укытучылар көчле иде, дип сөйләде. Хәзер үзләре шул мәктәпнең традицияләрен, эш алымнарын дәвам итәләр. Шул исәптән, татарча укытуны да, ә нәтиҗәсе – күз алдында.

ИҢ ЯХШЫСЫ БАЛАЛАРГА

Балаларның туклануына һәрвакыт зур игътибар бирелә, чөнки җәмгыятьнең иң мөһим әгъзаларының сәламәтлеге һәм үсеше, димәк, безнең киләчәгебез дә нәкъ менә шуның белән бәйле. Шуңа күрә Татарстанда балалар өчен югары сыйфатлы продукция җитештерә торган предприятиеләрнең булуы аеруча мөһим. «Сыйфатлы» проекты кысаларында без «Татарстан Республикасының иң яхшы товарлары һәм хезмәтләре» конкурсында җиңү яулаган һәм «Россиянең иң яхшы 100 товары» Бөтенроссия программасы каталогына кергән Казан шәһәре Балалар сөт кухнясы турында сөйләячәкбез.

Предприятие «4 витаминлы эчә торган йогырт» (караҗиләк, урман җиләкләре, өрек, кишер, алма һәм груша белән) товары белән дипломант, «Детское» сөте» һәм «Кече яшьтәге балалар өчен витаминлы «Детское» сөте» товарлары белән конкурс лауреаты булды. Һәм болар – лаеклы яуланган җиңүләр, чөнки бүген Казан шәһәре Балалар сөт кухнясы дигәндә, 18 төр продукция һәм Казанның Азык-төлек һәм социаль туклану департаменты составында балалар сөт ризыкларын җитештерү тәҗрибәсе күз алдында тотыла. Балалар сөт кухнясы белән сигез елдан артык Зилә Бикпиимер кызы Солтанова җитәкчелек итә. Балалар сөт кухнясы тырышлыгы бәрабәренә шәһәр балалары, 6 айлык чордан башлап, тулысынча куркынычсыз һәм сыйфатлы сөт ризыклары белән тәэмин ителә, чөнки эшкәртү-җитештерүгә алына торган сөт һәм теләсә нинди башка продукция санитар-эпидемиологик нормаларга туры килү-килмәүгә катгый лаборатор контроль уза. Барлык продукция фәкать сыйфатлы сыер сөтеннән (бер фермер хуҗалыгыннан) җитештерелә, аңа составында бифидобактерияләр һәм пробиотиклар булган файдалы һәм тере эчеткеч культуралар өстәлә.

Моннан тыш, барлык продукция дәвалау-профилактика үзлегенә ия. Сөт продуктлары бактерицид йогынты ясый, эчәклек микрофлорасын нормальләштерүгә ярдәм итә, зарарлы микрофлора үсешенә комачаулый. Сөт продукциясе базарында Балалар сөт кухнясының тагын бер өстенлеге – «Хәләл» стандарты буенча 13 төр сөт ризыгы җитештерү. Продукция Татарстанда төрле федераль сәүдә челтәрләрендә, шәһәрдәге тарату пунктларында сатыла, Республика балалар клиника хастаханәсенә, Суворов училищесына, Казанның берничә коммерцияле балалар бакчасына һәм мәктәбенә китерелә. Уникаль сөт продукциясе барлык яшь категорияләренә караган кешеләр өчен файдалы.

ДЕПАРТАМЕНТ ПИТАНИЯ КАЗАНЬ

Фотолар Казанның Азык-төлек һәм социаль туклану департаментыннан алынды. Реклама

Илшат Ганиев, «Майский» Теплица комбинаты» ҖЧҖ генераль директоры.

ЛАЕКЛЫ ҖИҢҮЛӘР

Татарстан төрле тармакларда сыйфатлы продукциясе белән яхшы танылган. Бу юлы сүз һәр Татарстан кешесенә яхшы мәгълүм – яңа өлгергән һәм экологик чиста яшелчәләр җитештерүче «Майский» Теплица комбинаты» ҖЧҖ турында барыр.

12 ноябрьдәге Сыйфат көненә багышлап, безнең журнал яхшы сыйфатлы продукциясе белән яхшы билгеле компанияләр турында сөйли. Татарстан брендының искиткеч тәмле кыяр, томат, борыч, баклажаннарын, яшел тәмләткечләрен һәм җиләкләрен бик күп хуҗабикәләр татып карарга өлгерде инде. «Татарстан Республикасының 2020 елгы иң яхшы товарлары һәм хезмәтләре» конкурсы экспертлары да, алар белән килешеп, монда җитештерелгән продукциянең өстенлекләрен югары бәяләде. Шулай итеп, предприятие абруйлы конкурсның «Азык-төлек товарлары» номинациясендә «Ябык грунтта үстерелгән яшел кыярлар (уртача җимешле, кыска җимешле)» товары белән лауреат (җиңүче) һәм шушы ук номинациядә «Ябык грунтта үстерелгән югары сортлы татлы борыч» һәм «Югары сортлы күк җиләк» товарлары белән дипломант булды.

1974 елда нигез салынган «Майский» Теплица комбинаты» ябык грунт яшелчәләрен җитештерү буенча махсуслаштырылган предприятие булып тора. «Майский» ТК» ҖЧҖ Татарстанның нитратларсыз һәм пестицидларсыз үстерелгән экологик чиста һәм яңа өлгергән яшелчәләргә ихтыяҗын тәэмин итә. Химикатлар кулланмау – предприятиегә күп еллардан бирле җитәкчелек итүче генераль директор Илшат Ганиевнең принципиаль позициясе. Ул экологик чисталыкны һәм технологияләрне саклауны өстенлекле урынга куя. Шуңа күрә дә «Майский» халыкара сыйфат системасын керткән, ябык грунт яшелчәләренең уңышы буенча Россиядә әйдәп баручы буларак, үсемлекләрне биологик саклауны үстерү буенча үз системасын тырышып үстерә бара. Мондый караш булганда, комбинатның киләчәктә дә сыйфат конкурсларында яңа җиңүләргә ирешәчәге ышанычлы!

Фотолар «Майский» Теплица комбинаты» ҖЧҖнән алынды

Реклама

ТАТАРСТАННЫҢ АКЫЛЛЫ ТЕХНОЛОГИЯЛӘРЕ

Республиканың җитештерү тармагы төрле казанышлары һәм оста белгечләре белән танылган. Бу өлкәдәге әйдәп баручы компанияләрнең берсе – «әйберләр интернеты»н кулланып, нефть сәнәгате өчен инновацион технологияләр һәм продукция җитештерә торган «Автоматлаштыру, үлчәү, инжиниринг» компаниясе.

Фәнни-техник үзәк телеметрик мәгълүматларны җыю һәм эшкәртү өчен үлчәү җиһазлары, функциональ контроллер шкафлары җитештерә һәм төрле максатларда кулланыла торган программалар әзерли. Предприятиенең югары квалификацияле коллективы нефть һәм газ чыгара торган предприятиеләр өчен җитештерүне автоматлаштырырга мөмкинлек биргән акыллы приборлар эшләп чыгара. «А2И» Фәнни-техник үзәге» ҖЧҖ Россия Федерациясе һәм чит ил нефть компанияләре белән хезмәттәшлек алып бара.

– Миссиябез югары нәтиҗәле һәм көндәшлеккә сәләтле приборлар, җиһазлар һәм программалар эшләп чыгарудан гыйбарәт, – дип сөйли «Автоматлаштыру, үлчәү, инжиниринг» Фәнни-техник үзәге» ҖЧҖ директоры Владимир Самойлов. –Продуктларыбыз процессларны автоматлаштыру хисабына югары нәтиҗәлелекне тәэмин итә. «Әйберләр интернеты» болыт технологияләре нигезендә читтән торып контрольдә тоту һәм идарә итүнең автоматлаштырылган системасын төзү өчен үзебез эшләгән программа модульләренең җитәрлек күләмдәге кирәкле тупланмасына ия без.

Татарстанның әлеге уңышлы компаниясе фәнни потенциал һәм стратегик менеджментны берләштерүнең бик яхшы үрнәге булып тора. Бу ширкәт А2И-БЗП күчерелмә саклагыч боксы товары белән «Татарстан Республикасының 2020 елгы иң яхшы товарлары һәм хезмәтләре» республика конкурсының «Җитештерү-техник максатлардагы продукция» номинациясендә лаеклы рәвештә лауреат (беренче урын), А2И-ППК тарировка җайланмасы белән шул ук номинациядә дипломант (икенче урын) исемен яулады. Фәнни-техник үзәкнең ышанычлы продукциясе эксперт комиссиясе тарафыннан югары бәяләнде һәм конкурсның федераль этабында катнашу өчен тәкъдим ителде.

Фото «Автоматлаштыру, үлчәү, инжиниринг» фәнни-техник үзәгеннән алынды.

КИЛӘЧӘГЕБЕЗНЕ ЯХШЫРТЫРГА ТИЕШЛЕ ПРОЕКТЛАР

КАЗАННЫҢ 12 ПАРКЫ

Җәяү йөрергә, тауларга менәргә һәм спортның су төрләре белән шөгыльләнү өчен табигатьнең 4600 гектар мәйданында уникаль ландшафт белән таң калдырырлык биотөрлелеккә сокланырга мөмкин... Сүзебез Руж елгасы үзәнендә, Торонто буйлап җәелеп киткән Rouge Natinal Urban Park паркы турында. Әлегә ул дөньяда су өстендәге беренче һәм бердәнбер шәһәр милли паркы. Ә менә икенчесе Татарстанда барлыкка килергә тора.

Автор:
Ольга Туманская

«Белем» паркы

КОЛАЧ ҖИТМӘСТӘЙНЕ КОЛАЧЛАП

Казансуның шәһәр эченнән уза торган һәм шәһәр янындагы үзәнлекләре, су өстен һәм Идел белән кушылганга кадәр яр буе территорияләрен һәм Зәңгәр күлләрне дә кертеп санаганда, 3 мең гектардан артык мәйданны били. Нью-Йоркның тугыз үзәк паркы кадәр диярлек! Казансуның Канада тәҗрибәсе һәм башка алдынгы практикалар үрнәгендә илһамланып эшләнгән үсеш стратегиясе – елганы саклап калу өчен кораштә мөһим адым.

– Әлеге проект Казанның яңа образын барлыкка китерәчәк – Казан Россиядәге елга паркларының иң зур экосистемасы булган шәһәргә әйләнәчәк, – дип тәгәллек кертә Казансуның үсеш стратегиясен эшләгән Orchestra архитектура студиясенең партнеры Екатерина Гольдберг. – Стратегия елганы халыкныкы итә һәм бер үк вакытта аның табигый байлыгын да саклап калачак.

Әлбәттә, проект Казансуга гына кагылмый, ул яр буе зоналарын да үз эченә ала – ә бу шәһәр эчендә 68 чакрымга сузылган яр буйлары. Сүз аерым-аерым кечкенә яр буйлары төзелеше турында түгел, ә 12 парктан торган бердәм чылбыр турында бара. Әйе, ул чын мәгънәсендә су өстендә милли парк булачак, аның үсеш стратегиясе коры җирдәге глобаль территорияне төзекләндерүне генә түгел, ә елганың үзенең экологик аспектларын да, яр буйларында яшәүче кешеләр, шулай ук төзүчеләр белән эшне дә күз уңында тота. Участок хуҗаларына, анда тоташ торак йортлар салганчы, ул территорияләрне альтернатив рәвештә үзләштерү һәм үсеш юллары тәкъдим ителгән.

– Без биш ел элек үк елганың үсеше буенча комплекслы күзаллау юклыгына төшендек, ә яр буйларын ныгыту буенча шактый кырыс тәкъдимнәр ишетә идек, – дип сөйли ТР Президенты ярдәмчесе, Казансуның үсеш стратегиясе кураторы Наталия Фишман-Бекмамбетова. – Яр буйларына тәртипсез рәвештә төрле биналар төзеп куярга теләүчеләр дә булды. Участокларны тәртипсез рәвештә үзләштерүне туктатырга, кыйммәтле территорияләрне – сулыкларны да, яшел зоналарны да саклап калырга кирәк иде. «Фаршны яңадан иттарткыч аша уткәреп булмаганны» барыбыз да аңлый. Стратегия ике ел эшләнде, һәм күренүенчә, алга куелган беренчел бурычларны башкарып чыктык, хәтта Гаврилов урамындагы төзелеш тә – безнең шәһәр төзелеше буенча озакка сузылган каршылык – стратегияне тәкъдим иткәннән соң уңай хәл ителде.

КАРШЫЛЫКСЫЗ МОХИТ

Казанның нәкъ үзәгендә, урман эчендә, кабан дуңгызлары гаиләсе көн итә. Ә Рус-Алман Швейцариясе территориясендә куян һәм су күсесен очратырга була, кайчак челән тавышы да ишетелеп китә... Шәһәр парклары гына түгел, ә Кызыл китапка кергән хайваннары да булган кыйммәтле табигать зоналары – мегаполис өчен уникаль мохит!

– Казансуның үсеш стратегиясе мондый территорияләрнең үсешенә бөтенләй яңа караш тәрбияли, – ди Казанның баш архитекторы урынбасары, Казан мэриясе каршындагы Иҗат төркеменең җитәкчесе Дарья Толовенкова. – Без табигать структурасына бөтенләй диярлек кагылмыйбыз, бары тик сак кына аңа кушылып китәбез. Ягъни елга ярларыннан чыга икән, ул паркка килгән кешеләрнең мәнфәгатьләренә берничек тә комачауламаячак – кемнеңдер яраткан эскәмиясе су астында калмаячак (чөнки ул урында эскәмия булмаячак), һәм кеше белән табигать арасында берниндн каршылык та килеп тумаячак. Мондый карарлар урбанистик күзаллаулардан гына

Казансу үсеше стратегиясен презентацияләү макетлары Шәһәр үсеше фонды матбугат хезмәте тарафыннан бирелде

чыгып кабул ителми, бирегә экологик план да күз уңында тотыла, күп нәрсә табигатькә кайтарылачак.

Казансу үзенә төрле чыганаклардан чыккан пычракларны җыеп, бөтен шәһәр аша ага. Стратегия аны чистарту буенча бер төркем чараларны үз эченә ала. Әлбәттә, билгеле бер очракларда махсус чистарту корылмалары кирәк булачак, әмма Казансуның сакланып калган табигый ярлары үзләре дә чистарта торган үзенчәлеккә ия булып чыкты.

Кабан күлендә билгеле бер үсемлекләр утыртылды һәм алар тернәкләнеп китеп, кирәкле функцияне башкарганчы шартлар тудырылды. Казансуда боларның барысы да бар! Кешеләр андый урыннарны сазлык дип йөртә. Ә ул «сазлык»лар, энә шул пычракны җыеп, зарарсызландыра. Табигый «чистарткыч»ларны юк итеп, ясалмаларын булдыру өчен өстәмә чыгымнар тудырганчы, аларның табигый структурасын саклау бик мөһим, дип саный стратегияне эшләүчеләр.

Екатерина Гольдберг суны шушы рәвешле табигый чистарту процессы көчле сәнәгать пычракларыннан да файдалы, дип ачыклык кертә. Әмма елганың әкренләп экореабилитацияләнү процессы башлансын өчен, беренчедән, әлеге зоналарга кешеләрне кертмәскә кирәк, икенчедән, пычрану чыганакларын юк итәргә. Монысы инде үзе бер квестка тиң.

– Безнең мәгълүматларга караганда, Казанда пычрак суларын елгага агыза торган эре предприятиеләр калмады, әмма яңгыр сулары һәм шәхси сәнәгать калдыклары белән проблемалар бар, – дип сөйли Екатерина Гольдберг. – Гадәттә, суның сыйфат мониторингы белән экологлар һәм активистлар шөгыльләнә. Без исә елганың тормышында катнашырга теләгән һәркем куллана алырлык махсус платформа булдырырга телибез.

Стратегиянең зур өлеше агарту эшенә багышлануын исәпкә алганда, әлеге идея утопия түгел. Һәм, ихтимал, күпмедер вакыт узгач Казансу паркларында суның пычрану дәрәҗәсен билгели торган күчмә датчиклар белән йөрү гадәти хәлгә әйләнер. Аларны якындагы экоүзәктән алырга, ә сынау нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны смартфоннан махсус кушымта аша җибәрергә мөмкин булачак.

«Урам» паркы.

«Иске Казансу» паркы.

ЯҢАЧА ЯШӘҮ РӘВЕШЕ

Экологлар санап чыгарган: Казансу парклары елына 10 100 тонна кислород эшләп чыгарачак, ә углекислый газны исә ике тапкырга күбрәк – 22 735 тонна йотачак. Әгәр дә бу мәгълүматларны милләтнең сәламәтлегенә – эчелмәскә тиешле даруларга, «алынмый калган» аллергеннарга, нерв ныклыгына күчерсәк? Андый саннар да бар.

Йөрәк-кан тамырлары авырулары – 30 процентка, сулыш юллары авырулары 40 процентка кимиячәк. Тулаем алганда, үлүчеләр саны 13,4 процентка азрак булачак. Сумнарда да санап чыгарылган – авыручылар саны кимүдән икътисадый файда елына 1,5 миллиард сум тәшкил итәчәк!

Иң мөһиме – әлеге стратегияне тормышка ашыру шәһәр кешеләренең яңа гадәтләре барлыкка килүгә этәргеч бирәчәк. Аларны сәүдә үзәкләреннән табигатькә алып чыгачак, комарлы шоппингны йөгерүгә һәм йогага, көймәләрдә һәм байдаркаларда йөрүгә, триатлонга һәм спорт ориентлашуына, кошлар артыннан күзәтүгә һәм экотрекингка, тимераякта һәм чаңгыда йөрүгә, хай-дайвингка һәм су асты археологиясенә алыштырачак...

Зәңгәр күлләрдән Казансу Иделгә кушылган урынга кадәр шау-шулы магистраль һәм чокырчакырлы юллардан түгел, ә елга яры буйлап, махсус юлдан велосипедта үтү – Наталия Фишман-Бекмамбетованың хыялы. Триатлон белән мавыга торган кеше буларак, Наталия яңа «Манзара» паркы ачылуны көтә: анда транспорт йөрми торган яшел территориядә Казанның гүзәл урыннарын тамаша кылып йөгерергә мөмкин булачак. Стратегия бик күп уникаль табигый урыннарны ачачак, бүген исә аларга чыгу юлы юк диярлек. Шунысы да бар: Казансуның булачак парклары территорияләреннән безнең миллионга якын халкыбыз автомобильдә ун минутлык юлда яши, ә ярты миллионыбыз – җәяүләп үтә алырдай 15 минутлык юлда!

Шул ук вакытта, медальнең икенче ягы да бар. Стратегияне тормышка ашыру шәһәр кешеләренең ияләшкән гадәтләрен бозып куйса? Әйтик, бер урында балык тотарга, икенче җирдә кояшта кызынырга, өченчесендә – пикникка чыгарга ияләшкән булсалар? Әгәр дә аларның яраткан пляжы урынында шау-шулы опен-эйр мәйданы ясап яки балык керә торган урынга пристань китереп куйсалар?

– Стратегиянең төп бурычларының берсе – кешеләрнең гадәтләрен барлау булды, һәм стратегия проекты белән һәр паркның андый менталь картасы бар, – дип, бу сорауларга да шунда ук җавап бирә Дарья Толовенкова. – Без кемнең кайда су коенганын, машина куйганын, шашлык кыздырганын беләбез – хәтта рөхсәт ителмәгән урыннарны да. Безгә бит хулиганнарны тотарга һәм җәза бирергә кирәкми, ә кешеләрнең территорияләрне ничек итеп файдаланырга теләвен белергә кирәк. Паркларның проектларын әнә шул ихтыяҗларны истә тотып эшләргә тырышабыз.

Нәтиҗәдә, унике паркның һәркайсының үз вазыйфасы була. Ял һәм пляжлар зоналары, балык тоту һәм спорт урыннары, мангал куярга, бер көнгә, ял көннәренә, каникулларга палаткалар белән килергә рөхсәт ителә торган территорияләр... Стратегиянең структурасы шактый катлаулы, эш планы да шундый ук – әгәр бер паркка проект авторлары төзекләндерү, дизайнер эшләре белән керсә, юллар төзесә, башкаларында бернәрсә дә үзгәрми диярлек, бары тик өйрәтә торган навигация, экосукмаклар һәм күзәтү мәйданчыклары гына барлыкка килә... Иң мөһиме, стратегияне эшләүчеләр ул ачыктан-ачык, җәмәгатьчелек белән нәтиҗәле диалоглар аша гамәлгә ашырылачак дип вәгъдә итә.

ЯШЕЛЛЕКТӘ ИКЪТИСАД

Татарстанда матур урыннар күп, алар үзләренең экологик чисталыгы һәм гүзәллеге белән Алтай һәм Байкалга көндәш була ала, дип саный стратегияне эшләүчеләр. Булачак милли парк – шуларның берсе. Экосәяхәтләр – республика өчен өстенлекле туристик юнәлеш. Казансуның үсеш стратегиясе маршрутларның төрле вариантларын күздә тота – катлаулылыгы һәм озынлыгы ягыннан да, шулай ук башка урыннар белән туристик бәйләнеше ягыннан да.

Шәһәр кешеләре өчен елгада ял итү ни дәрәҗәдә кыйммәткә төшәчәк? Әгәр кичә сез елгада бушлай коенгансыз һәм балык тоткансыз икән, иртәгә шушы ук урыннарда төзек, әмма түләүле пляжлар барлыкка килергә мөмкин, үзең тоткан табан балыгы керкә балыгы бәясенә төшүе ихтимал.

– Казанда эш болайрак тора: шәһәрнең барлык парклары да бушлай, сезгә бары тик өстәмә хезмәтләр өчен генә түләргә кирәк булачак, ә ул хезмәтләрдән, асылда, файдаланмаска да мөмкин. Мәсәлән, кафеда кәһвә сатып алганда, – дип, ачыклык кертә Дарья Толовенкова. – Казансу парклары белән дә шулай ук булачак. Сез әлеге территориядә бушлай ял итә аласыз, шул ук вакытта берәр түләүле хезмәттән файдаланырга мөмкин.

Рус-Алман Швейцариясе.

Шул ук вакытта нечкәлекләре дә бар: стратегиягә кергән кайбер участокларның хуҗалары да бар. Аларның күбесе үз территорияләрендә стратегиянең гомуми концепциясе белән каршылыкка керми торган бизнес корырга теләячәк. Мәсәлән, бөтен уңайлыклары булган палаткалардан торган шәһәрчек. Ул бушлай урыннарга көндәш була алса, начармыни?

Стратегияне әле күптән түгел генә тәкъдир иттеләр, ә инде проектларның берсе – яшьләрнең «Урам» экстрим-паркы гамәлгә ашырылган да инде. Озакламый тагын берсе гамәлгә ашарга тора – «Манзара» паркы буенча халык фикерен белешү, сөйләшүләр башланган, киләсе елга проектны финанслау өчен акчалар салынган. «Казансу буе бакчалары» паркының архитекторы билгеләнгән – ул танылган француз архитекторы Мишель Пена.

– Мондый эшләр бары тик Татарстанда гына мөмкин! – дип раслый Наталия Фишман-Бекмамбетова. – Хәзер республикада глобаль проектларны башкарып чыгар дәрәҗәдә көчле команда тупланды, ул теге яки бу катлаулы инженерлык бурычларын ничек хәл итәргә кирәген аңлый һәм аның бу турыда стратегик күзаллавы бар. Һәм, беләсезме, бу бит акыллы архитекторлар яки талантлы урбанистлар хезмәте генә түгел, ә бөтен бер системада күнекмәләр туплану нәтиҗәсе дә. Ул системада йөзләрчә белгеч хезмәттәшлек итә, аларның барысын да шундый территорияләрдә эшләү буенча уртак максат берләштерә. Һичшиксез, бу Татарстан керткән ноу-хау булып тора.

Хәзерге вакытта стратегияне эшләүчеләр алдында паркларның проектларын төзү һәм аларны гамәлгә ашыру өчен чыгымнарны санау бурычы тора. Алга китеп. Ә бу исә акчалар булуга, республика аларны кая куярга икәнен беләчәк дигән сүз. Бу да планлаштыру өчен яңача караш.

КИЛӘЧӘККӘ ЭКСКУРСИЯ

Россиядәге беренче су өсте Милли паркы нинди булачак



1. «ИСКЕ КАЗАНСУ» ПАРКЫ

Бишбалта бистәсендә Зилант монастыре янәшәсендә урнашачак. Адмиралтейство һәм бистәләр, һөнәрчеләр һәм һөнәрләр – әлеге урынның тарихы шундый. Алар турында иске сәнәгать зоналарын реновацияләү һәм яңа җәмәгать урыннарында зур булмаган заманча җитештерү предприятиеләре һәм остаханәләр сөйли ала. Әлеге вакытта кулланылмый торган автокүперне җәяүлеләр өчен променад итеп үзгәртәчәкләр.

2. «МАНЗАРА» ПАРКЫ

Ленин һәм Киров дамбалары арасында булачак. «Кырлай» паркы ягыннан Кремльгә иң күркәм манзаралар ачыла. Күзәтү мәйданчыклары һәм шәһәр тарихына кагылышлы кече архитектура формалары бу урынның төп вазыйфалары булачак. Кайчандыр бирeдә Казанның капкалары булган, шушы урыннан сәяхәтчеләр шәһәр белән таныша башлаган, шушыннан кораблар йөзеп кергәннәр... Шулай ук паркта шәһәр пляжы, җәяү йөрү, йөгерү өчен сукмаклар, спорт белән шөгыльләнү өчен мәйданчыклар булачак.

3. «КАЗАНСУ БУЕ БАКЧАЛАРЫ» ПАРКЫ

«Казан» Гаилә үзәгеннән алып, «Ривьера» күңел ачу комплексына кадәр сузылачак. Су буендагы чирәмдә гаилә белән пикниклар ясарга, бадминтон уйнарга, елга буйлап үтеп йөргән пароходларны күзәтергә була. Әлеге парк Казансуның төп порты булачак, шәһәр круизлары, елга буйлап экскурсияләр шушыннан башланачак, бирeдә арендага көймә, катамаран алып йөрергә мөмкин булачак, шулай ук яхталар фестивале уздырылачак.

12 «БИШ ЕЛГА» ПАРКЫ

11 «СУ АЛАНЫ» ЭКОПАРКЫ

10 КАЗАНСУ КУЛТЫГЫ

9 «САВИН» ПАРКЫ

8 РУС-АЛМАН ШВЕЙЦАРИЯСЕ

7 «СПОРТ» ПАРКЫ

5. «БЕЛЕМ» ПАРКЫ
ТР ның Милли китапханәсе Милли-мәдәни үзәк бинасына күчте, һәм ул мульти-мәдәни пространство булып китте. Паркның концепциясен шул билгеләгән дә инде. Биредә китап фестивальләре уздырылачак, балалар һәм әдәбият дөньясына битараф булмаганнар өчен павильоннар эшли башлаячак.

6. «УРАМ» ПАРКЫ
Миллениум күпере астындагы яшьләр паркы стратегиянең беренче итеп гамәлгә ашырылган проекты булды. Ул Россиядәге иң зур экстрим-парк. Тәҗрибәле һәм яңа башлаучы спортчылар өчен скейт-парк, памп-треклар, воркаут һәм паркур өчен мәйданчыклар, стритбол паркы, эйр-паркы һәм тренинг-зонаны үз эченә алган парк ике гектарга якын мәйданны били.

7. «СПОРТ» ПАРКЫ
«Ак Барс Арена» стадионы янындагы парк берьюлы берничә спорт объектын берләштерә. Биш чакрымлы юл йөгерүчеләрнең һәм велоспорт белән шөгыльләнүчеләрнең күңеленә хуш киләчәк, ә яшел зона барлык физик культура һәм сәламәт яшәү рәвеше яклы кешеләрне үзенә сыйдырачак. Территориядә спортчылар өчен кафе һәм кунакханә урнашачак.



4. ФЕСТИВАЛЬ КВАРТАЛЫ
Цирк һәм Үзәк стадионнан ерак түгел яшел амфитеатр күтәрелә. Әлеге парк шәһәрнең төп вакыйгалары уза торган урыны булып китәчәк – биредә шаушулы чаралар, фестивальләр үткәреләчәк. Зур парковканы һәм стадионга караган зонаны Кремль манзарасына таба җәяүлеләр йөри торган юллар алыштырачак.

8. РУС-АЛМАН ШВЕЙЦАРИЯСЕ
Уникаль урын, биредә Кызыл китапка кергән хайваннар да, тарихи объектлар да күп. Аның үзенең мәдәни коды бар, җәяү йөрү өчен, пленэрларга, экскурсияләргә туры килә... Сүз уңаеннан, нәкъ менә биредә Казан тирәсендә кешенең беренче туктаган урыны табылган. Алга таба Швейцария белән «Спорт» паркын җәяүлеләр юлы белән берләштерү күздә тотыла, ул юл... Казансу өстеннән үтәчәк.

9. «САВИН» ПАРКЫ
Район масштабындагы парк, аның эчтәлеген шул якларда яшәүче кешеләр үзләре билгеләячәк. Аның территориясендә гаилә һәм балалар белән ял итү урыннары булачак, шул ук вакытта кыйммәтле табигать зоналарын да, шул исәптән Крачков күлләрен дә саклап калачаклар.

10. КАЗАНСУ КУЛТЫГЫ
«Ливадия» шифаханәсе янында тимер юл буйлап җәеләчәк. Парк елганың төп су станциясе булачак, аны спортның су төрләрен – кайтсерфингны, виндсерфингны, ишкәк ишүне, катер белән идарә итүне яратучылар үз итәчәк... Кыйммәтле табигать территорияләре һәм сулы-сазлыклы урыннар янынннан экосукмаклар узачак һәм экоүзәк урнашачак.

11. «СУ АЛАНЫ» ЭКОПАРКЫ
«Казансу култыгы» каршында сулы-сазлыклы парк «Борисоглебское» аэродромы ягыннан елгада барлыкка киләчәк. Университетлар белән берлектә биредә студентлар һәм биология белән мавыга торган кешеләр өчен фәнни база урнашачак. Мисал өчен, саз итекләре киеп, анализга су алып, аны лабораториядә тикшерергә өйрәнергә теләүчеләр өчен.

12. «БИШ ЕЛГА» ПАРКЫ
Казансуга кече елгалар коя торган урыннан алып, Зәңгәр күлләргә кадәр районны үз эченә алган табигый парк палаткалы походлар өчен менә дигән урын булачак. Яки байдаркаларда. Биредә экокемпинглар, мәктәпләрнең палаткалы лагерьлары, шулай ук пикник өчен зоналар да урнашачак. Керә торган капкалар янында парковка, прокат пунктлары һәм башка сервислар барлыкка киләчәк. Әлеге зонада үзеңне тоту кагыйдәләре, билгеләнгән экосукмаклар паркны кешенең зыян сала торган гамәлләреннән саклаячак.

ПИЛОТСЫЗ ТРАНСПОРТ ЧАКЫРТТЫГЫЗМЫ?

Автор:
Ксения Сёмина

2050 елга Кытай дөньяның әйдәп баручы транспорт державасына әйләнергә, алга киткән транспорт мәгълүмати инфраструктурасын булдырырга планлаштыра. Лидерлык өчен көрәштә көнчыгыш күрше белән Россия бәхәсләшә алыр иде, һәм Татарстан бу очракта мөһим роль уйнарга мөмкин.

Бу тезислар Kazan Digital Week 2020 халыкара онлайн-форумында яңгырады. Мәйданчык бөтен дөньядан җыелган 6 меңнән артыграк катнашучыны җыйган иде. Пилотсыз транспорт чарадагы төп темаларның берсенә әйләнде.

Фото: Иннополис матбугат хезмәте

УЙЛАП-НИТЕП ТОРМАСТАН

2019 елда Иннополиста (Татарстан), Россия шәһәрләреннән беренче буларак, «Яндекс» компаниясенең пилотсыз такси хезмәте эшли башлады. 2018 елда РФ Хөкүмәтенең 1415 нче Карары нигезендә Татарстанның да, Мәскәү кебек үк, «гомумкулланыштагы автомобиль юлларында югары автоматлаштырылган транспорт чараларын сынау» территориясе итеп билгеләнүе нәтиҗәсе бу.

«Яндекс» вәкилләре әйтүенчә, бүген инде Иннополиста сынала торган такси IT-шәһәрдән читкә чыгып йөрергә дә әзер. Форумда билгеләп үтелгәнчә, «Яндекс» – Американың сигез һәм Кытайның бер корпорациясе белән беррәттән, пилотсыз авто базарында дөнья лидерлары унлыгына керә торган бердәнбер уенчы. Әмма Россиядә «Яндекс»ның да потенциаль көндәшләре бар. Һәм әлеге көндәшләр – Татарстаннан. Сессияләрдән берсендә форумда катнашучыларга реаль вакыт режимында яздырылган ролик күрсәтелде: пассажир утыргычындагы операторлы җиңел автомобиль каршылыклар полосасын һәм караңгылыктан калкып чыгучы манекеннарны бик оста урап уза. Икенче роликта исә йөртүчесез «КАМАЗ» Татарстанның Югары Ослан районындагы таулы-чокырлы җирләреннән бик ышанычлы бара. Болар барысы да – Иннополис университеты тикшеренүләре.

– Без пилотсыз машиналарны төрле платформалар – Kia Soul, Toyota Prius, Hyundai Solaris, Hyundai Santa Fe һәм башкалар базасында булдырдык. Алар төрле типтагы – бензин, электр двигательләре белән җиһазландырылган. Безнең машиналар барысы бергә 23 мең чакрым чамасы юл үтте, – дип сөйләде форумда «Иннополис университеты» Югары белем бирү АКБО лабораториясе җитәкчесе **Сәлимҗан Гафуров**. – Хәзер без карьер транспорты тармагында тикшеренүләр үткәрәбез, шулай ук, Мәгълүматлаштыру, автоматлаштыру һәм элемтә фәнни-тикшеренү институты белән берлектә, тимер юл транспортында уртак проектны гамәлгә ашырабыз.

Карьер транспорты тармагында Иннополис белән КАМАЗ ярыша ала. Компания югары автоматлаштырылган һәм пилотсыз транспорт юнәлешен үстерү белән дүрт ел шөгыльләнә һәм шул вакыт эчендә мондый автомобильләрнең тулы бер линейкасын эшләде. Бу – завод эчендәге йөк күчерүләр өчен «Одиссей» пилотсыз машинасы да, электр двигательле кабинасыз «челнок» та, йөртүчегә ярдәм итү системасы булган ADAS-3 коммуналь автомобильләре дә (алар юлда кайбер карарларны үзләре кабул итә ала), «КАМАЗ»ның К6 яңа моделе прототибы да, 2021 елда чыгару анонсланган, күләмле ябык территорияләрдә һәм объектларда пассажирлар ташу өчен тәгаенләнгән икенче буын «ШАТЛ» микроавтобусы да.

Якын арада үзидарәле карьер үзбушаткычларын сынау башланырга тора. Компаниядә әлеге юнәлешне коммерция ягыннан иң өметлеләрдән берсе, дип саныйлар.

БЕР СӘГАТЬЛЕК МАШИНА

Боларның барысы да ахыр кулланучыга, ягъни сезнең белән безгә кирәкме икән соң? «Милли телематика системалары» концернының (компания югары технологияле Үзәк бокра автомобиль юлын һәм Мәскәү бокра автомобиль юлын төзү белән шөгыльләнә) оештыручысы һәм генераль директоры **Алексей Нащёкин** форумда түбәндәгеләрне сөйләде: «Без, 10-15 елдан соң транспорт тулысынча пилотсыз булачак һәм транспортның яңа төре өчен яңа буын инфраструктурасы таләп итeләчәк, дип ышанабыз», – диде. «Яндекс» вәкилләре дә әлеге фикер яклы.

– Без зур технологик күчеш алдында торабыз. Пилотсыз такси кеше идарә итә торганга караганда куркынычсызрак. Йөртүче-робот тәртипле, юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозмый, игътибарын читкә юнәлтми, арымый, алкоголь кулланмый, – ди «Яндекс»ның пилотсыз автомобильләр бизнесын үстерү буенча директоры **Артём Фокин**. – Иннополистагы машиналарны да кертеп, Мәскәү, Татарстан,

Израиль һәм АКШ ның берничә штаты юлларында без 150 ләп автомобильне сынийбыз. Алар 7 миллион чакрымнан артыграк юл үтте һәм зур зыян китерерлек бер генә һәлакәткә дә юлыкмады.

Мондый таксиларның бәясе дә көндәшлеккә сәләтле булырга тиеш. Берничә елдан соң пилотсыз автомобильнең бәясе шәхси кулланучы сатып алырлык дәрәҗәдә арзанаер, дип фаразлау өчен нигез бар.

– Бер ел элек «Яндекс» пилотсыз машинасы өчен асма (отвес) 400 мең $ булган. Хәзер ул 200 мең доллар тора. Технологияләр үсә, машинаның эче арзаная. Әлеге тренд дәвам итсә, тагын бер 4–5 елдан соң аның бәясе 5–10 мең долларга кадәр төшәр һәм мондый җиһазлы автомобильне гади кулланучы да сатып ала алыр, дип фаразларга мөмкин, – ди «Цифрлы транспорт һәм логистика» ассоциациясенең баш аналитигы **Андрей Ионин**. – Әмма шулай да миңа Кытай ягы фаразлаган вакыйгалар тизрәк чынга ашар кебек тоела.

Шунысы да игътибарга лаек: пилотсыз машиналар базары уенчылары мондый транспортны күбрәк шәхси түгел, бәлки җәмәгать транспорты сыйфатында күзаллый. Бу очракта киләчәк картинасы мондыйрак: клиент, А ноктасыннан Б ноктасына барыр өчен, төймәгә басып, үзенә кирәкле автомобильне чакыра. Аннары автомобиль башка заказны үтәргә китә. Клиентка парковка турында да, иминиятләштерү хакында да, машинаны карап тоту турында да кайгыртасы булмый.

– Пилотсыз машиналардан файдалану концепциясен без аларны хосусый затлар кулланырга тиеш, дип күзалламыйбыз әле. Теләгән һәркем шундый автомобиль сатып алачак һәм шунда йөриячәк, дип сөйләргә иртәрәк. Без такси, автобуслар, башка пассажир транспорты, йөк кучерүләр турында сөйлибез, ягъни аннан файдаланган өчен җавап тотучы юридик зат булырга тиеш. Ә физик затлар исә – аннан соңгы этап, аңа әле бик ерак, – ди «Яндекс»ның корпоратив мөнәсәбәтләр буенча директоры **Антон Шингарёв**.

ТАКСИ ЮЛГА ЧЫГАРГА ӘЗЕР

Югары автоматлаштырылган транспорт иминлеге Россиядә хәзер гамәлдә булган документлар белән дә (РФ Хөкүмәтенең 1415 нче карары, «АвтоНет» юл картасы, Гомумкуллану юлларында пилотсыз транспорт чаралары катнашында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү концепциясе), халыкара нормалар белән дә регламентлана. Әмма пилотсыз автомобиль катнашындагы юл-транспорт һәлакәте һәм башка хәлләр очрагында җаваплылык мәсьәләсе Россия законнарында да, халыкара кануннарда да ачык кала.

– АКШтагы инцидентны искә төшерик: 2018 елда пассажир урынында оператор утырган пилотсыз автомобиль җәяүленең гомерен өзгән иде. Штат прокуратурасына гаепләүне әзерләүгә ике ел вакыт кирәк булды, ул быел көз генә игълан ителде. Ике як та гаепле дип табылса да, операторга усал ниятсез үтерү өчен, 6 елга төрмәгә утыру куркынычы яный. Киләчәктә мондый очракларда зыянны кем капларга тиеш булачак? Бу транспортны уйлап табучылармы? Әмма андый практика юк. Аларның нәкъ менә кулланучы каршында җавапсызлыгы үзләренә шундый зур табыш китерә дә бит. Дәүләтме? Әмма дәүләтнең көйләү темплары технологияләр үсеше темпларыннан артта бара, – ди Андрей Ионин. – Җаваплылык каралмау – санлы трансформациянең барлык юнәлешләре өчен дә уртак проблема. Кара тартма, акыллы юллар һәм трафик белән идарә



итүнең дәүләт системасын булдыру зарурлыгы закон белән беркетелгәнче, автомобильдә руль бик озак кулланылачак әле.

Инцидентлар исә барыбер була тора. Форумда Россия ЭЭМ Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча Баш идарәсе башлыгы **Роман Мишуров** сөйләвенчә, 2018 елдан бирле Мәскәүдә пилотсыз автомобильләр катнашында 14 юл-транспорт һәлакәте теркәлгән, шулардан дүртесендә автоматлаштырылган транспорт чарасы гаепле. Бер кеше зыян күргән. Тикшеренүчеләр фикеренчә, мондый очраклар робот-пилотның кирәкле тәҗрибәсе булмау аркасында килеп чыга. Бу максаттан Иннополис юлда очрарга мөмкин хәлләрнең бихисап симуляторларын булдыра. Робот симуляторда өйрәнә, аннары белемен практикада куллана. «Яндекс»та исә пилотсыз машиналарга чын мисалларда өйрәнү яхшырак, дип саныйлар.

– Көйләү мөһим, әмма ул тыюлар һәм мәҗбүри тестлар сыйфатында түгел, бәлки гомуми киңәшләр сыйфатында формалаштырылырга тиеш, чөнки робот-йөртүчеләрнең хәзерге вакытка тупланган тәҗрибәсе теге яки бу кагыйдә һәм нормаларга тәңгәллекнең катгый критерийларын төгәл формалаштырыр өчен җитәрлек түгел, – дип саный Артём Фокин. – Алга китеш булсын өчен, безгә автомобильләрне юлга чыгарырга, технологиягә әнә шул тәҗрибәне тупларга мөмкинлек бирергә кирәк. Башта тармакны үстерү, аннары гына көйли башлау зарур.

Ничек кенә булмасын, пилотсыз транспорт тармагына кагылышлы норматив актлар эшләнә инде. РФ Президенты Владимир Путинның 2020 елның 1 апрелендәге боерыгы һәм РФ Хөкүмәте Рәисе Михаил Мишустинның Транспорт, Эчке эшләр, Сәнәгать һәм сәүдә, Икътисадый үсеш министрлыклары-на 2020 елның 10 апрелендәге күрсәтмәсе буенча, ведомстволар хәзер норматив-хокукый һәм техник көйләүне кайгырта, ул югары автоматлаштырылган транспорт чараларын илнең транспорт комплексына тизләштереп кертү нормаларының тиешле күләмен тәэмин итәчәк.

КИЛӘЧӘК ПРОЕКТЫ

Быел февральдә Татарстан парламентарийлары РФ Дәүләт Думасына «Инновацион транспорт чаралары турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон проектын тәкъдим иткән дә инде.

– Эксплуатацияләүче компанияләрнең операторы булырга һәм ул штаттан тыш хәл килеп чыккан очракта җаваплылыкны бүлешергә тиеш. Бөтенләй пилотсыз вариант – шактый ерак киләчәк эше әле. Әмма хәтта ул вакытта да билгеле бер диспетчерлык һәм машиналар тәртибен күзәтәчәк белгечләрне мониторинглау таләп ителәчәк, – дип саный закон проектын эшләүчеләрнең берсе, Татарстан Дәүләт Советы депутаты **Марат Галиев**. – Безнең карашка, күчеш чорында пилотсыз һәм пилотлы транспорт чараларының юлда бер үк вакытта булуы да кыенлык тудырачак. Бу очракта пилотсыз машиналарның аерым билгеләре булырга тиеш. Мондый нечкәлекләр бик күп. Мәсәлән, без киберкуркынычсызлыкны тәэмин итү маддәсен аерып куйдык. Боларның барысын да бүгенге техника дәрәҗәсендә ничек тормышка ашырып булуы – билгесез. Тулы масштаблы закон – бик күп профиль белгечләре өчен бурыч. Әмма норматив базаны инде хәзер үк әзерләп була.

КОРОНАВИРУСТАН ВАКЦИНА: БЕЗНЕҢ ВЕРСИЯ

Автор:
Әскар Сабиров

COVID-19 дәвереннән лайфхак. Чит илдә командировкада калган Казан тәрҗемәчесенә 500 доллар штраф түләтмәкче булганнар: кунакханәдә битлеген онытып калдырган өчен. Әмма ул бу хәлдән чыгу юлын тапкан: битен хатын-кызларның гигиена әйбере белән каплаган... Шәп бит? Ничек карыйсың инде. Сәламәтлегеңне куркыныч астына куюдан ни мәгънә? Бәлки, коронавирус йоктырмый калу әмәлен табаргадыр, яисә йоктыру куркынычын киметү буенча берәр идея тәкъдим итәргә?

Иллюстрацияләр: Александр Алёшин

Менә монысы турында уйлап карарга була, дип хәл итте «Татарстан». Һәм ковид куркынычы яный торган хәл-әхвәлләр турында сөйләргә алынды – ни дисәң дә, вакыт-вакыт һәркайсыбыз шундый вазгыятьтә кала. Сөйләргә генә түгел, вазгыятьне хәл итү буенча үз вариантыбызны тәкъдим итәргә дә булдык. Пандемия белән көрәш кысаларында югарыдан килгән күрсәтмәләр һәм оператив штаб әйткәннәр – яхшы анысы, әмма түбәннән килгән инициативаларның да яшәргә хокукы бар. Кайчак түбәннән яхшырак та күренә бит ул.

БУТАФОРИЯ ВАЗГЫЯТЕ

Казан янындагы Ореховка бистәсендәге азык-төлек кибетендә зур гипермаркеттагы кебек барысы да җитди: битлегең юк икән – сиңа бернәрсә дә сатмыйлар. Бәхеткә, битлеген өйдә онытып калдырганнарга һәм моңа җиңел караучыларга тугыз сумга битлек сатып алырга тәкъдим итәләр.

Төрле урында һәм төрле вакытта сатып алган битлекләрдән монысын сувенир итеп саклыйм: гадәти булмаганга. Ул бөтен килеш – хәтта бәйләп куя торган бауларына кадәр-юка гына кара төсле тупас тукымадан кайчы белән киселгән. Бендерның үлемсез «12 стульев» әсәрендәге гыйбарәне хәтерлисезме: «Гадәти малай. Аны кем малай, ди, шул беренче булып миңа таш атсын...» Чыннан да, кем аны битлек түгел, ди? Бернәрсәдән дә саклламый, әмма битлек түгел дип әйтеп булмый. Гадәти булмаган очракмы? Ашыкмагыз. Тикшереп карасаң, безнең илдә барыбыз да ковидка каршы торырлык дөрес битлек кияме соң? Нәтиҗәсе тынычландырырлык булмас. Чын медицина битлеге булган хәлдә дә, иманым камил, аны билгеле бер вакыт узуга, яңасына алыштырып тормыйлар. Кая инде берничә сәгать?! Метрода яки автобуста битлекләр картинасына сокланып барганда, кайберләрен күптән инде рекордлар китабына кертергә вакыт икәне аңлашыла: кесәдән ничә мәртәбә чыгарылганына карап... Ә бит андый озын гомерле битлекләр коронавирусның дошманы булудан бигрәк, дуслары булып чыга.

Нәрсә эшләргә?

Һәммә кешене «дөрес» битлекләр кияргә мәҗбүр итү һәм аларны даими рәвештә алыштырып торуларын таләп итү – файдасыз һәм тормышка ашырып булмастай гамәл. Барысын да контрольдә тоту мөмкин булмаганга гына түгел. Көн саен йөз сум акчаны битлеккә генә тоту (даруханәләрдә еш кына аларның бер данәсен егерме сумга саталар) кем өчендер бик кыйммәткә төшә.

Әгәр башка юлын тапсак? Күптән түгел җаваплы кешеләр дә катнашкан киңәшмәдә түбәндәге схеманы файдаландылар. Һәрбер чакырылган кешегә яңа битлек бирделәр, билгеле, сыйфатлыны, һәм нәкъ менә шунысын кияргә киңәш иттеләр. Ә хәзер күз алдына китереп карыйк: гипермаркетка, башкарма комитетка, театрга, дәваханәгә, цехка яки офислар үзегенә... ниһаять, битлек кию мәҗбүри булган урыннарга кергәндә, шулай эшләсәләр? Беренчедән, халыкны яхшы, бутафор булмаган битлек белән тәэмин итү эше җиңеләячәк, һәм инде берәү дә турникет аша авызын алкаларына канцелярия скрепкалары белән эләктереп куйган кулъяулык белән каплап узмаячак. Икенчедән, үзәкләштерелгән күпләп сатып алу битлекләрнең бәясен киметергә мөмкинлек бирәчәк.

Битлекләрне ничек таратырга – ниндидер бәягәме, әллә бушлаймы – бәхәсле мәсьәлә. Вариантлары күп. Кибетләрдә, мәсәлән, берәр нәрсә сатып ала икән, ул кешегә битлек бәясен кайтарырга мөмкин... Ә болай мин үзем бушлай тарату яклы. COVID-19дан шәхси саклану чаралары никадәр ышанычлы булса, эпидемиянең геометрик прогрессия буенча үсү шанслары да шуның кадәр азрак. Ә хәзер предприятие, офис һәм, ниһаять, җирле хакимият өчен нәрсә отышлырак булуын санагыз: хезмәткәрләргә, тулаем халыкка бушлай битлекләр өләшүме, әллә авыру китереп чыгарган чыгымнарны түләүме?



ВАЗГЫЯТЬ: ПИК СӘГАТЕ

Иртә. Эш көне башлана. Борынны битлек белән каплап, Киров районындагы тукталыштан 46 нчы маршрут автобусына утырам. Берничә тукталыш үтүгә, автобуста пассажирлар саны бермә-бер арта. Кешеләр битлеккә битлек тиярлек итеп басып баралар, социаль ара калдыру турында сүз дә була алмый. Янымда басып барган кешенең аягына басмагансың икән – анысы өчен рәхмәт. Салонда һава юк, мондый шартларда битлек белән авызны каплау да тын кысылуга китерә. Коронавирустан саклану турында сүз башлау мәгънәсезлек булып тоела. Җәмәгать, бу бит пик сәгате, башкача була да алмый. Арттан килгән икенче автобуста да шулай ук басып торырга да урын юктыр. COVID-19 өчен шыгрым тулы автобустан да уңайлырак тагын нинди шартлар була ала?

Нәрсә эшләргә

Маршрутка чыккан автобуслар санын арттыру мөмкин түгел, гәрчә аларның йөрү ешлыгына төзәтмәләр кертергә булса да. Тагын бер юл бар, аны элек кулланып караганнар иде. Үз вакытында Казанда төп күперләрнең берсе сафтан чыккач, шәһәр бөкеләрдә утыра башлады, һәм җирле хакимиятләр предприятиеләр белән эш көне башлану сәгатенә үзгәрешләр кертергә дип килештеләр: кайсыдыр эш көнен – җидедә, кайсыдыр – сигездә, кайсыдыр тугызда башлый иде... Гап-гади бит... Шул ук вакытта нәтиҗәсе дә бар: юлларда иркенрәк. Коронавирус очрагында исә мондый сыгылмалы график җәмәгать транспортында кешеләр санын киметер иде, һәм социаль ара калдыру хыялда гына түгел, чынбарлыкта мөмкин булыр иде.

Мәскәү тәҗрибәсен дә кулланырга мөмкин, билгеле, безнең җирлеккә яраштырып. Ишеткәнсездер инде, Мәскәүдә, чир йоктырмасыннар һәм өйдә калсыннар өчен, өлкәннәрнең ташламалы транспорт карталарын эшләүдән туктаттылар. Моны бездә дә эшләргә була, әмма гаделрәк итеп – юлга түләгән акчаларын кайтару шарты белән.

ВАЗГЫЯТЬ: ЭЛЕКТРИЧКА

Җомга киче. Казанның Төньяк вокзалы платформасында – алдан көтелгәнчә аншлаг: көн саен эштән өйләренә кайтып йөрүчеләр янына дачага баручылар да өстәлә. Кризислар һәм оптимизацияләр нәтиҗәсендә дүрт кенә вагонга калган электричкага (иркенрәк яшәгән елларда вагоннар саны ун була иде) пассажирлар күз ачып йомган арада кереп тула. Дөрес, уртада басып баручылар юк диярлек, әмма утыргычлар төчкерә, борын тарта торган халык белән шыплап тулган – һәр «купе»да алтышар кеше. Өчәү бер якта иңгә иң куеп утыра, өчәү – каршыда. Күршеңнең йогышлы авырулы булу ихтималы турында уйлаган саен язгы карантин чоры сагындыра – ул вакытта вагоннар ярым буш йөргән иде. Дөрес, шул сәбәпле, электричкалар саны да бик азга гына калган иде. Үз чиратында, Юдино бистәсе ягына бара торган автобуслар туп-тулы йөри башлады.

Нәрсә эшләргә

Шәһәр янына йөри торган электричкаларга ике-дүрт вагон өстәргә була – моның әллә ни кыенлыгы юк. Аңлашыла ки, компания-оператор өчен табышлы вариант түгел: өстәмә вагоннар – өстәмә чыгымнар. Ләкин ничек хәл итәбез соң: барысын да ничек бар, шулай калдырабыз да, вируска чәчәк ату мөмкинлеге бирәбез (ул чагында пассажирлар саны ягыннан язгы вазгыять кабатлану ихтималы зурая), яки инде – акыл белән уйлап эш итәбез дә тиешенчә социаль ара калдыруны тәэмин итәбез һәм вируслы кеше белән аралашу хәтәрен киметәбез.

ВАЗГЫЯТЬ: АЭРОПОРТ

Казан аэропорты терминалы. Теркәлгәч һәм махсус контроль узгач, мәгълүм лоукостер рейсы белән очучы пассажирлар кысан һәм тынчу залда самолетка утырту башланганны көтәргә мәҗбүр булалар – ул каядыр кырык минут. Социаль ара калдыру турында онытырга туры килә – биредә тамашачылар рәтләрне һәм трибуналарны яртылаш кына тутырырга хокуклы булган театр да, стадион да түгел. Биредә буш урыннар булмый диярлек, бәләкәй генә кафедагага яки, гафу итегез, бәдрәфкә булган чиратка караганда, халыкның ни дәрәҗәдә күплеген чамаларга була.

? Нәрсә эшләргә

Казанның хәзерге аэропортында пассажирлар арасында тиешле ара калдыру мөмкинлеге бирә торган заллар җитәрлек. Әмма аларның һәркайсы сәяхәтчеләрнең төркемнәренә карап билгеләнгән: берсе халыкара рейсларга оча торган пассажирлар өчен, икенчесе – ВИП-клиентларга, тагын берсе – эчке рейслар өчен... Лоукостерлар пассажирларының, табигый ки, билетлары бәясенә карап, көтү залы да арзанлы. Ә нигә әле стереотипларны вакытлыча гына булса да җимереп, пассажирларны иркенрәк залларда көттермәскә һәм шул рәвешле ковид йоктыру ихтималын киметмәскә? Өстәвенә, халыкара сектор бүген элекке елларга караганда, билгеле сәбәпләр аркасында, күпкә бушрак. Табигый, бу өстәмә чыгымнар һәм оештыруны таләп итә. Әмма вазгыятьнең гадәттән тыш катлаулылыгы үз кагыйдәләрен урнаштыра. Әлеге дә баягы, өстәмә тырышлыклар һәм чыгымнар бүген булса, иртәгә пандемия таралу аркасында авиаочышларсыз калмабыз.

ВАЗГЫЯТЬ: ТЕРЕ АКЧА

Кайчак алар миңа куркыныч төш булып керә. Микроблар мыжлап торган, вак акчаны өзлексез санаудан бармаклары кара төскә кергән резин перчаткалар. Шундый перчатка кигән куллары белән кондуктор миңа электричкада вак акча кайтарып бирде, шулар белән билет өзеп тоттырды.

Барысы да мин кыюсыз рәвештә генә пластик карта белән түләмәкче булгач башланды.

– Бары тик тере акча гына! – Кондуктор битлеге астыннан әдәпсез рәвештә йөткереп, шулай дип җавап бирде. Һәм минем күзләрдәге сорау билгеләрен укып өстәп куйды:

– Сорауларыгыз булса, җитәкчелеккә...

Казанга кадәр юл буена мин кесәмә кергән вак акчалар аша, әгәр алар ике-өч авыру кулы аша үткән булса, чир йоктыру ихтималы нинди дип санап кайттым...

? Нәрсә эшләргә

Пандемия вакытында тере акча әйләнешен бөтенләй үк тыю мөмкин түгел икән, банк карталары белән түләү мөмкин булган һәр җирдә ул мөмкинлектән файдалану өчен шартлар тудырырга кирәк. Техник мөмкинлекләргә сылтамалар урынлы түгелдер. Һәрхәлдә, хәтта базарда валидаторсыз гына сату итүчеләрнең дә күпчелеге бу хәлдән чыгу юлын тапты – акчаны үзләренең карталарына күчерергә тәкъдим итәләр...

ВАЗГЫЯТЬ: ДӘВАХАНӘ

Дәүләт И., 35 яшь. Казанда яши. Авыруның беренче билгеләре сизелә башлауга ул, ни кызганыч, аның яшендәге барлык ирләр кебек үк аларны җитди кабул итмәгән. Бары тик өч көннән соң температурасы 38,5 тән югары күтәрелгәч кенә, өенә табиб чакырган. Күрәсең, табибның да саграк кылана торганы эләккән – килмәгән. Тагын бер атна узгач, авыруның хәле бик мөшкелләнгәч, өйдәгеләре тагын бер тапкыр дәваханәгә мөрәҗәгать иткән.

Регистратурада табибның килмәвен белгәч, чын мәгънәсендә: «Ә бездән нәрсә телисез?» – дип гаҗәпләнгәннәр. «Кеше үлеп китсә, кем җавап бирәчәк, шуны беләсебез килә...» – дигәч кенә, хәлгә кергәннәр.

Дәүләтне коткарып калганнар. Ашыгыч ярдәм килгәндә, ул инде үзе сулый алмаган – шунда ук кислород биргәннәр. Ике атна «кызыл зона»да ятканнан соң, дәваханәдән 45 процент үпкәсен югалтып чыккан, әмма үзләрен аямыйча авырулар янында булган табибларга рәхмәте чиксез аның.

Безне ковидтан коткару өчен тырыша торган табиблар – чын каһарманнар. Әмма медицина да тормыш кебек – каһарманнардан гына тормый. Табибларның яхшылары бар, бик үк яхшы булмаганнары да. Бик үк яхшы булмаганнары кинәт кенә яхшырып китми инде. Һәм кырыс тормыш чынбарлыгы бар: табиблар җитми, коронавирус турында төрлесен ишетеп, коты алынган халыкның, төчкерсә дә, дәваханәгә йөгерә торганы бар. Нәтиҗәдә дәваханәләрдә чиратлар – анда исә чир йоктыру куркынычы зур, һәм өйгә табиб килсен әле дигәнгә, үзегез дәваханәгә килегез, чакыручылар болай да күп, дигән сәер киңәшләр.

Нәрсә эшләргә

Татарстан – бик күп алдынгы цифрлы технологияләр пилот режимында сынау уза торган төбәк. Бездә, мәсәлән, телемедицина ярдәмендә күптәннән һәм уңышлы рәвештә диагнозлар куялар, хәтта операцияләр ясыйлар. Әгәр кайсыдыр бер ерак районда катлаулы очрак икән, җирле хирурглар, Казан белән элемтәгә кереп, республика клиник дәваханәсенең тәҗрибәле белгечләре җитәкчелегендә операция үткәрәләр һәм алар уңышлы килеп чыга. Әмма бездәге телемедицина үзәге – ни әйтсәң дә, гадәттән тыш очраклар өчен. Ә участок табибына эре шәһәрләрдә, сыйфатлы интернет-компьютер, смартфон булган җирләрдә пациентлары белән онлайн-консультация үткәрергә нәрсә комачаулый? Бүгенге көндә техник яктан моны әллә ни катлаулы эш, дип уйламыйм. Сүз, табигый ки, табибның пациент белән күзгә-күз бөтенләй аралашмавы турында бармый. Гадәти салкын тигәнгә диагноз кую өчен – ә алар күпчелек – тәҗрибәле табибка онлайн элемтәгә чыгу да җитә. Нәтиҗәдә бу нәрсә бирә? Дәваханәләрдә чиратлар кыскара, табибларның эше азая (алар бүген алсыз-ялсыз эшли), һәм аларның коронавирус йоктыру куркынычы кими (ковид йоктыру куркынычы астында аларның һәрбер пациентның өенә барасы килеп тормыйдыр).

Сүз уңаеннан әйткәндә, табибларның онлайн-элемтә аша консультацияләр бирүе безнең генә фантазия түгел. Якутиядә, мәсәлән, авыруларны онлайн кабул итү – чынбарлык. Коронавирус аркасында пациентларның кинәт артуы һәм табибларны өйгә чакырту кинәт арткач, алар яз көне үк пациентларны онлайн кабул итү буенча технологияләр эшләргә мәҗбүр булган. 1 июньгә әлеге бурыч хәл ителгән дә. Бүген дәваханәгә «барып кайту» өчен шәһәр кешесенә яки еракта гы көтүлектән болан караучыга смартфон куллану да җитә. Димәк ки, бу җәһәттән без планетада иң беренчеләр рәтендә түгел. Шулай да вазгыятьне үзгәртү шансы бар. Татарстанда эшләнгән цифрлы ресурслар белән таулар күчереп була. Өстәвенә, коронавирус барыбызны да гадәти булмаган юллар табарга, моңа кадәр башкарып чыга алмастай тоелган бурычларны да хәл итәргә мәҗбүр итә.

P.S.

Татарстанның «XXI гасыр чумасы» белән көрәштә куйган тырышлыклары Россиянең күп төбәкләре өчен үрнәк булып тора. Кайбер төбәкләрдә вирусның таралуын бездәге кебек нәтиҗәле итеп туктарлый алмыйлар. Әмма яхшы итеп эшләп булганны да яхшыртырга урын бар. Материалдагы вазгыятьләр чын: автор, хезмәттәшләр, укучыларыбыз барысын да үз тәҗрибәсеннән чыгып сөйләде. «Татарстан»ның максаты – югарыда билгеләнгән проблемаларга тиешле ведомстволарның һәм предприятиеләрнең игътибарын юнәлтү. Һәм, билгеле, җаваплы кешеләрдән конструктив эшләр белән ныгытылган төгәл җаваплар алу.

Һәм, әйдәгез, иң мөһимен дә онытмыйк: ковид кебек көчле һәм мәкерле дошман белән көрәштә вакланырга ярамый, чыгымнарны һәм тырышлыкларны экономияләү бик сирәк очракта аклана. Кеше гомере һәм сәламәтлеге – ярым-йорты чаралар һәм кул кушырып утырган өчен артыгы белән зур бәя.



Гомәр Яруллин, Татнефть Профсоюз рәисе.

«Татнефть» җитештерү берләшмәсенең профсоюз оешмасы 1985 елның 27 июнендә сәнәгать һәм төзелештәге нефть, газ тармаклары хезмәткәрләренең Татарстан өлкә комитеты профсоюзлары составында төзелә. Ул вакытта аны Александр Юхимец җитәкли. 1989 елда профком рәисе итеп Марат Мәһдиев сайлана. 1992 елда беренче тапкыр «Татнефть» җитештерү берләшмәсенең бердәм коллектив килешүе имзалана. 2000 елдан бирле коллектив «Татнефть» профкомы белән җитәкчелек итүне Гомәр Яруллинга ышанып тапшыра. Бүген Татнефть Профсоюз 140 мең әгъзаны берләштерә.

ЗАКОН ҮТӘЛЕШЕ САГЫНДА

Төзелеш һәм сәнәгатьнең нефть, газ тармаклары хезмәткәрләренең гомумроссия профессиональ союзының «Татнефть Профсоюз» Төбәкара профсоюз оешмасы 35 еллык тарихка ия. Ул Татарстанда иң зур профсоюз оешмаларының берсе.

Татнефть Профсоюз рәисе Гомәр Яруллин «Татарстан» журналына нефтьчеләр профсоюзының бүген нинди бурычларны хәл итүе хакында сөйләде.

– Гомәр Кәримович, шундый бай тарихлы булу яхшы әлбәттә, әмма Татнефть Профсоюз оешмасының бүгенге көндәге эшләре һәм борчулары да бар бит...

– Әүвәлгечә үк, аларның иң мөһиме – нефтьчеләр мәнфәгатьләрен социаль-икътисадый яклау, хезмәтне саклау, хокукый яклау, ял, сәламәтләндерү һәм җитештерү процессларының тотрыклылыгы. Иң мөһим локаль акт, аларны гамәлгә кертүнең базисы – Коллектив килешүе, ул профсоюз әгъзасы булган хезмәткәрләрне нәтиҗәле, бер команда булып эшләргә мәҗбүр итә; шул чакта хезмәт җитештерүчәнлеге арта, көндәшлеккә сәләтлелек көчәя, димәк, компания хезмәткәрләренең дә, пенсионерлар һәм профильле уку йортлары студентларының да тулаем социаль яклануы арта. Бу – төрле тормыш хәлләрендә матди ярдәм, сыйфатлы медицина хезмәте күрсәтүгә булышу, гаилә ялын оештыру, ипотека торагын гадел бүлүне контрольдә тоту, хезмәткәрләрнең ялын һәм сәламәтләндерүне булдыру, балалар сәламәтләндерү лагерьларындагы ялны хәстәрләү, эшләмәүче профсоюз әгъзаларының пенсия белән тәэмин ителешен кайгырту, хезмәткәрләр һәм пенсионерларның, аларның гаилә әгъзаларының социаль якланганлыгы мәсьәләләрен хәл итү.

Бездә профсоюз әгъзаларын хокукый яклау буенча комиссия эшли, ай саен күчмә юридик консультацияләр уздырыла. Эшнең мондый формасы нефтьчеләргә хокукый ярдәмне аларны эштән аермыйча гына күрсәтү мөмкинлеген бирә. Кабул итү нәтиҗәләре буенча тиешле инстанцияләргә, эш бирүчеләргә хатлар җибәрелә, консультатив һәм гамәли ярдәм күрсәтелә.

– Нефть тармагында эшләү күтәренке физик йөкләмәләр, һөнәри авырулар һәм имгәнүләр белән бәйле. Татнефть Профсоюз хезмәтне саклау җәһәтеннән нинди эш алып бара?

– Хезмәткәрләрнең сәламәтлеген саклауны без үзебез генә дә, һәм хәтта хакимият белән бергәләп тә, хәл итә алмыйбыз. Әлеге эш хезмәтне саклау белгечләре белән безнең, һәм, әлбәттә инде, хезмәткәрләрнең үзләренең уртак гамәлләрен таләп итә. Профком әлеге вазыйфаны башкара алсын өчен, эш урыннарында хезмәтне саклау буенча 2,5 мең профсоюз вәкиле сайланган. Россия «Нефтегазстройпрофсоюз» оешмасының баш техник инспекторы безнең штаттагы хезмәткәр булып тора, ул, оешмаларны, җитештерүләрне, цехларны һәм эш урыннарын тикшерү юлы белән, хезмәт шартларын һәм аны саклауның торышын җәмәгать контролендә тота.

Бүген компаниядә «Шок үзәкләре» актив оештырыла, әлеге үзенчәлекле тренажерлар сәнәгать куркынычсызлыгы һәм хезмәтне саклау кагыйдәләрен бозган очракта хезмәткәргә нинди имгәнүләр янавын бик ачык күрсәтә. Мәсәлән, теләүчеләр минималь бәрелешү көчендәге юл-транспорт һәлакәте моделен үзләрендә сынап карый ала. Ышаныгыз, бу инструктаж һәм теорияләргә караганда көчлерәк тәэсир итә!

Предприятиеләрдәге профком рәисләре шок-тренажерлы әлеге үзәкләр үсешенә актив булыша.

Шулай ук хезмәтне саклау буенча вәкилләр белән эш алып барыла, алар уку үзәкләрендә профильле программалар буенча укытыла. Ел саен «Хезмәтне саклау буенча иң яхшы вәкилне» ачыклау бәйгесен үткәрәбез.

– Торак мәсьәләсе һәрвакыт һәм һәркайда катлаулы. Нефтьчеләр аны ничек хәл итә?

– Хезмәткәрләренә торак шартларын яхшыртуда ярдәм күрсәтү – «Татнефть» социаль сәясәтенең мөһим юнәлешләреннән берсе.

2005 елдан башлап «Татнефть» компаниясе хезмәткәрләренең торак мәсьәләләре республикадагы социаль ипотека программасы буенча хәл ителә. «Татнефть» компаниясе Татарстан Республикасында социаль ипотека буенча торак төзелеше программасының актив катнашучысы һәм төп түләүчесе булып тора.

2005 елдан 2020 елга кадәр (быелны да кертеп) нефть төбәге шәһәр һәм бистәләрендә, ипотека төзелеше программасы кысаларында, гомуми мәйданы 860,58 мең квадрат метрга тәңгәл 117 торак йорт (12 796 фатир) һәм 40 хосусый йорт төзелгән һәм файдалануга тапшырылган.

Югарыда күрсәтелгән чорда структура бүлекчәләре хезмәткәрләре өчен «Татнефть» 1,8 миллиард сум беренчел кертем түләгән. Әлеге торакның 30 проценттан артыгы яшь гаиләләргә бүленгән.

Социаль ипотека программасы буенча торак алырга теләүчеләрнең тулаем саны 2020 елның 1 июленә 4 450 кешене тәшкил иткән. Татнефть Профсоюз социаль ипотека төркеме белгечләре һәм предприятиеләрнең беренчел профоешма хезмәткәрләре әлеге программада катнашучыларның исәбен алып бара, ипотека торагын бүлүдә катнаша. Аңлатуны сорап һәркемнең профкомга мөрәҗәгать итәргә хокукы бар. Белгечләр киңәш бирә, аларның мөрәҗәгатьләрен җавапсыз калдырмый. Мондый тере аралашу ике як өчен дә файдалы.

– Татнефть Профсоюз якын киләчәктә нинди бурычларны хәл итәргә җыена?

– Татнефть Профсоюз командасы өчен безнең эшебез беркайчан да ялыктыргыч булмады. Биредә, социаль-икътисадый аспектлардан тыш, спорт-сәламәтләндерү һәм мәдәният эшчәнлеге, ветераннарны кайгырту һәм профсоюз активын укыту, мәгълүмати эш, яшьләр сәясәтен гамәлгә кертүдә ярдәм. Катлаулы эпидемиологик вазгыять эшне киметүгә сәбәп була алмый, киресенчә, аны көчәйтергә кирәк. Без яңа электрон платформа булдырырга ниятлибез, ул профсоюз әгъзалары белән сыйфатлы кире элемтә урнаштырырга, профсоюз әгъзаларын исәпкә алуны санлаштырырга тиеш. Үткән 35 елдагы кебек үк, профсоюз нефтьчеләрнең социаль гарантияләрен тәэмин итүдә, аларның хокукларын яклауда иң мөһим роль уйнарга бурычлы.

Фотолар «Татнефть» матбугат хезмәтеннән алынды

СТРАТЕГИЯ – МИЛЛИ, СҮЗЛӘРЕ – ХАЛЫКНЫКЫ...

Татар халкының үсеш стратегиясе кабул ителде. Шуңа бәйле рәвештә, халыкның кайбер танылган һәм атказанган вәкилләре кызыксына башлады: әлеге стратегик документның авторы кем соң? Нәкъ менә шул сорауга җавап эзләп, без Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров белән әңгәмә кордык.

Ниндидер бер вакыйга уңаеннан татар җәмәгатьчелегенең күптән болай кызып-кызып, кайвакыт исә ярсып та, бәхәсләшкәне юк иде инде. Мондый диспутларның кабынуына исә Бөтендөнья татар конгрессының Милләт җыены сәбәп булды, анда катнашучылар август азагында, нәкъ Республика көне алдыннан, Татар халкының үсеш стратегиясен кабул итте. Ул халыкка игълан ителгәч үк, төрле фикерләр яңгырый башлады – яңа туган документны күккә чөеп мактаучылар да, тәнкыйть утына тотучылар да шактый иде. Янәсе, күпме көттек, нәтиҗәдә исә нәрсә килеп чыкты... Стратегияне чыннан да бик озак көттек. Бүген ул языла башлаганга инде ике елдан артты – аны эшләргә ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов ТР Дәүләт Советына юлламасында әллә кайчан старт биргән иде. Шул вакыт эчендә без баштарак әкренләп гомуми контурлар, аннары тәфсилләрәк эскизлар һәм кайбер әчтәлекле элементлар тоемлана башлануына шаһит булдык. Әмма күп кенә галимнәр һәм җәмәгать активистлары яңа гына табадан төшкән Стратегиядә үз фикерләренең бөтенләй исәпкә алынмавына аптырады. Нәкъ менә шушы Стратегиянең никадәр «стратегик» һәм эшкә яраклы булуы хакындагы дискуссия башланыр өчен сылтауга әйләнде дә. Сылтауга, әмма сәбәпкә түгел, чөнки татар халкы алдында торган реаль проблемалар, аларның өстенлеге һәм аларны хәл итү ысуллары турында төрле күзаллау гына сәбәп була ала.

Бүген Стратегиягә үзенең карашын Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе итеп әлеге вазыйфага сентябрь азагында гына билгеләнгән Данис Шакиров белдерә. Безнең әңгәмәдәшебез Конгресста яңа кеше түгел, соңгы елларда ул БТК Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары булып эшләде, шунлыктан үз эшчәнлегенә даирәсен яхшы белә һәм татар конгрессының Стратегия буенча рәсми позициясен дәлилләп аңлата ала.

– Иң әүвәл Сезнең БТК Башкарма комитеты җитәкчесе итеп билгеләнүегез уңаеннан котлауларыбызны кабул итегез. Сезнеңчә, Башкарма комитет эшендә нәрсәне үзгәртергә, нәрсәне исә саклап калырга кирәк?

– Минем тормышымның шактый өлеше Бөтендөнья татар конгрессы белән бәйле, мин биредә инде дистә елдан артык эшлим. Иң түбәннән, референт вазыйфасыннан башлаган идем. Шунлыктан, әлбәттә, ниндидер тупланган тәҗрибә, конгрессның Башкарма комитеты каршында торган мәсьәләләрне аңлау бар.囗Эштә булган тәртипне сакларга кирәк, дип уйлыйм. Бу мөһим. Минем шигарем – халкыма хезмәт итү!

– Татар халкының үсеш стратегиясе шактый озак вакыт дәвамында әзерләнсә дә, хәзерге документны БТК Милли шурасы тиз арада кабул итте, һәм киң җәмәгатьчелек аның белән шуннан соң гына таныша алды. Стратегиянең әлеге редакциясен кем әзерләде?

– Стратегияне әзерли торган төп экспертлар төркеменә фәнни интеллигенция вәкилләре, татар җәмәгать эшлеклеләре, ТР министрлык һәм ведомстволарының хезмәткәрләре керде. Стратегия БТК берләштергән татар иҗтимагый оешмаларының тәкъдимнәрен исәпкә алып кабул ителде. Стратегияне эшләү үзәге, җаваплылык үзәге, әлбәттә, Казанда иде.

Стратегияне әзерләү – бер көнлек кенә эш түгел. Гаять зур конструктив һәм системалы эш алып барылды. Стратегиянең эскизы Милли шура утырышында тикшерелде.

Мондый документны кабул итүнең зарурлыгы турында беренче булып Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов белдергән иде: бу турыда ул үзенең ТР Дәүләт Советына юлламасында 2018 елның 24 сентябрендә сүз кузгатты һәм җаваплылык үзәге итеп Бөтендөнья татар конгрессын билгеләде. Президент әйтеп үткәнчә, стратегия һичшиксез милләтне берләштерә торган документ булырга тиеш. Ел ярым дәвамында

без республика районнарында, РФ федераль округларында әллә никадәр киңәшмә һәм түгәрәк өстәл уздырдык, аларда стратегия эскизының контурлары һәм төп принциплары тикшерелде. Стратегия проектына кадәр аның эскизы әзерләнде, аннары ул, безнең барлык татар иҗтимагый оешмалары тәкъдимнәрен исәпкә алып, тулыландырылды һәм баетылды.

– Кайвакыт мондый шелтә ишетергә мөмкин: ике елга сузылган шундый интенсив эш нәтиҗәсе булган Стратегия нигәдер нибары берничә биткә генә сыеп беткән.

– Бу нигезсез үпкәләр. Иманым камил, мондый төп документ берничек тә 500–600 битле була алмый. Кайберәүләр бик мөһим моментны истән чыгара – Стратегияне шундый ук бурычларны хәл итүгә юнәлтелгән башка концепцияләрдән һәм дәүләт программаларыннан аерып карарга ярамый бит. Бу инде гамәлгә кертелә торган документлар комплексы. Тәфсилләбрәк аңлатам хәзер.

Стратегия белән бергә «Гамәл стратегиясен тормышка ашыру эшчәнлегенең төп юнәлешләре» документы һәм 2020–2023 нче елларга «Татар халкының милли тәңгәллеген саклап калу» дәүләт программасы да кабул ителде. Аларны гамәлгә кертүгә 2023 елга кадәр 400 миллион сум акча бүлү күздә тотыла. Моннан тыш, безнең ана телләрен саклау һәм үстерү буенча дәүләт программасы да гамәлдә. Шунлыктан Стратегияне гамәлгә кертүнең барышын һәм перспективаларын инде гамәлдәге дәүләт программалары белән комплекста карарга кирәк.

Стратегияне гамәлгә кертү – безнең уртак эшебез, бөтен халыкның уртак бурычы. Инде бүген үк күп нәрсә эшләнгән һәм эшләнә. БТК даими рәвештә бик күп чаралар үткәрә, мәсәлән, Татар авыллары эшкуарлары җыены, татар яшьләре, татар хатын-кызлары, дин әһелләре, укытучылары, төбәкне өйрәнүчеләре һ.б. Бөтендөнья форумнары. Әлеге форумнарга ниндидер мөһим мәсьәләләрне тикшерер өчен җыйналалар. Нәкъ менә алар барышында һәм алар нәтиҗәсендә тулы бер хәрәкәтләр формалаша. Шул рәвешле, Стратегиянең юнәлешләре татар халкының төрле категорияләре катнашында гамәлгә ашырыла.

– Татар телен өйрәнү мәсьәләсе – иң авыр мәсьәләләрдән берсе. Бу эштә халыкның үзаңына гына исәп тотарга ярыймы? Яки, бернигә карамастан, милли мәгариф системасын булдыру зарурмы? Аның зарурлыгы турында да еш сөйлиләр.

– Туган телне саклау һәм үстерү – безнең уртак бурычыбыз. Әмма һәркем үзеннән башларга һәм үзенең шәхси җаваплылыгын тоярга тиеш. Үз телен саклаган халык кына хөрмәткә лаек. Бу өлкәдә бик күп нәрсә халыкның үзаңына, безнең бөек тарихыбызны ничек белүенә бәйле. Ана телен популярлаштыру – һәркемнең бурычы.

Бүген «Ана теле» сайты эшли. Башка бер генә милли республикада да мондый программа юк. Программа «English first» платформасында булдырылган. Анда тугыз дәрәҗә бар. Теләгән һәркем сайтта теркәлә һәм Җир шарының теләсә кайсы почмагыннан теләсә кайсы вакытта шөгыльләнә ала.

Татар теленең кызыклылыгын арттыру, җәмәгать тормышының төрле тармакларында, икътисадта, фәндә һ.б. аннан файдалану даирәсен киңәйтү БТК эшендә өстенлекле юнәлеш булып тора. Шунлыктан, сүз дә юк, өзлексез милли белем бирү системасын формалаштырыга булышырга кирәк. Барлык дәресләр дә татар телендә генә укытылган мәктәпләр бар, һәм бу анда укучыларның БДИ бирүгә әзерлегенә берничек тә комачауламый. Татар мәктәпләрен тәмамлап, максималь балл җыючыларга мисалларыбыз җитәрлек.

– Стратегия белән беррәттән, документны гамәлгә кертү буенча эшчәнлек юнәлешләре исемлеге дә кабул ителгән. БТК эшнең практикада ничек оештырыласын аңлыймы: конкрет пунктларны гамәлгә кертү өчен җаваплы структураларны күрсәтү, тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларын булдыру, куелган бурычларга ирешү күрсәткечләрен билгеләү планлаштырыламы?

– Стратегияне гамәлгә кертү – БТК эше генә түгел. Әйе, конгресс – әлеге процесста төп катнашучылардан берсе, әмма бердәнбер түгел. Бу – комплеслы бурыч. Мин алдарак әйтеп киттем бит инде – республикада татар халкының мәдәниятен һәм телен саклау һәм үстерүгә юнәлтелгән ике дәүләт программасы гамәлдә. ТР милли сәясәте программасы бар. Әлеге программаларда барысы да – җаваплылар да, үтәлү вакыты да – күрсәтелгән.

Без үзебезнең бөтен мөмкинлекләрне тулы куәтенә файдаланырга омтылабыз. 2017 елда БТК Милли шурасы рәисе итеп ТР премьер-министры урынбасары Васил Габделгаяз улы Шәйхразиев билгеләнде. Җитәкчебезнең югары статусы безгә актуаль мәсьәләләрне РФ төбәкләре башлыклары дәрәҗәсендә күтәрү һәм аралашу, чит ил вәкилләре белән очрашу һәм нәтиҗәле диалог алып бару мөмкинлеген бирә. Конгресс җитәкчесенең статусы БТК ның тулаем мөмкинлекләрен дә объектив арттыра.

Татар җәмгыяте үсә, аның алга баруы беркайчан да туктамый. Шунлыктан без хәзер кабул ителгән Стратегиягә дә вакыт үтү белән төзәтмәләр кертелүгә әзер. Иң мөһиме – бергә эшләү, шул чакта барысы да уңышлы булачак.

Нияз Әхмәдуллин әзерләде

ТАТАРНЫҢ КИЛӘЧӘГЕН БИЛГЕЛӘҮЧЕ МӨҺИМ ДОКУМЕНТ

Автор: Фаяз Хуҗин

Татар халкының киләчәге турында уйланулар-фаразлар, галимголәмә арасында җитди сөйләшүләр, оптимистик һәм пессимистик рухта алып барылган бәхәсләр беркайчан да тынып тормады. Мәгълүм ки, 1552 елгы фаҗигале вакыйгалардан соң ук татарлар, үзләре төзегән мөстәкыйль дәүләтләрдә торып яшәргә өйрәнгән ирек сөючән каһарман бабаларыбыз, азатлык сугышына күтәрелә, аннан соңгы ике гасыр буена Степан Разин, Емельян Пугачев җитәкчелегендәге крестьян сугышларында, Җангали Шөгеров (1616–1619), Теләкәй батыр (1682), аның улы Күчем Теләкәев һәм Алдар Исәкәев (1707–1711), Акай һәм Габдулла Күчемовлар (1735–1738), халык арасында Батырша исеме белән танылган Габдулла Галиев (1755) күтәргән фетнәләрдә катнашып, йә Болгар дәүләтен, йә Казан ханлыгын яңадан торгызу өчен, гасырлар буена калыплашкан традицион яшәү рәвешен, диненмәдәниятен, ахыр чиктә милләтен саклап калу өчен көрәшә.

ДУСЛЫК – ТИГЕЗЛЕК, ДИГӘН СҮЗ

Халкыбызның киләчәктәге язмышы мәсьәләсе алдынгы карашлы татар зыялылары тарафыннан XX йөз башларында да бөтен кискенлеге белән күтәрелә. Гаяз Исхакыйның татар иҗтимагый һәм әдәби тормышында зур вакыйга булып торган «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәре – моның ачык мисалы.

Дәүләтчелегебезне яңадан торгызу турындагы изге хыял 1920 елның 27 маенда тормышка ашырыла: Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты тарафыннан Россия Социалистик Федератив Советлар Республикасы (РСФСР) составында «Автономияле Татар Социалистик Совет Республикасын (АТССР) төзү турында Нигезләмә»гә кул куела.

Әлеге тарихи вакыйгадан соң нәкъ җитмеш ел үткәч, 1990 елның 30 августында, ТАССР Югары Советы сессиясендә республикабыз суверенитеты турыда Декларация кабул ителә. Суверенитет кысаларында Татарстан Республикасы Россия Федерациясе составындагы иң алдынгы, икътисады һәм мәдәнияте иң югары үскән төбәкләрнең берсенә әверелде. Уңышларның нигезендә күпмилләтле дәүләтчелек үсешенең бай тарихы-тәҗрибәсе, гасырлар буена дәүләтчелек идеяләре белән сугарылып калыплашкан милли аң, азатлык өчен көрәштә һәм тыныч хезмәттә сыналган батырлык һәм фидакарьлек ята иде.

Кызганыч ки, соңгы йөз елны эченә алган тарих милләтебез үсешендәге тискәре якларны да ачып салды: баксаң, интернационализм идеяләре белән сугарылган идеология һәм нык үскән икътисад кына халыкларны милләт буларак үз йөзләрен саклап калуны тәэмин итә алмый икән. Күпмилләтле илдә яшәгәч, халыклар дуслыгы турында кайгырту, сүз дә юк, кирәк, әлбәттә. Әмма дуслык тигезлекне таләп итә. Борын-борыннан шулай килә инде ул кешелек җәмгыятендә: олы туган кечесенә карата игътибарлырак, кайгыртучанрак була. Бездә башкачарак килеп чыкты. Башта гарәп һәм латин графикаларын рус кириллицасына күчереп, безне меңьеллык язма мирасыбыздан мәхрүм иттеләр, соңрак, нык үскән социализм төзү елларында, татар мәктәпләрен дә яба башладылар. Дөрес, суверенлык елларында татар мәгарифендә бераз җанлану булып алды, әмма милләтебезне сәламәтләндерүдә үзгәреш җилләренең шифасы ул кадәр сизелмәде шул. Киресенчә – күпме фаҗигаләр кичереп төзегән һәм инде яшәү рәвешенә әверелгән колхозларны җимереп ташлау авылларыбызны да юк итүгә этәрде. Авыл беткәч, мәктәбе дә бетә инде аның. Ә бит авыл халкы – милли мирасыбызны, аерым алганда, туган телебезне, моңыбызны, йолаларыбызны, гореф-гадәтләребезне саклаучылар алар. Әйе, башлыча авыл халкы исәбенә үсте безнең әдәбиятыбыз, сәнгатебез, гуманитар фәннәребез.

2000 нче еллар башыннан Россиядә милли проблемаларга игътибар нык кимеде. Моны үз күзләребез белән күреп торабыз: Татарстаннан читтә яшәүче татарлар 1990 нчы елларда ачылган мәктәп-гимназияләрен ябарга мәҗбүр ителделәр; урта мәктәпнең уку-укыту программаларыннан «милли-төбәк компоненты» төшенчәсе алып ташланды, ягъни төбәк тарихын (бездә «Татарстан һәм татар халкы тарихы»н) һәм туган телне укыту федераль кануннар нигезендә тыелды; 11 нче сыйныфны тәмамлаганнан соң бердәм дәүләт имтиханнарын бары тик рус телендә генә тапшыру рөхсәт ителә. Соңгы таләп исә авылларда сакланып калган татар мәктәпләрендә дә имтихан бирәсе фәннәрне рус телендә укытырга мәҗбүр итә. Әйе, балаларыбыз русча әйбәт сөйләшә, әмма ана телен оныта бара. Объектив статистика мәгълүматларына караганда, Татарстанда яшәүче 2,1 миллион татар кешесенең 1,5 миллионы үз телендә аралашмый. Ана телен оныткан, милли тарихын белмәгән бала «Мин – татар!» дип горурлана алырмы икән киләчәктә? Ай-һай... Татарларның сан ягыннан елдан-ел кимүе – әнә шул сәясәтнең нәтиҗәсе инде.

Менә шуңа күрә дә Бөтендөнья татар конгрессының Милли шурасы тарафыннан агымдагы елның август азагында кабул ителгән «Татарлар: гамәл стратегиясе» һәм «Гамәл стратегиясен тормышка ашыру буенча эшчәнлекнең төп юнәлешләре» исемле документларны без бик дулкынланып укып чыктык, өйрәндек. Чөнки бу документларны халык күптән көтелгән, төп нигезләмәләре киң җәмәгатьчелек тарафыннан тикшерелеп хупланган, тулыландырылган һәм киләчәктә халкыбызны саклауга, үстерүгә юнәлдерелгән гамәлләр җыентыгы буларак кабул итте.

«ТАТАРЛАР: ГАМӘЛ СТРАТЕГИЯСЕ»

Документларның беренчесен, «Татарлар: гамәл стратегиясе» дигәнен, бик җентекләп эшләнгән, күләме белән җыйнак кына, эчтәлеге белән фәлсәфи характердагы тирән фикерләр туплаган күмәк хезмәт дип атарга була. Биредә Стратегиянең төгәл максатлары бәян ителгән, глобальләшү шартларында татар милләтен саклау һәм үстерүдә милли

Фото автордан

үзаңны, мәдәни мирасны, туган телебезне, моңыбызны, иманыбызны, традицион гаилә кыйммәтләрен саклау, мәгърифәткә омтылу һәм башка юнәлешләр буенча эшләү зарурлыгы күрсәтелгән. Йомгаклау өлешендә «Кем ул татар?» соравына җавап бирелә. Автор-төзүчеләрнең: «Мәдәниятебез, телебез өчен, гореф-гадәтләребезне саклау өчен, үзебезгә, ата-бабаларыбызга кадерле хәзинәләрне киләсе буыннарга тапшыру өчен җаваплылыкны бары без генә үз өстебезгә ала алабыз», – дигән фикерләре белән килешмичә мөмкин түгел.

Шунысын да өстәп әйтергә кирәк: «Гамәл стратегиясе»н теоретик характердагы документ дип әйтергә була, шуңа күрә, аңлашыла ки, биредә күрсәтеп үтелгән юнәлешләрне тормышка ашыруның төгәл вакыты күрсәтелмәгән. Ул – озак елларга исәпләнгән проект.

Ә менә «Гамәл стратегиясен тормышка ашыру буенча эшчәнлекнең төп юнәлешләре» – башка эш. Миңа калса, бу документны югарыда каралганы белән берләштереп, аны «Татарлар: гамәл стратегиясе һәм аны тормышка ашыруның төп юнәлешләре» дип тә атарга булыр иде. Ярый, ничек бар, шулай булсын, эш бит исемдә түгел – җисемдә.

Стратегиянең төп юнәлешләре бәян ителгән документның күзгә иң беренче ташлана торган җитешсезлеге, минемчә (моңа башкалар да игътибар итмичә калмагандыр, шәт), милләтебезне саклау һәм үстерү юнәлешендә кылыначак гамәлләрнең үтәлеш вакыты һәм үтәлеш өчен җаваплы оешмаларның яисә затларның исемнәре күрсәтелмәүдә. Әлеге Стратегиядә санап үтелгән гамәлләрне тормышка ашыру ничә елга исәпләнгән? Эш нәтиҗәләренә кайчан йомгак ясалачак? Аңлашылмый. Бер караганда, «Оештыру эшләре» дигән бүлектәге «татарлар күп яши торган төбәкләрдә татар ашларын, киемнәрен һәм традицион спорт уеннарын популярлаштыру», «төбәкләрдә татар иҗтимагый оешмаларының активлыгын һәм мөстәкыйльлеген стимуллаштыру», «татарлар күп яши торган төбәкләрдәге милли-мәдәни оешмалар арасында үзара бәйләнешләрне ныгыту», «татарларның башка милләт вәкилләре белән дуслыкта һәм татулыкта яшәүләрен тәэмин итү» кебек пунктларның үтәлеш вакытын төгәл генә билгеләп тә булмый, чөнки алар даими һәм системалы рәвештә башкарыла торган эшләр. Ә гомумән кирәк иде микән әлеге һәм башка вак-төяк пунктларны шундый җитди документка кертергә? Алар миңа җитди документның дәрәҗәсен төшерә кебек тоела.

Хәзер «Туган телне саклау һәм үстерү» дип аталган һәм без тикшерә торган Стратегиянең генә түгел, бәлки Бөтендөнья татар конгрессы эшчәнлегенең асылын, нигез ташын тәшкил итә торган мөһим бүлеккә мөрәҗәгать итик. Ун пункттан торган бу бүлектә шул ук көн саен эшләнә торган яисә эшләнергә тиешле гадәти гамәлләр санап кителә: балалар бакчаларында, мәктәпләрдә татар төркемнәре ачу өчен ата-аналар белән максатчан эш; Россия төбәкләрендәге мәктәпләрне (аларда татар сыйныфлары булган очракта) татарча дәреслекләр белән тәэмин итү; ел саен үткәрелә торган «Татарча диктант» акцияләрендә татарларның катнашуын оештыру; татар телендә алып барыла торган радио-һәм телетапшыруларны популяштырлашу, Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребезнең тормышы турында сюжетлар әзерләү h.б. Болары да кирәк, әлбәттә, һәм аларның күбесе эшләнә дә. Ә телебез югала бара. Нишләргә соң?

киләчәккә йөз тотып...

Бу сорауга җавап бар: татар теленең статусын күтәрергә, куллану даирәсен киңәйтергә теләсәк, беренче чиратта Татарстан Дәүләт Советы депутатларыннан утырышларны татарча алып баруны һәм Дәүләт Советының әле 1990 нчы еллар башында ук кабул ителгән Татарстан Милли университетын ачу турындагы карарын тормышка ашыруны таләп итәргә кирәк. Бездә Татарстан Фәннәр академиясе бар, ә милли университет юк. Болай булырга тиеш түгел, әлбәттә. Һәм бу таләп – вакытлы матбугат битләрендә еш күтәрелә торган халык таләбе! – «Гамәл стратегиясен тормышка ашыру буенча эшчәнлекнең төп юнәлешләре»ндә чагылыш табарга тиеш иде, югыйсә.

Минемчә, Стратегиягә тагын бер мөһим пунктны кертү кирәк иде. Югарыда әйтеп үтелгәнчә, 2007 елның 1 декабреннән көченә кергән 309 санлы Федераль канун нигезендә урта мәктәпнең укыту программаларыннан «милли-төбәк компоненты» дигән төшенчә алып ташланды. Татар баласы үз халкының тарихын белмәгәч, матур итеп үз ана телендә язарга-сөйләшергә өйрәнмәгәч, аннан нинди милләтпәрвәр чыксын, ди. Минемчә, безнең Дәүләт Думасы депутатларыннан менә шул карарны гамәлдән чыгаруны таләп итәргә кирәк. Кызганыч, «Гамәл стратегиясенең төп юнәлешләре»ндә милли-төбәк компонентына кагылышлы пунктны да таба алмыйбыз.

Мәдәни мирасны барлау, саклау һәм баету өлкәсенә караган бүлектә Россия территориясендә һәм чит илләрдә татар халкы һәм аның күренекле шәхесләре белән бәйле истәлекле урыннарның тулы җыелмасын әзерләү турындагы пункт та бар. Татарларны дөньякүләм таныту максатында бик кирәкле һәм файдалы эш планлаштырыла! Моны хупларга һәм тормышка ашыруда төрле яклап ярдәм генә итәргә кирәк.

«Гамәл стратегиясен тормышка ашыру буенча эшчәнлекнең төп юнәлешләре»ндә тагын «Яшьләр белән эшләү», «Татарлар арасында эшмәкәрлек активлыгын арттыруда ярдәм итү», «Гаилә кыйммәтләрен саклау һәм ныгыту», «Халык иҗатын үстерүгә булышлык итү» кебек бик кирәкле бүлекләр дә бар. Планлаштырыла торган гамәлләр исемлегенең күп очракта декларатив характерда булуы гына күңелне борчый: «яшь буынны үз халкыңның бай тарихи-мәдәни мирасы белән горурлану рухында, туган җирнең патриотлары, Туган илнең сакчылары итеп тәрбияләү»; «татар халкының дөньяга карашы нигезләрендә балаларда милли рух формалаштыру», «татар эшмәкәрләренең төбәкара багланышларына булышлык күрсәтү» h.б. Бөтендөнья татар конгрессы бу эшләрне үзе башкарып чыгарга тиешме, әллә башка фәнни, мәгариф, җәмәгать оешмалары белән хезмәттәшлектәме? Шулар ачыкланмаган.

Гомумән алганда исә, Бөтендөнья татар конгрессы тарафыннан эшләнгән һәм аның Милләт җыелышы хуплаган «Гамәлләр стратегиясен» мин халкыбызның киләчәк язмышын билгеләү, аның яшәешен тәэмин итү максатында башкарыласы эшләрне күрсәткән мөһим документ дип бәялим. Әйе, эшләнәсе эшләрнең, гамәл юнәлешләренең тулы исемлеге түгел ул. Документта әйтелгәнчә, аны тулыландыруда, камилләштерүдә милләтебез язмышына битараф булмаган һәр татар, һәр иҗтимагый оешма катнаша ала. Чөнки халкыбызның киләчәге – үзебезнең кулда.

ТАТ
МЕДИА

Кышкы язылу өчен кар көри торган машина, кухня техникасы һәм гаджетлар от!

Бүләкләр 2021 елның 12 февралендә уйнатылачак

1 язып

2020 елның 25 декабренә кадәр ТАТМЕДИА АҖнең бер газета һәм бер журналына языл (акциядә катнашучы басмалар белән tatmedia.ru сайтында танышып була)

2 җибәр

«Акция» билгесен куеп, язылу квитанцияләренең копиясен безгә җибәр (телефон номерыгызны язарга онытмагыз). Адрес: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 яки podpiska@tatmedia.ru

3 от

Язылган өчен тостер, чәйнек, смартфон яки планшет от. Төп бүләк — кар көри торган машина!



Тулырак мәгълүматны, акциянең узу вакытын, бүләкләр, аларны алу тәртибе турында tatmedia.ru сайтында белә аласыз. Акция 19.10.20 — 20.03.21 кадәр үткәрелә. Гаризалар 30.01.2021 кадәр кабул ителә. Оештыручы — ТАТМЕДИА АҖ. Реклама 16+ Товарлар рәсемдә күрсәтелгәннән үзгә булырга мөмкин.

Игелекле эшләр

Акыллы гамәлләр

Мәңгелек кыйммәтләр

Игелекле эшләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Америкалылар бабаларыбызны ничек ачлыктан коткарган

Хөрмәт ничек мәхәббәткә әйләнә

Дөньядагы иң шәп урынны кайда таптык

КОТКАР РОССИЯНЕ, АМЕРИКА!

Автор: Әскәр Сабиров

1921 елның сентябре. Казан тимер юл вокзалы перронында бер төркем яшьләр пәйда була, күренеп тора – чит илдән килгәннәр. Киемнәре үк ят – эшләпә, килешле пәлтә, ак күлмәк, галстуктан... Революцион җимереклекләр фонында – кәттә кыяфәтле әфәнделәр. Сәләмә солдат киеменә төренгән, ач карашлы сирәк-мирәк җәяүлеләр ят кешеләргә сәерсенеп карыйлар: башка дөнья кешеләре. Тук кыяфәтле, пөхтәләр – мөгаен, буржуйлар...

АКШтан килүчеләр чыннан да пролетарийлар түгел. Затлы фин нәселе вәкиле, швед короле туганы Ивар Уорен, аксөяк, рәсем сәнгате белгече, Гарвард университетын тәмамлаган Джеймс Ривз Чайлдс, Джон Бойд, Уильям Шафротның зыялы, хәрби әзерлекле, әдәпле манераларыерактан ук күренеп тора...

Ачлык хөкем сөргән Татариягә алар ник килгән? Максатлары – бүген тәрәзәләрдән һәм урам чатларыннан аларга усал караш ташлаганнарга исән калырга ярдәм итү. Менә шундый буржуйлар.

ТАССР

ГУВЕР ВӘГЪДӘ ИТӘ: «БУЛЫШЫРБЫЗ!»

Яшь америкалылар – Америка ярдәм администрациясе, ягъни АРА хезмәткәрләре. Бу дәүләтнеке булмаган хәйрия оешмасы, җитәкчелектә – «кызылларны» җене сөймәүче, АКШ сәүдә министры Герберт Гувер.

Ләкин сыйнфый нәфрәт турында уйлар вакыт түгел. 1921 елның июлендә «Нью-Йорк Таймс» газетасында Максим Горькийның «Ко всем честным людям» дип аталган мөрәҗәгате басыла: «...Россия халкына ачлыктан үлү куркынычы яный. Исегезгә төшерәм, рус халкы сугыш һәм революцияләр йогынтысында какшады һәм аның авыруларга каршы торучанлыгы, физик яктан чыдамлыгы бик нык кимеде. Лев Толстой һәм Достоевский, Менделеев һәм Павлов, Мусоргский, Глинка һәм башка дөньякүләм кыйммәткә ия кешеләр иле өчен рәхимсез көннәр җитте, һәм мин Европаның һәм Американың барлык зыялы кешеләре, рус халкының гаять аяныч хәлен аңлап, тиз арада икмәк һәм медикаментлар белән булышырлар, дип ышанам».

Гувер – таш түгел. Горькийның мөрәҗәгатен укыганнан соң, шунда ук язучыга телеграмма суга. Аның асылы: Америка, АРА йөзендә, ярдәмгә киләчәк, кайбер шартлар үтәлгәндә. Берничә айдан соң формальлекләр үтәлә. Ригада Совет Россиясе белән шартнамә имзалана, америкалылар ачлыктан иң нык интеккән төбәкләрдә авырлы хатыннар һәм 14 яшькәчә булган балалар өчен ашауны оештыруга алына. АРАга АКШ Конгрессы тарафыннан ачлыктан интегүчеләр өчен азык-төлек сатып алырга бүленгән беренче ун миллион доллар – ул вакытлар өчен фантастик акчалар...

Азык-төлекне каядыр, төгәл билгеле булмаган урынга китерү – бу, әлбәттә, америкача түгел. Һәр паекның чыннан да мохтаҗ кешегә барып җитүенә ирешергә кирәк. АРА урыннарга үз вәкилләрен юллый – илгә ябырылган фаҗиганең чын масштабын үз күзләре белән күрергә һәм ярдәм күләмен билгеләргә. Шуңа күрә бу вакытка эшче структура төзелә. АРАның Үзәк вәкиллеге – Мәскәүдә. Калган территорияләр районнарга бүленә. Һәркайсында – үз дирекциясе.

Татария Казан районына керә. Коллегалары белән урындагы хәлләрне белергә килгән Ивар Уорен монда җитәкче булачак.

Фото: Александр Ефремов

«АЛАР КӨНЕНӘ УНИКЕЛӘП КЫРЫЛА...»



Америкалылар мораль яктан әзерлекле. Беренче бөтендөнья сугышы тәмамланганнан соң нык кына җимерелгән Европа илләренә ярдәм күрсәткәндә әлеге егетләр төрлесен күрә. Монда да алдан ук күп нәрсә билгеле. Кешеләрнең инде күптәннән ашарга яраклы бар нәрсәне ашап бетереп, имән чикләвеге, салам, агач кайрысы, үлгән терлек, ат тиресе, ә кайбер урыннарда кеше ашауларның да очраклы турында газеталар, хәтта большевикларның үзәк басмасы булган «Правда» да хәбәр итеп тора. Әмма үз күзләре белән күргәннәр аларны тетрәндерә.

Казан районы кантоннары буйлап йөргәннән соң Уильям Шафрот болай дип яза: «Үзәк Европада гуманитар миссия эшчәнлеге чорында мин беркайчан да ачлыктан кечкенә скелетка әверелгән, аяклары нәзек чыбыкка калган, бу кадәр сәләмәгә төренгән балаларны күргәнем булмады, алар көненә уникеләп кырыла, дип сөйлиләр».

Ивар Уорен һәм аның коллегаларына барысы да аңлашыла: ярдәм күләме турында алдан ясалып куелган исәп-хисапларны үзгәртергә кирәк булачак – арттыру ягына. 1921 елның 9 октябрь санында «Известия ТатЦИКа» газетасы «Ачлыкка интегүче балаларга Америка ярдәм администрациясе Казанда» дигән мәкаләсендә түбәндәге саннарны китерә: «А.Р.А тарафыннан баштарак барлыгы 63000 балага ярдәм паегы бирү күздә тотылган иде; паекларны түбәндәгечә бүлү каралды: Казанга 6000 паек бирергә, Татреспублика кантоннарына: Спас кантонына – 7000, Лаешка – 3000, Мамадышка – 3000, Бөгелмәгә – 6000, Алабугага – 4000, Буага – 4000, Свияжскига – 3000, Тәтешкә – 7000, Чистайга – 5000, Минзәләгә – 8000, Чаллыга – 4000 һәм Арчага – 3000. Мистер Уорн (Уорен – ред. иск.) кантоннар буенча йөреп кайтканнан һәм Мәскәүдәге Үзәк комитеттан өстәмә мәгълүматлар алганнан соң, октябрь һәм ноябрьгә Татреспубликага биреләсе паеклар санын 150 000 гә кадәр арттырырга карар кылынды».

ДӨНЬЯ БУРЖУАЗИЯСЕННӘН КАКАО ҺӘМ АК КҮМӘЧ

Ашыгырга кирәк. Америкалылар тарафыннан оештырылган беренче балалар ашханәләре һәм ашату пунктлары Татариядә 1921 елның октябрь башында ук эшли башлый. Беренче чиратта алар приютларда һәм балалар йортларында пәйда була, чөнки анда читтән ярдәм күрсәтелмәгән очракта хәлләр бөтенләй коточкыч була.

Балаларны америкалылар катгый калькуляция буенча ашаталар. Филантроп-капиталистлар тарафыннан расланган продуктлар җыелмасы: дүшәмбе, пәнҗешәмбе: какао – 3,3 мыскал (1 мыскал=4,27 г); шикәр – 8,2; сөт – 15,4; икмәк – 30; сишәмбе, җомга: дөге-16,4; сөт – 8,2; шикәр – 3,7; икмәк – 30; чәршәмбе, шимбә: кукуруз-19,9; май – 4,2; он – 6,5; икмәк – 30; якшәмбе: сөт – 2,3; ногыт – 16,4; май – 4,2; он – 6,5; икмәк – 30.

Продуктлардан боткалар, ашлар, шулай ук икенче ашлар һәм эчемлекләр әзерлиләр, кайбер ризыклар балалар өчен бөтенләй ят була, үз гомерләрендә бер тапкыр да ашап карамаган: пудинглар, какао... Һәм тагын иң тәмлесе – ак күмәч.

Америка ашханәсенә беркетелгән һәр балага якынча 800 калорий туры килә – ачтан үлмисең. Дөрес, аерым айларда, әйтик, кышын, 500 калорийга кадәр төшә. Тик АРА гаебе белән түгел – шартлар буенча, хәйриячеләр үз акчаларына ашамлыклар сатып алалар һәм океан аръягыннан Россиягә кадәр китерәләр, ә хуҗалар ил эчендә таратуны үз өстенә алалар. Кораблар портларга вакытында килә, ә алга таба ничек туры килә, – шулай, чөнки тимер юлларда хаос һәм җимереклек хөкем сөрә.

Хакимият аярдәм кулы сузган америкалыларга рәхмәт белдерәме? Ихтимал. Хәер, бу, «Известия ТатЦИКа» газетасында түбәндәге эчтәлекле мәкалә бастырырга комачауламый: «Көнбатыш Европа һәм Америка илләрендә Идел буе кебек дистәләгән төбәкне ашатырга җитәрлек артып калган икмәк бар. Ләкин ач үлемгә дучар ителгән миллионнарны җиңел һәм тиз арада коткарып калырлык барлык бу байлыклар дөнья буржуазиясе кулында. Идел буена күрсәтелә торган ярдәм тирәсендә күтәрелгән ыгы-зыгы никадәр көчле булса, чынлыкта күрсәтелә торган реаль ярдәм шулкадәр аз булуның да төп сәбәбе шунда».

ШВЕД КОРОЛЕ ТУГАНЫННАН ДИЗАЙН

Бәхеткә, Америка егетләре совет газеталарын укымыйлар. Хәер, Казан районындагы бәлаказаның масштабы шулкадәр зур була ки, газеталар укырга вакыт калмый. «Дөнья буржуазиясенең» яшь вәкилләре ачтан интеккән кешеләрнең мөмкин кадәр күбрәгенә ярдәм итәргә тырыша. 1922 ел башына азык-төлек паегы ала торган балалар саны 200 меңгә җитә, һәм бу сан ай саен үсә генә бара.

Кышка төбәктә балаларны ашатуны оештыру бөтен вагы-төягенә кадәр җайга салына. Уорен, Чайлдс һәм аларның коллегалары – элеккеге офицерлар, мөмкин булган барлык урыннарда да үрнәк, армиядәгечә диярлек тәртип урнаштыруга ирешәләр. Ләкин бер проблема баштарак барысының да үзәгенә үтә. Урыннарда азык-төлекне гадел итеп бүләргә тиешле иҗтимагый комитетлар ике якның килешүендә каралган тәртиптә оештырылмый. Юк, комитетлар төзелә, эшли, ләкин аларның составы алдан ниятләнгәнчә булмый. АКШтан килгән хәйриячеләр, беркатлыланып, анда табиблар, укытучылар, агроном, рухани, шулай ук җирле авыл советы вәкиле керер, дип уйлыйлар.Чынлыкта исә һәр комитет тулысы белән диярлек дәүләт түрәләреннән тора. Һәм паеклар, сыйнфый яисә башка билгегә таянып түгел, ә бәлки ихтыяҗга карап бүленер, дип беркем дә ышанып әйтә алмый.

Хәер, ачлык, авырулар һәм җимерекләкләр хөкем сөргән илдә административ ресурс кайвакыт америкалыларга ярдәмнең бердәнбер реаль чарасына әйләнә. АРА хезмәткәрләренең хакимиятләр белән мөнәсәбәтләрне ачыклап торырга вакытлары юк: кешеләрне коткарырга кирәк. Тиздән алар шуны аңлый: продуктлар белән ярдәм итү генә аз – хәл шулкадәр авыр.

Балалар йортларындагы хәлләрне күрү америкалылар өчен чираттагы тетрәнүгә әверелә. Джеймс Ривз Чайлдс, Югары Ындырчы авылындагы балалар йортына барганнан соң, үзенең көндәлегендә болай дип яза: амбарда йөзгә якын бала, стена буйлап балалар йоклый торган сәкеләр сузылган. Юрган, карават, урын-җир... – боларның берсе дә юк, сәламәгә төренгән балалар, җылыну өчен, бер-берсенә елыша.

Буа балалар йортында булганнан соң, АРА хезмәткәрләре җентекләп теркәп куялар: 81 баланың 20 се тиф белән авырган, 10сы әлегә кадәр авырый. Барысына бергә – 21 карават, 20 юрган. Урын-җир, эчке киемнәр, җылы киемнәр һәм аяк киемнәре юк, кайбер балалар бөтенләй шәрә йөри...

Дөнья буржуазиясенең «битараф» вәкилләре шунда ук эшкә керешә. Күргәннәре турында АРАның Мәскәүдәге җитәкчелегенә җиткергәннән соң, карарны көтеп тә тормыйча, кул астында булган әйберләрдән ярдәм оештыра башлыйлар – балалар йортларына продуктлар төяп китерелгән капчыкларны бирәләр. Швед короле туганы Ивар Уорен, бөтен фантазиясен эшкә җигеп, балалар өчен кышкы кием уйлап таба: бер капчык икенчесенә кидерелә, алар арасына салам тутырыла, анда өч тишек тишелә, баш һәм ике кул өчен – үзенчәлекле пәлтә килеп чыга. Салам тутырылган капчыклар шулай ук матраска да әйләнә...

ТИФКА КАРШЫ КӨРӘШ

Аннан соң АРА массакүләм төстә кием-салым китерүне җайга сала. Казан районында америкалылар тарафыннан балаларга 124 675 пар як киеме, 137 242 пар оекбаш, 27 522 күлмәк, малайлар өчен 26 312 костюм, 11 915 пәлтә, 6 922 одеяло һ.б.лар таратыла.

Дөрес, океан аръягыннан килгән таләпчән хәйриячеләрнең һәрвакыт бер шарты була: киемнәрне таратыр алдыннан балалар йортына дезинфекция үткәрергә, балаларны бетләрдән арындырырга, гап-гади тәртип ясарга. Сабын, дезинфекция матдәләре? Боларның барысын да АРА бирә, хезмәткәрләре исә үзләре дезинфекцияләргә дә булыша. Әмма бернинди дә гамәл кылмау белән катгый килешмиләр. Кайчак кырысрак булуны да таләп итәләр – тәрбияләнүчеләре язмышына битараф булган балалар йорты директорларын эштән азат итүгә кадәр...

Алар балалар йортларына үз тәртипләрен кертә: туклануны һәм көнкүрешне җайлыйлар,

балаларга киносеансларга кадәр оештыралар. Фильмнар планета, аның флора һәм фаунасы турында гына түгел, анда американлылар күзлегеннән карагандагы нормаль тормыш нинди булырга тиешлеге күрсәтелә, дөрес оештырылган көнкүреше, гигиена таләпләренең үтәлеше белән бергә...

Болар барысы да – халыкның ачлык-ялангачлыктан кырылуы дәвам иткән, эпидемия котырган һәм медикаментлар булмаган илдә. Монда да АРА, мөмкин булган барлык чараларга таянып, совет гражданнарының сәламәтлеген кайгырта. АРАның медицина программасы эшли башлый. Аның беренче карлыгачы – Татариядә балалар өчен туберкулёз шифаханәсен ачу. Алга таба тагын да күбрәк: хастаханәләргә, поликлиникаларга, балалар йортларына, мәктәпләргә дарулар, дезинфекция матдәләре китерелә башлый. Тифтан, вабадан, чәчәк авыруыннан вакциналар ясыйлар, ләкин халыкның томаналыгы монда да комачаулый – күпләр баш тарта. Ә американлылар баш тартмаслык ысул уйлап таба: прививка ясатмаган кешегә паек бирелми. Нәтиҗәдә Казан районында әлеге авырулардан 1,5 миллион кешегә прививка ясала.

Ә азык-төлек ярдәме белән эшләр ничек тора? Аның күләме артуга таба бара. 1922 елның гыйнварыннан Америкадан китерелгән азык-төлек паегын инде олы кешеләр дә ала башлый. 1922 елның 1 июленә бирердә көн саен 1,1 миллион паек таратыла! 1923 елның маена Татреспублика балаларының яртысы паек хисабына яши.

БҮЛӘККӘ – ГПУның АЕРЫМ ФИКЕРЕ

Америка ярдәм программасы Казан районында ике елга якын эшли һәм 1923 елның июлендә генә туктый. Сәбәбе нәрсәдә? Язын, Идел буенда әле ачлык дәвам иткәндә, Советлар Россиясе икмәк экспортын яңартып җибәрә. Үз икмәген читкә чыгарганда, бушлай ярдәм, табигый ки, сәер күренә.

Үзләре киткәндә АРА Казан районындагы медицина учреждениеләренә ярты елга җитәрлек медикаментлар запасы калдыра...

Американлыларның риясыз ярдәменә безнең илдә нинди бәя бирәләр соң?Лаеклы бәя, дип уйларга хаклыбыз. Хәер, Лубянкадагы иптәшләрнең бу хакта үз фикерләре булган. ГПУ хезмәткәренең бер донесениесендә мондый юлларны очратырга мөмкин: Казан районында эшләгән ун американлының «6сы хәрби, 2се Ак армиядә сугышкан, 3се Америка һәм инглиз разведкасында эшләгән. Үзләренең сәләтләре һәм үткәннәре буенча, хәрби чыгышлар очрагында, АРАның Казан бүлеге штаб, тәэминат бүлеге, разведка башлыгы сыйфатында барлык операцияләр һәм кешеләр белән идарә итә алырлык тәҗрибәле җитәкчегә ия»...

СОҢГЫ СҮЗ УРЫНЫНА

400 меңгә якын. Кайбер тарихчылар фикеренчә, Татариядә 20 нче елларда котырган ачлык нәтиҗәсендә шулкадәр халык үлгән. Илебезгә американлылар тарафыннан күрсәтелгән ярдәм нәтиҗәсендә күпме гомерләрнең сакланып калуын, әлбәттә, беркем дә беркайчан да санамаган. Ярдәмнең күләменә караганда, сүз йөз меңнәрчә кеше гомере турында бара – әле бу бер Татариядә генә.

Ләкин бүген бу турыда белүчеләр аз – океан аръягында яшәүче планетадаш күршеләребез күрсәткән игелекле эшләр турында искә төшерү бездә ничектер кабул ителмәгән. Юкса, килешәсездер, безнең бу хәлләрне онытырга хакыбыз юк – илләр арасында нинди генә мөнәсәбәтләр булмасын, нинди генә сәяси җилләр исмәсен.

Икенче елга Идел буенда коточкыч ачлык башлануга 100 ел тула. Һәм, мөгаен, авыр 20 нче елларда ерак Татарстанга килеп, безнең әби-бабаларыбызны үлемнән коткарган американлыларга һәйкәл ачу бик гадел гамәл булыр иде. Ә ачылышка Татарстан җирендә тиңе булмаган коткару операциясендә турыдан-туры катнашкан яшь американлылар Ивар Уорен, Джеймс Ривз Чайлдс, Джон Бойд, Уильям Шафротның варисларын чакырырга.

Кайчандыр Максим Горький АРА җитәкчесе Герберт Гуверга язган хатында болай дигән: «Сез күрсәткән ярдәм тарих битләренә бөек данга лаеклы уникаль, гаять зур казаныш булып язылыр һәм сез үлемнән йолып калган миллионлаган рус кешесенең хәтеренә бик озак елларга кереп калыр».

Һәм бүген классигыбыз әйткән сүзләрне чынга ашырырга безнең хәлебездән килә. 100 елдан соң булса да.

РУФИНА ФӘТТАХОВАНЫҢ ТОРМЫШ ЛИНИЯСЕ

Автор: Руфия Фазылова

ВИЗИТ КАРТОЧКАСЫ

Руфина Фәттахова – югары категорияле табиб, медицина фәннәре кандидаты, ТР ның атказанган табибы. 1937 елда Башкортостанның Тәтешле районында дөньяга килә. 1964 елда Казан дәүләт медицина институтын тәмамлый. 1972 елдан Казан дәүләт медицина академиясендә укыта башлый. Һәм хәзерге көндә дә биредә эшли.

Медицина уку йортына керү алдан уйланылган адым да, хыял да түгел иде. Унынчы сыйныфны тәмамлагач, иптәш кызым белән газетада игъланнар караштыра башладык. Ул чакта югары уку йортының исемнәре белән бергә бинаның фотосурәтләре дә басыла иде. «Уку йортының менә монысы матур», – дип сөйләнгәләп, белдерүләр укыйбыз. Шул вакыт эти килде дә: «Балалар, уку йортын бинасына карап сайламыйлар бит», – диде. Ул безгә Уфага медицина институтына барырга киңәш итте. Әти укытучы, мәктәп директоры булып та эшләде. Аның киңәшен тоттык.

«Медицина институтына укырга керә алмасаң, өйгә кайтмыйсың», – диде әти. Керә алмасам, нишләргә тиеш идем, анысын әйтмәде. Күрәсең, яхшы укыгач, имтиханнарны уңышлы тапшырыр, дип уйлагандыр. Тиешле тәрбия бирдем дип тә фикер йөрткәндер. Озын сүзнең кыскасы, ул елны медицина институтына керә алмадым, балл җитмәде. Шуннан Уфа медицина училищесына киттем. Анда бишкуллап алдылар.

Кулга диплом алгач, ике ел фельдшер булып эшләдем. Шул чагында үземә максат куйдым – врач булам. Уфа дәүләт медицина институтына керер өчен ныклап әзерләндем. Һәм теләгемә ирештем.

Нурихан белән танышканда аның беренче хатынынннан аерылган икәнен белә идем. Икебез дә Яңавылдан булып, бер мәктәптә укысак та, берберебезне күргән юк идек. Яшь аермасы шактый бит – 9 ел. Уфа медицина институтының беренче курсында укып йөргән чагым. Кышкы каникулга кайткач, китапханәгә бардым. Анда классташым Әлфия мөдир булып эшли иде. Яшь язучы буларак, Нуриханны очрашуга чакырганнар. Нишләптер, ул чара да, Нурихан үзе дә әллә ни тәэсир итмәде миңа. Икенче көнне миңа Уфага китәргә кирәк иде. Без Нурихан абый белән Уфага бер үк рейста очтык. Утыргычлар да янәшә туры килде кебек. Ни генә булмасын, сәгать буе диярлек без аның белән сөйләшеп бардык. Аның кулында кечкенә чемодан бар иде. «Уфа буйлап күтәреп йөреп булмас, сезнең бүлмәгә куеп торырга ярыймы?» – диде ул... Каршы килмәдем. Иптәш кызым белән без аны озатып та калдык әле. Ул Казанга китте. Аннан хатлар язышa башладык. Ул минем хатларның берсен дә ташламаган, саклаган...

Өченче курсны тәмамлагач, Нуриханга кияүгә чыктым. Һич көтмәгәндә тәкъдим ясады ул. Өченче курсны тәмамлагач, җәйге каникул вакытында Яңавылда берничә мәртәбә очраштык без, бер мәртәбә Ямады авылына Илдар Юзиевларга да барып кайттык. Алар Казаннан этиләренә кайткан булганнар. Җәй азагында, укулар башланганчы дип, Нурихан мине Казанга кунакка чакырды. Дусларча гына инде. Ул миңа Казанның матур урыннарын күрсәтеп йөрде, Казан дәүләт медицина институтына алып барды. Әлбәттә, Уфа медицина институты белән чагыштырганда,

Фото: Александр Ефремов

КДМИ җиһазлар ягыннан күпкә алга киткән иде. Алай гына да түгел, Нурихан мине бирегә дүртенче курска ничек күчереп булу турында да кызыксынды. Менә шулай, бер уйламаган җирдән, берәүгә дә әйтмичә, без өйләнешеп куйдык һәм мин укуны Казанда дәвам иттем.

Беренче урында гаиләме, эшме, – дип сорыйлар. Әлбәттә, институтны тәмамлап, эшкә урнашкач, беренче чиратта эш турында уйлыйсың. Диагнозны дөрес куйдыммы, дөрес эшлимме икән, дисең. 1972 елда Казан дәүләт медицина академиясенә эшкә урнашкач, көнетөне әзерләнергә туры килде. Ул бит студентлар белән генә эшләү түгел, ә врачларны укыту. Алар каршына чыгу өчен күпме әзерләнгәнемне үзем генә беләм. Шуңа күрә, ул елларда гаилә беренче урында булды, дип әйтә алмыйм.

КДМАда берничә ай эшләгәч, китәргә уйладым. Кайттым да, Нуриханга әйттем:

– Укыту эшен ташлыйм. Врач булып кына эшләргә уйлыйм.

– Ни өчен? Нәрсә булды? – диде Нурихан.

– Үземнең тавышымны магнитофонга яздырып тыңлап караган идем, миндә акцент көчле, – дим.

– Син лекцияңнең темасын беләсеңме? – диде ирем.

– Әлбәттә, ул бит минем диссертация темасы. Ул теманы миннән күбрәк белүче дә юк.

– Әгәр дә син темаңны белеп сөйләсәң, тыңлаучы синең акцентыңа игътибар да итмәячәк. Ә инде син бик әйбәт русча сөйләсәң, әмма темаңны белмәсәң, алар сине гафу итмәячәк. Үзең уйла, телисең икән, кит, – диде Нурихан.

Шулай итеп мин кафедрадан китмәдем.

Акцент дигәннән, кафедра мөдире миңа: «Өйдә дә ручса сөйләшегез», – дия иде. Беренчедән, акцентны бетереп булмый. Татар мәктәбен бетергән, татарча уйлый торган кеше бит мин. Икенчедән, ничек инде өйдә русча аралашасың, ди?! Нурихан белән?!... Сөйләшкәндә ялгыш русча сүз кыстырсаң өтеп алырга да күп сорамас!

Дөресен генә әйткәндә, элек җәмәгать транспортында кычкырып татарча сөйләшергә курка, ояла идек. Хәзер яшьләр андый түгел. Миңа калса, аларда беркайчан да бездәге кебек оялу булмас. Хәзер бит замана башка: Европа илләрендә әллә ничә төрле телдә сөйләшәләр. Ерак барасы түгел, бездә дә үзбәкләр, башка халыклар рәхәтләнеп үз телләрендә аралаша. Берәү дә бармак төртеп күрсәтми.

1980 нче елларда радио, телевидениедә сәламәтлек турында тапшырулар алып бардым. «Азат хатын» журналында да шундый сәхифәм бар иде. Төп эш урыным – Биектау районының Каменка бистәсендә урнашкан туберкулез авырулары хастаханәсендә. Эштән соң, тапшырулар төшерергә шәһәр үзәгенә йөгерәм. Кайчакта туры эфирда эшләргә дә туры килә иде. Башта тапшыруга килгән врачны алдан әзерлисең: ул татарча камил сөйләргә тиеш. Ә бу ул чорда шактый катлаулы эш иде.

“

– Бераз ирек сыман замана килгәч, матбугатта: «Тегеләй итик, болай итик», – дигән язмалар күренә башлады. Телне дин саклап калган, дин тотарга кирәк, дигән өндәүләр көчәйде. Хәзер инде күп нәрсә ачыклана төште кебек: яулыклы апа-әбиләр, яшь туташлар шәһәр тулы, ләкин аларның күбесе рус телендә аралаша.

Тапшыруларны коллегаларым да карап баралар иде. Медицина терминнарын фәкать татарча сөйләп булуына шаккаталар. Татарча сөйли белгән өчен генә теләсә кайсы врачны чакырып булмый – гадәттә тапшыруларда да иң беренче сүз профессорга бирелде. Бу үзенә күрә, телне саклауның бер күренеше булгандыр дип уйлыйм.

Безнең почта әрҗәсе газета-журналлар белән тула иде. Бер ишесе –Нуриханга, бер ишесе миңа килә. Почта ташучы: «Сез яздырган газета-журналлар белән сумканы күтәрерлек булмый», – дия иде. Безнең заманда профессиональ журналларга язылу мәҗбүри булды. Хәзер андый мәҗбүрилек юк. Хәтерлим, КДМАда эшли башлаган елны кафедра мөдире матбугатка язылган квитанцияләрне карап-тикшереп тора иде.

Казанда татарларның татарча сөйләшмәвенә аңлы кеше бик борчыла. Хәер, элек тә борчылалар иде. Ул чакта үзара зарланышудан узмады. Күпләр русларны гаепләде. Бераз ирек сыман замана килгәч, матбугатта: «Тегеләй итик, болай итик», – дигән язмалар күренә башлады. Телне дин саклап калган, дин тотарга кирәк, дигән өндәүләр көчәйде. Хәзер инде күп нәрсә ачыклана төште кебек: яулыклы апа-әбиләр, яшь туташлар шәһәр тулы, ләкин аларның күбесе рус телендә аралаша.

Соңгы берничә елда миңа еш кына Коръән ашларында, никах бәйрәмнәрендә катнашырга туры килде. Хәзрәтләрнең күбесе яшьләргә татар телендә вәгазь сөйли алмый. Гарәпчә ятлаган аятьләрен чатнатып укып чыгалар да, тиешле гонорарларын алып кайтып китәләр.

Сүз дә юк, татар бакчалары, мәктәпләре булмау, баланың яшьтән үк үз телендә сөйләшмәвенә китерә. Ләкин бакчага йөрмәгән балаларның да телсез-чукрак кебек гариплегенә кем гаепле? Аңсыз ата-ана! Баланың теле ана куенында ачыла лабаса! Телне саклауда гаиләнең роле турында Роза ханым Туфитулова беренчеләрдән булып күтәреп чыкты, һаман шул турыда тукыды.

Менә хәзер телне саклау һәм үстерү максатыннан, ТР Президенты каршында махсус комиссия оештырылды. Моның өчен 100 млн акча каралган икән. Тик, әгәр халыкның үзаңы үзгәрмәсә һәм татар теле югары органнарда гамәлгә кермәсә, 100 млрд сум тотылса да, файдасы булмаячак.

Нурихан гомере буе бар булмышы белән татар милләтен түбәнсетүгә каршы торырга тырышты. Шуңа да иҗаты, фәнни эшләре, публицистикасы белән тарихыбызның тирәннән килүен, татар милләтенең, теленең бик борынгы булуын раслап килде. «Тарихны җиңүчеләр яза», – дип әйтә иде ул. Ә без, ни кызганыч, җиңелгән халык...

Нурихан коммунистлар партиясенең милләт мәсьәләсендә үткәргән басымын тоеп, шуңа әрнеп яшәде. Хрущев заманында татар авылларында татар мәктәпләре ябылу күбәйде, рус мәктәпләре ачтылар. Авылларда багана башына радио асып куйдылар. Аннан көне-төне русча сөйләделәр. Якындагы йортларда яшәүче халыкка бу радио йокларга комачаулый, ләкин зарланырга ярамый. Нурихан бу хәлләргә бик нәфрәтләнде. Руслаштыру мәсьәләсен ул инде мәктәп укучысы булган вакытында ук аңлаган булган. Хәтерлим, үләренә 2–3 көн кала, ашап утырганда, әрнеп:

«Кайсы юллар,
Нинди упкын
Тарта безне җан сорап?!» (Дәрдмәнд «Кораб» – ред.) – дип куйды.

– Син моны нишләп исеңә төшердең әле? – дим.

– Ә минем аны онытканым да юк. Сизмисеңмени, җанкисәгем, тагын кирегә китте бу... – дип куйды.

Нурихан үзенә бикләнгән кеше иде. Минем беркайчан да аның кәгазьләрендә актарынганым булмады. Аның үз бүлмәсе, үз дөньясы. Вафатыннан соң шактый хатлар, документлар таптым. Аларның күбесен халыкка чыгарырга да ярамыйдыр.

Бер килүендә Мөхәммәт Мәһдиев Нуриханга: «Син – бәхетле. Ыгы-зыгыга катышмыйсың», – диде. Ул чынлап та язучылар җыелышына да йөрергә яратмады. Ничектер андый чараларны вакытны бушка уздыру дип кабул итә иде.

Мәхәббәт яши-яши килә. Безнең шулайрак булды. Таһир-Зөһрә мәхәббәте булмаса да, аның эчке культурасы, укымышлы булуы – шулар җәлеп иткәндер. Ә аннан хөрмәт мәхәббәткә күчкәндер. Бу хөрмәт иҗатына гына да түгел. Ул беркайчан алдашмас, кеше сөйләмәс, башкаларның кимчелегенә төртеп күрсәтмәс. Шул ук вакытта рецензия язса, турысын әйтер. Һәрвакыт үзенең фәненә чумып яшәде.

Бала тәрбияләүгә килгәндә... Нурихан белән бер малай, бер кыз үстердек. Үземне начар яки әйбәт әни булдым, дия алмыйм. Булдыра алган хәтле тырыштым дип саныйм. Нурихан балаларны бик караштЫ. Ул бит күбрәк өйдә эшләде. Аннан безнең балалар мөстәкыйль булдылар. Ул чорда хәзерге кебек бала культы юк иде дә бит.

Кайнанамның бер сүзе бар иде: «Үз ризыгыңны балаңа бирмә, игелексез булыр». Ул чакта кибетләрдә хәзерге кебек азык-төлек тулып ятмады бит. Санаулы әйберне алып кайтасың да, өстәлгә куясың. Бала үзенекен ашый да, тагын карап тара. Нәүмиз булмасын дип, үз өлешеңне дә аңа бирәсең. Хәер, мин бүген дә шулай итәм – оныклар килсә, аларга бирәсем килә. Кызым Чулпан моның өчен әрли: «Юк заман түгел бит», – ди. Ә миңа биргәч күңелле. Шуннан рәхәтлек алам.

Алтмыш елдан артык медицинада өлкәсендә эшләгән кеше буларак, үземнең сәламәтлегемә зур игътибар бирәм, дия алмыйм. Пандемия башлангач та, аерым чаралар күрмәдем. Кеше арасына чыгып йөрмәүне санамаганда әлбәттә. Кирәк-ярак әйберләрне балалар китереп китә.

Аптекалардан беркайчан бернинди витамин алганым юк. Натураль ризык ашарга тырышам. Мисал өчен, шул ук коронавирустан иң кирәге С, Д витаминнары. С витамины карлыганда, гөлҗимештә күп. Ә Д витамины ак майда, йомыркада, диңгез балыкларында күп. Шулай ук, ит ризыкларында да бар.

Пандемия минем өчен авыр булмады, чөнки янәшәдә урман, бакча. Рәхәтләнеп саф һавада йөрдем. Ә табигать көч бирә, начар уйларга чумарга вакыт калдырмый.

Иммунитетны ныгыту һәрвакыт кирәк. Моның юлы гап-гади – дөрес туклану (күбрәк яшелчә, җиләк-җимеш, ит, балык ризыклары), саф һавада йөрү. Хәзер бигрәк тә мул уңыш чоры. Карлыган, җиләк – һәммәсен туңдыргычка катырып куям. Соңгы елларда кайнатмалар ясамыйм, чөнки файдалы матдәләре калмый.

САЛАВЫЧНЫҢ КЕНДЕК ӘБИСЕ

Автор: Руфия Фазылова

1998 елдан бирле ноябрьнең соңгы якшәмбесендә рәсми рәвештә Әниләр көнен билгеләп узабыз. Ел буе күңелдә җыелып килгән җылы сүзләрне иң газиз кешеләребезгә ирештерәбез. Әйе, әниләре исән-сау булганнар өчен бу бик зур көн. Һәм... балалары булган хатын-кызлар өчен дә. Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы мәгълүматлары буенча, Россиядә һәр алтынчы хатын-кыз ана булу бәхетеннән мәхрүм...

Бу юлы сүзем – йөзләгән хатын-кызга ана булырга ярдәм иткән кеше турында.

Фото: Лилиана Вәлитова

ЯЗМЫШ ЭЧЕНДӘ ЯЗМЫШ

1952 елның көзе. Балтач районының Салавыч авылына яшь фельдшер килә. Татарчасы такы-токы гына булган кыз бер әбигә йортка керә. Әбинең исә талканы коры – беләме, белмиме, Аннага бары татарча гына эндәшә. Шулай итеп, бер ай дигәндә, яшь фельдшер татарча сөйләшә башлый. Әлбәттә, бу татар әбисендә яшәгән өчен генә түгел. Анна, Салавычка килгәнче, Норма авылында эшләп ала. Күпмедер дәрәҗәдә телен шунда шомарта. Һәм медицина ягыннан да тәҗрибә туплый. Аннаны Салавычка вакытлыча гына дип җибәрәләр. Авылның фельдшер-акушерлык пункты җитәкчесе авырып китә. Яшь кыз шунда эшләп торырга тиеш була.

Анна Кузнецова тумышы белән Алабуга районының Гәр авылыннан. Бүген аның рус милләтеннән икәнлеген бары тик аерым бер сүзләрдә җиңелчә акценты гына искәртә.

– Миңа карата авыл кешеләре бик хәерхаһлы булдылар, – дип искә алды ул Анна-Нурания апа. – Ул чорда укытучылар, фельдшерлар дәрәҗәле кешеләр саналды. Нинди авыру булса да, иң беренче миңа килделәр. Әнә шулай эшли-эшли барысына да өйрәндем инде. Авыл кешесе хастаханәгә йөрергә бик яратмый бит. Җитдирәк авыру очракларында кешеләрне Балтачка җибәрә идем. «Рәхмәт, Нурания апа!» – дип әйтәләр иде соңыннан.

– Ә Нурания исемен сезгә кайчан куштылар? – дим.

– Кияүгә чыккач...

Анысы тагын бер үзенчәлекле тарих. Зәңгәр күзле рус кызы авыл кызлары белән уртак телне тиз таба. Бергә кич чыга башлыйлар. Аларга кушылып татарча җырларга, биергә өйрәнә. Салавыч яшьләрен рус җырларына да өйрәтә. Ике арада менә шулай дуслык күпере салына.

– Алабуга фельдшер-акушерлык мәктәбен тәмамлагач, без юллама белән өч ел эшләргә тиеш идек, – диде Нурания апа. – Өч ел узганнан соң туган ягыма кайтам, дип кенә килдем бирегә. Әти-әни, туганнар да: «Анда каласы түгел», – дип киңәш итте. Тик язмышның үз планнары булган икән.

– Салавычта калганга үкенмисезме? – дим.

– Юк, үкенмим. Ирем бик яхшы кеше иде. Кайнанам да ярдәмчел булды, балаларны ул үстерешге. Мин бит көнен дә, төнен дә эшкә чыгып киттем. Йорттагы эшләр кайнанама калды.

Нурания апа алга таба да мәрхүм тормыш иптәшен мактап телгә алды. Мәхәббәт тарихларын сагынып сөйләде:

– Ул елларда авылда яшьләр күп иде. Елына әллә ничә солдат кайтты. Барысы да матур киемнән, шәм кебек егетләр. Гыйззәтулла армиядән 1953 елда кайтты. Без кызлар белән клубка чыккан идек. Мин аны шунда ук күреп алдым, күзләр дә очрашты кебек. Башта Гыйззәтулла читтән генә карап йөрде, аннан килеп танышты. Озата кайтты. Матур сөйләшүе, чибәрлеге белән җәлеп итте ул мине. Менә шулай аралашып киттек. Озакламый: «Әйдә, никах укытабыз», – диде ул. Мин риза булдым. Татарлар никахсыз өйләнми икәнен беләм бит, шуңа күрә моңа әзер идем.

– Ә әти-әниегез?

– Аларга әйтмәдек.

– ?!

– Әти-әни минем татар егете белән очрашканны белделәр. Турыдан-туры әйтмәсәләр дә, сизеп тордым: алар каршы. Өч ел вакытның тизрәк узып, эшкә үзебезнең якка кайтуымны көттеләр.

«ТӨКЛЕ АЯГЫҢ БЕЛӘН...»

Анна шулай итеп Нураниягә әйләнә. Рус кызы дип тормый, кайнанасы аны җылы кабул итә. Хәер, бу аңлашыла да, Анна авыл кешеләре өчен иң беренче чиратта – табиб, нинди генә борчу булса да, аңа киләләр. Ә ачык йөзле туташ аларның һәркайсына ярдәм итә. Шулай булгач, аның бүтән милләт, бүтән диннән булуы алай мөһим дә булмый.

– Кайнанама тиз ияләндем. «Төкле аягың белән, кызым. Бәхетле булыгыз», – дип каршы алды ул мине. Бер гаилә булып яши башладык. Яшьлегем белән күп эшләрне белми идем, ул өйрәтте.

– Ә әти-әниегезгә кайчан әйттегез? Алар бу яңалыкны ничек кабул итте? – дим.

– Мин инде ул чакта көмәнле идем. Нишләсеннәр, риза булдылар. Туганнар белән безгә килделәр. Табын артында утырып сөйләштек, елаштык...

Нурания апа гомер буе улы Рәшит, килене Фәридә белән яшәгән. Бүген дә алар тәрбиясендә. Безнең сөйләшүне тыңлап торган Рәшит абый әйтә куйды:

– Аннары риза булганнар инде алар. Әти әнине бик хөрмәтләп яшәде, әби-бабай шуны күргәндер. Без ел саен әнинең туган ягы – Алабуга районы Гәр авылына кунакка бара идек. Ике туганнар да монда еш килде. Хәзер дә аралашып яшибез, бер-беребезгә хөрмәт белән карыйбыз.

– Дүрт туганнан мин генә калдым инде, – дип куйды Нурания апа. – Туксан ике тула бит инде. Авылда да мин белгән кешеләрнең күбесе гүр иясе булды.

Нурания апа кайнанасы белән дистә елдан артык яши. Килене белән утыз елдан артык гомер кичерә.

– Безнең әни сабыр ул, – диде Фәридә апа.

Мин исә бик четерекле теманы кузгатырга тырышып карыйм – дин. Башына ак яулык бөркәнгән әбинең дингә карашы ничек икән?

– Әни үзе намаз укымый... – диде Фәридә апа.

– Аллаһка ышану күңелдә булырга тиеш, – дип сүзгә кушылды Нурания апа. – Без бит динсезлек чорында үстек. Кайнанамның да Коръән китабын тотып утырганын хәтерләмим. Әлбәттә, өйдә барлык мөселман ашларын укыттым. Тәре, хач кебек әйберләр йортта булмады. Балаларым да – мөселман. Кызым мәчеттә укып йөри, остабикә. Хәтерлим, берсендә, Салавычның бер ак әбисе миңа ияреп, бала тапкан хатын янына барды. «Сабый тугач, кендеген үзем кисим әле», – дип сорады. «Кендек кисү бик саваплы эш», – диде. Ә мин йөзләгән баланың кендеген кискән кеше. Менә шул эшләрем мине оҗмахка алып керер, дип ышанам...

«ЮЛДА ТАПТЫРДЫМ»

Кендек әбисе. Салавычка фельдшер булып килгән яшь кыз санаулы вакыт эчендә әнә шул исемне йөртә башлый.

– Сезгә кадәр авылда балаларны кем таптырган? – дим.

– Авылда кендек әбиләре бар иде. Ул вакытта бит бөтен кеше өйдә бәбиләде. Фельдшерлык дипломым булгач, бәби тапкан җиргә мине дә чакыра башладылар. Хәтерлим, беренче сабыйны таптырган вакытта кияүдә дә түгел идем. Фельдшерлар мәктәбендә безгә төрле очракларда ярдәм күрсәтүне өйрәттеләр, шул исәптән бала таптырганда да.

Аннаны тиздән башка авылларга да чакыра башлыйлар. Халык арасында «кулы җиңел» дигән даны тарала. Яңгырмы, кар-буранмы, көнме, төнме, фельдшерны алып китәләр.

– Бала тапканда хатын-кыз яшәү белән үлем арасында кала. Фаҗигале очраклар булдымы? – дим.

– Алланың рәхмәте, егерме ел эчендә бер фаҗигале очрак та булмады. Хәзер телевизорлардан, газета-журналлардан бала тапканда үлүче аналар турында ишетәм, укыйм да уйланам – элек хатын-кызлар көчле булган. Аның бит әле шартлары да юк. Шунда бер кырыйда – яшь бозау, кечкенә сарык бәрәннәре. Икенче якта хатын бәбили. Нинди дезинфекция! Әле бала торергә чүпрәк әзерләп куйсалар ярый. Кайвакыт анысы да булмый...

Нурания апаның үзеннән калмый торган букчасы була. Анда беренче ярдәм күрсәтү өчен барлык әйберләр, шул исәптән кайчы, спирт та ята.

– Бала таптырганда кулланган инструментларны Балтачка, дезинфекцияләргә җибәрә идем. Гомумән, чисталыкка зур игътибар бирдем. Инфекция китмәсен өчен, барысын да эшләдем, – ди Салавычның кендек әбисе.

Алай да Нурания апа алдан хәстәрен күргән: авыррак очраклар булса, хатын-кызларны Балтач сырхауханәсенә җибәргән.

Изге һөнәре өчен Нурания апага Аллаһы Тәгалә дөньялыкта ук әҗерен бирә кебек тоелды – балалары янәшәсендә матур картлык кичерә.

– Берсендә бер ана машинада бала тапты, – дип хатирәләре белән бүлеште әңгәмәдәшем. – Өйдә таптырырга куркыныч дим, Балтачка барырга чыктык. Тик сырхауханәгә барып җитеп булмады. Машина эчендә сабыйның кендеген кисәргә туры килде. Бер дә онытылмый: чүпрәк юк. Әти кешенең өстендәге күлмәген салдырып алып, баланы төрдек. И-и-и... Аның ул күлмәге чиста булганмы... Шуларны уйлап шаккатып утырам. Әйе, ул чорда адәм баласы черек булмаган шул. Хатын-кызлар кырда эшләп кайтып бәбиләде. Ун көн бала тапканчы, ун көн бала тапкач ял бирәләр дә, шуның белән шул. Колхозга эшкә чыгасың.

Нурания апа үзе дә өч бала – ике ул, бер кыз тапкан ана. Дәүләтнең законы аңа да бер була – бәби табып, ун көн узгач эшкә чыга. Ә балаларын кайнанасы карый.

– Ирем дә, кайнанам да минем эшкә хөрмәт белән карадылар, – ди кендек әбисе. – Бар, бар, кеше көтеп тора, дип кенә әйтәләр иде. Камыр куясың гына, ишек шакыйлар. Бала тапкан хатын көтеп тормый бит. Бөтен эшеңне ташлап чыгып китәсең. Андый вакытта мичкә ягып, камырны пешерү иргә кала иде...

Мунчага кереп, юынмыйча чыгу да Нурания апа өчен гадәти хәл була. Бала таптырудан тыш, мондый авырулар да күп. Фельдшер булгач, барысына да ярдәм итәргә кирәк.

– Әле ярый ирем көнләшмәде, – дип сүзен дәвам итте әңгәмәдәшем. – Гадәттә, мине алырга ат белән ирләр килде. Бәбиләгән хатынның хәле әйбәтләнгәнен көтеп, кайчакта төн кунып та кайттым. Гыйззәтулла, төне буе кайда йөрдең, дип ник бер әйтеп карасын. Барысы да исән-саулармы, дип кенә сорар иде.

– Районда әнине белмәгән кеше юк, – дип сүзгә кушылды Фәридә апа. – Ул дөньяга килергә булышкан балаларның күбесе исән бүген. «Кендек әбием» дип киләләр, хәлен сорап торалар. Хәзер әни халык арасында бик йөрми. Аның турында: «Баланы ипле таптыра, шифалы куллары белән ярдәм итә», – дип әйтәләр иде. Чынлап та шулай булгандыр, бер фаҗигале очрак та юк бит. Ә ул чорда елына, кимендә, алтмыш бала дөньяга килгән!

1970 нче еллардан соң өйдә бала табарга ярамый башлый. Нурания апа да: «Бүлнискә барыгыз. Башымны төрмәгә тыгасыз бит», – дип, көмәнле хатын-кызларны үгетли. Ә халык әле дистә еллардан соң үзара сөйләшкәндә: «Нурания апа таптырса, болай авыр булмас иде», – ди торган була.

P.S.

Нурания апа рәсми рәвештә исем-фамилиясен алыштырмаган – Анна Кузнецова булып калган. Моның сәбәбен сораган идем: «Ирем фамилиянне алыштырдымәде. Балалар исә әтиләре фамилиясен алдылар», – диде.

Татар авылына килгән рус кызының язмышы менә шундый. Әйе, яхшылык, осталык, милләткә карамый. Хәер, бик тиздән Салавыч халкы аның бүтән милләттән булуын оныткан да инде. Ул алар өчен сабыйларына якты дөньяга туарга ярдәм иткән кадерле кендек әбисе. Һәм шулай булып калачак та.

Изге һөнәре өчен Нурания апага Аллаһы Тәгалә дөньялыкта ук әҗерен бирә кебек тоелды – балалары янәшәсендә матур картлык кичерә. Моны ул үзе дә аңлый, шуңа шөкерана итә.

БУА
http://buinsk.tatarstan.ru/
Журнал
ТАТАРСТАН
ВЕСТНИК
БОЛЬШЕВИК
ТАТАРИИ
ПРИЧАЛ
TATARSTAN

РЕДАКЦИЯ КУХНЯСЫ

БУА БАШЛЫГЫННАН ЯШЕЛЧӘЛӘР БЕЛӘН ПЕШКӘН САРЫК ИТЕ

Ит ит инде – тагын ни кирәк! Чын ирләр ашы! Буага без шундый ризык ашарга бардык – анда тәмле пешерәләр. Күрәсең, шуңадыр да шәһәрдә адым саен кафе-ресторан эшли, аларның һәркайсының менюсында башка берни белән дә чагыштырып булмый торган үз ризыгы бар. Ә менә район башлыгы Рәнис Кәмәртдиновның яраткан ризыгы – яшелчәләр белән пешерелгән сарык ите.

БЕЗГӘ КИРӘК БУЛАЧАК:

- сарык боты – 1 данә;
- тоз, мөшкәт чикләвеге, борыч, рәйхан, бәбрия (розмарин), прованс үләннәре – тәменчә;
- сарымсак – ике баш;
- яшелчәләр: кабак, татлы борыч, помидорлар, суган – ашарга утыручылар санынча;
- аджика – ярты банка;
- кулинария җиңсәсе.

«АКСАКАЛ» ӨЧЕН ЧЫГАРМА

– Гомумән, мин ашарга бик сирәк пешерәм. Пешермим диярлек, – дип ачыктан-ачык белдерә Рәнис Рәфис улы. – «Татарстан» журналы өчен – аның 100 еллыгы уңаеннан гына чыгарма ясыйм. Аксакалларны хөрмәт итәм мин, – дип елмая ул. Һәм «беркайчан да пешермим» дисә дә, житез хәрәкәтләр белән сарык ботын тәмләткечләр белән уа һәм чын осталарча ит арасына сарымсак кыстырып чыга. Тәмләткечле ит, мичкә кергәнче үк, авыздан сулар китерә. Ул мичтә өч сәгать пешкән арада, искиткеч тәмле өчпочмаклар белән чәй эчә-эчә, сөйләшеп утырырга вакытыбыз барлыкка килә. Мондый тәмле өчпочмакларны Буада гына ясыйлардыр!

– Бу гаилә белән бәйрәмнәрдә пешерелә торган ризык. Мондый бот егермеләп кешегә җитә, – ди башлык. – Әмма минем күп балалы гаиләдә дә, ә минем өч балам бар, егерме кеше барыбер җыелмый. Шуңа да мондый ризык пешергәч, кунаклар чакырырга кирәк, югыйсә ашап бетереп булмячак. Татарларда исраф дигән төшенчә бар, ягъни ашап бетерә алган кадәр әзерләргә (алырга) кирәк. Шуңа да исраф булмасын өчен, мондый ботны ашарга кунаклар кирәк, югыйсә үзеңә ашап бетерергә туры киләчәк. Ә бу мөмкин түгел.

Ә болай мин ит белән бәрәңгеле бөтен ризыкны да яратам. Ә алар, нигездә, татар ризыкларында була. Тагын грузин ризыкларын яратам. Диңгез ризыкларын да яратып ашыйм.

Александр Ефремов фотолары

БУАДА БӨТЕН НӘРСӘ ТӘМЛЕ

Сүз аш-су ягына таба борылгач, Буа, Татарстанның башка шәһәрләреннән аермалы буларак, үзенә генә хас нинди тәмле ризыгы белән мактана ала, дип кызыксынабыз.

– Буада бөтен нәрсә дә тәмле! – дип җавап бирә башлык. Татарстан башлыкларыннан башка җавап көтмибез дә инде без. – Бездә борай, тутырма, кияү пилмәне, керкә (форель) балыгы белән мантый бик тәмле була...

– Ягъни сездә кулинария туризмы да җәелдерергә була?

– Рәхәтләнеп! Кулинария генә түгел. Бу бит Идел аръягы зонасы. Бөтен чаралар бездә үткәрелә. Курсәтергә дә, карарга да кызыклы нәрсәләр күп бездә. Табигать манзараларыннан башлап, мәдәни байлыкларга, хәтта сәнәгать өлкәсендәге истәлекле урыннарга кадәр.

СӘНӘГАТЬ ӨЛКӘСЕНДӘГЕ ИСТӘЛЕКЛЕ УРЫННАР

– Табигать һәм мәдәни байлыклар аңлашыла: мөгаен, музей һәм сезнең менә дигән драма театрыгыздыр, ә менә сәнәгать өлкәсендәгеләре белән җентекләбрәк танышыр идек.

– Мин аграрий күзлегеннән чыгып әйтәм. Безнең район авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнә һәм озак еллар инде республикада авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү буенча алдынгы урыннарда бара. Быел буалылар рекордлы уңыш җыйдылар – тулаем уңыш күләме буенча без беренче урында. Шуңа да без эшкәртү заводлары белән горурланабыз. Беренче чиратта, Буа шикәр заводы белән. Ул безнең шәһәр бюджетын булдыручы предприятие, 1962 елда төзелгән. Сезон вакытында анда 800 гә якын кеше эшли. Аның җитештерүчәнлеге дә арта, инвестицияләр дә керә. Хәзерге вакытта завод тәүлегенә 6 тоннага кадәр шикәр чөгендере эшкәртә. Әле кайчан гына тәүлегенә 3 тонна иде. Туристларга шикәр комының, рафинад шикәрнең ничек эшләнүен күрү кызыклы булыр иде, заводның тарихы да бик кызыклы.

Буа спирт заводы продукциясенең ничек җитештерелүен күрү, минемчә, тагын да кызыклырак. Ә нигә юк, ди әле? Кырымда «Массандра»га экскурсияләр бар, дегустация дә ясыйлар. Краснодар краенда Темрюк коньяк заводында да экскурсияләр үтә. Анда туристлар агымының туктап торганы юк. Ә безнең спирт заводы сыйфат буенча дөньяда икенче урынны били! Ягъни менә дигән туристлык маршруты.

Ә инде милли проектлар ярдәмендә шәһәр матурланып кына калмады, ял итү уңайлы да, заманча да булды.

ТАТАРСТАННЫҢ ОЗЫН ГОМЕРЛЕЛӘРЕ

– Аңа кадәр заманча түгел идемени?

– Ул, әлбәттә, тирән тарихлы шәһәр. Тарих та беркая да китмәде – быел Буа 140 еллыгын билгеләп үтә! Ә Буа районына 90 ел. Ягъни сез генә озын гомерле түгел, безнең дә горурланырлыгыбыз һәм күренекле даталарыбыз бар.

Бер-беребезне юбилейларга чакырырга вәгъдә бирешеп, әңгәмәбезне дәвам итәбез һәм сөйләшү барышында Буа муниципаль районының республикада гамәлдә булган 40 программаның 24ендә катнашуын беләбез.

– Яшәү өчен уңай шартлар тудырылмаган булса, бүген сез күргән Буа булмас иде, – ди Рәнис Рәфис улы. – Быел гына да биредә 10 яңа социаль объект төзелде.

ӨСТЕНЛЕК – УҢАЙЛЫЛЫККА

– ФАПлар, мәктәпләр, спорт комплекслары?

– Барысы да... «Мәдәният» милли проекты буенча Кырык Садак авылында күпфункцияле үзәк төзедек. «Демография» милли проекты буенча Буада – 260 урынлык балалар бакчасы. Шәһәрдә балалар бакчасына ихтыяҗ зур иде, бигрәк тә ясле төркемнәренә. Хәзер бу мәсьәлә хәл ителде. Буа балалар бакчасы – районда иң зуры, заманча салынганы, балалар

өчен махсус җиһазлар белән җиһазландырылганы. Кечкенә кызымның да әлеге матур бакчага йөри башлавын түземсезләнеп көтәм.

Авыл территорияләренә милли проектлар ягыннан аерым кайгыртучанык күрсәтәбез, чөнки халыкның төп өлеше авыл җирлекләрендә яши. Быел авылларда 28 спорт мәйданчыгы төзедек, шуларның 26 сы – баскетбол-волейбол өчен, 2 се – футбол мәйданчыгы, авыл кешеләре шулай теләде. 16 авыл җирлегенә тротуарлар ясадык, коелар казыдык, урамнарга яктылык үткәрдек. Раково авылында – ФАП белән кибет, Тингашта – спорт мәйданчыклары, Яңа Чәчкапта 100 урынлык күпфункцияле үзәк төзелде... 7 мәктәпкә, Мәдәният йортына һәм авыл башкарма комитетына, 11 авыл хуҗалыгы объектына капиталь ремонт ясалды. Мәсәлән, Вольный Стан авылындагы бинаны реконструкцияләү анда мәктәпне, балалар бакчасын, Мәдәният йортын, китапханәне, почтаны, фельдшер-акушерлык пунктын бер урында туплау, димәк, авылда төп социаль объектларны саклау мөмкинлеге бирде.

САННАР ҺӘМ КРЕАТИВ

– Саннар сокландыра, алар артында ниләр бар? «Төзедек-ремонтладык» та һәм барысы да совет чорындагы кебек хрущевкаларга охшап калдымы? Шулай да бу яңартуларда креатив бармы?

– Бакча, лицей, Яшьләр паркы яныннан узганда, креативын үзегез күрерсез... Шуны гына әйтәм: объектларның төзелә торганы буенча да, ремонтлана торганы буенча да җәмәгать фикерен тыңлыйбыз, эшкә креатив яшьләрне җәлеп итәбез – безнең архитектура университеты студентлары бар. Башта алар безгә практикага кайталар, ә мин аларга нинди дә булса объект бирәм, хезмәт хакы түлим. Берәр җитди, олыларча эш, бигрәк тә нәтиҗәсе гасырларга кала торган иҗади эш булса, алар бик тырыша. Һәм аннан соң да бездә эшләргә кала, беркая да китми. Менә, мәсәлән, шундый бер дизайнер кыз – Камилә Гайнатуллина белән без Җиңүнең 75 еллыгына авылларда 14 һәйкәл эшләдек. Барлык һәйкәлләр дә төрле-төрле, матур һәм затлы килеп чыкты. Мәсәлән, Яңа Чәчкаптагы һәйкәл кара граниттан. Камиләнең дизайнер булларак эшләгән эшләре арасында Боерган, Мөкерле, Ырыңгы, Кошки-Теняк авылларында ял, балалар һәм спорт мәйданчыклары да бар. Шулай ук ул лицейда санузелларның бизәлешен, ашханә залының, спорт залының һәм Буа ветеринария техникумының җыелышлар залының дизайн-проектларын эшләде.

ТАШЛАНДЫК АВЫЛЛАР БУЛМАСЫН ӨЧЕН

– Җитәкчелекнең кечкенә авылларга игътибар итүе искиткеч. Россиядә хәзерге вакытта күп кенә авыллар ташландык хәлдә. Сездә дә бармы андыйлар?

– Районда ташландык дип авыз тутырып әйтә торган авыллар юк. Әмма авылларда ташландык йортлар бар иде. Барлыгы 176 ташландык йорт барлыгын ачыкладык. Әлбәттә, алар дәүләт реестрында теркәлмәгән. Кайдадыр күршеләре аша, кайдадыр картлар аша ул йортларның кемнәрнеке булуын белештек. Туганнары юкмы, варислары. Һәм алар табылды. Аңлату эшләре алып бардык, кайчагында оялтырга да туры килде: күрше йортлар яхшы хәлдә, ә сез бабагызның йортын оныткансыз дип, мәсәлән. Анда сезнең әби-балаларыгыз яшәгән. Ике банка буяу сатып алып, капкаларын буяр, койма алыштырыр өчен әллә ни күп кирәкми... Ягъни кайчак ышандырып, кайчак административ комиссия аша кисәтү ясап, кешеләргә йогынты ясарга тырыштык. Һәм акренләп андый ихаталарны тәртипкә китерә алдык. Варислар булмаганда, авыл җирлеге документлар җыя, нотариуска мөрәҗәгать итә һәм андый объектларны муниципаль милек итеп терки. Алга таба аларны сүтеп, территориясен тигезләп, аны йә берәр фермерга хуҗалыгын киңәйтергә, йә булмаса күршеләренә күпеллык үлән чәчәргә бирергә планлаштырабыз. Тиз эшләнә торган эш түгел ул. Без аны элекке башлык – Марат Азатович вакытында ук башлаган идек, быел инде ташландык ихаталар калмады диярлек. Гадәттә, элек ул участокларга бәрәңге утырталар иде – һәр йорт артында 50–70–100 сутый җир була. Хәзер инде андый зур мәйданнарга бәрәңге чәчмиләр, кешеләр китеп бетте, берәүгә дә җир кирәк түгел. Һәм ул җирләрдә хәзер үлән үсә. Үләннән бигрәк, агач баса. Бу, беренчедән, янгын куркынычсызлыгы өчен начар, икенчедән, анда сукбай этләр ияләшә. Гомумән, эшлисе эшләр байтак әле.

“

– Яшәү өчен уңай шартлар тудырылмаган булса, бүген сез күргән Буа булмас иде, – ди Рәнис Рәфис улы. – Быел гына да бирелдә 10 яңа социаль объект төзелде.

ЯКТАШЛАР ЯРДӘМЕ

– Былтыр «Пирамида»да якташлар белән очрашу уздырганда, мин аларга туган авылларына ярдәм итүләрен сорап мөрәҗәгать иттем. Һәркемнең мөмкинлеге төрле: кайберәүләр нинди дер глобаль мәсьәләләрдә бөтен авылга ярдәм итә, ә кайберәүләр туган нигезләрендә өй тирәли үләнен генә чапса да яхшы... Бу ата-бабага хөрмәт билгесе дә, кече ватаннарын кайгырту да. Кайберәүләр чыннан да битараф калмады, кайтып җыештырды.

Безнең якташлык җәмгыяте бик актив. Алар картлар йортына да кайта, бүләкләр тапшыра. Беренче сыйныф укучыларына уку кирәк-яраклары салынган портфельләр бүләк итә. Шәһәрдә агачлар утыртырга уйласак, үсентеләр белән тәэмин итә. Быел шундый фикер килде: 40 нчы еллардан башлап, Буа районының 60тан артык авылы юкка чыккан. Күпләренең урыннары да билгеле түгел инде: үлән үскән, җир белән тигезләнгән. Якташлар ул авылларны табып, урыннарына истәлекле тамгалар куярга дип хәл итте. Картлардан, туган якны өйрәнүчеләрдән сораштык, эзләдек, тикшердек. Шул рәвешле утызга якын авылны таптык. Өчесенә истәлекле тамга урнаштырдык, аларга Бөек Ватан сугышында катнашканнарның исем-фамилияләрен яздык. Быковка, Хороновары, Алексеевка авыллары.

Безнең яңа скай-парк шулай ук ТР төзелеш, архитектура һәм ТКХ министры – якташыбыз Марат Мансурович Айзатуллин ярдәмендә пәйда булды. Буалылар аңа бик рәхмәтле. Парк урманда урнашкан – яшьләргә вакытларын актив, файдалы итеп уздыру өчен иң яхшы урын. Олылар да рәхәтләнеп һава сулап йөри ала. Нарат урманы һавасы, территориясе яктыртылган, «кошлар өчен кунакханә» һәм башка кызыклы әйберләр дә бар.

Районга ТР Дәүләт Советы депутатлары да – Шакир Шахмәтович Яһудин белән Ринат Рәүфович Гайзатуллин ярдәм итә.

БАШ НӘРСӘ УЙЛАП АВЫРТА

– Район башлыгы булып эшләү дәверендә нәрсәне үзегезнең иң зур казанышыгыз дип саныйсыз? Һәм башыгыз нәрсә өчен ныграк авырта?

– Без Марат Азатович белән ике зур объект төзелешен башлаган идек. «Импульс» спорт объекты һәм «Абвгдейка» балалар бакчасы. Быел бу зур эшне тәмамладык. Сәләтле балалар өчен ремонтланган мәктәп тә күңелгә рәхәтлек бирә. Мәктәп иске иде, бөтен коммуникацияләре тузган... Һәр кабинетны дизайнерлар белән эшләп чыктык. Һәр кабинетның дизайнын укытучылар белән сайладык. Анда бер-берсенә охшаган кабинетлар да юк! Матур килеп чыкты, гадәти түгел. Алгы өлешен дә үзенчәлекле итеп эшләдек – уннарча дизайнер эше арасыннан иң яхшысын бөтен мәктәп белән сайладык. Мәктәп төркемендә тавыш бирү юлы белән иң күп тавыш җыйганын эшкә тукталдык.

Вольный Стан авылындагы күпфункцияле үзәк тә әйбәт килеп чыкты: 2010 елда куркыныч хәлдә булу сәбәпле ябылган бакчаны төзекләндердек, ремонт ясадык. Хәзер аның ишегалдында волейбол һәм футбол уйнар өчен ике спорт мәйданчыгы бар. Яшәр, укыр һәм спорт белән шөгыльләнер өчен менә дигән шартлар – Буадагы һәм Казандагы спорт мәйданчыкларыннан берни белән дә аерылмый. Тагын озак еллар әле халыкка хезмәт итәргә язсын! Буалылар Президентыбыз Рөстәм Нургалиевич Миңнехановка безнең төбәкнең төрле яклап үсеше өчен бик рәхмәтле. Аның ярдәменнән, президент һәм федераль программалардан башка без бу кадәр объектларны, юлларны һәм башка инфраструктураны төзи һәм төзекләндереп чыга алмас идек.

Буада тагын сәнәгать паркы төзелеше бара. Резидентлары да бар инде, яңа инвесторлар җәлеп итү эше дә дәвам иттерелә – сәнәгать паркының киләчәге зур булачак.

Ә авыл җирлекләрендәге проблема – юллар һәм су. Халыкның бөтен теләкләрен дә үтәргә тырышабыз – булдыра алганча, әлбәттә. Хәзерге вакытта 90 процентка кадәр проблемалар хәл ителгән. Кайдадыр хәл ителә. Эшләрне этапларга бүләбез һәм ел дәвамында башкарып чыгабыз. Әлбәттә, тизрәк эшлисе килә. Буада 7,8 чакрым сууткәргечкә ремонт ясалды, 600 метр яңа су челтәре төзелде. Хәзерге вакытта йортларны яңа сууткәргечләргә тоташтыру эшләре бара. «Чиста су» программасы буенча Ырыңгы авылында су белән тәэмин итү челтәрләренә капиталь ремонт эшләре тәмамланды, Ивашевка авылында яңасы төзелде, Вольный Стан, Алших, Мулланур Вахитов, Ришино, Карлы авылларында су белән тәэмин итү челтәрләре ремонтланды.

Шулай да юллар баш авырттыра торган мәсьәлә булып кала бирә әле. Торгилар үткәрелеп, ки-

лешүгә кул куелганчы, ярты җәй үтеп тә китә... Аннан соң тиз-тиз генә акчаларны тотып бетерергә кирәк... Буада 30 процентка кадәр юллар канәгатьләндерерлек хәлдә түгел иде. Президентыбызга зур рәхмәт, мөрәҗәгатемне кире какмады, быел Буа өчен генә 134 млн сум акча бүлеп бирелде. 9,5 чакрым юл салдык шәһәрдә. Республика программаларын һәм муниципаль юллар фондларын кертеп исәпләгәндә, Буа районында 21,9 километр юл салынды.

Шул ук вакытта, баш ничек кенә авыртмасын, ул күңелле хәл. Чөнки үзеңнең уңай үзгәрешләрдә катнашуыңны тоясың. Әкрен генә, җай белән генә эшләр дөрес юнәлештә бара. Районда тормыш шартлары яхшыра.

КЕЧКЕНӘ ШӘҺӘРДӘН – ЗУР ШӘҺӘРГӘ. ҺӘМ КИРЕСЕНЧӘ

– Сез шактый вакыт Казанда – зур калада яшәгәнсез. Ә хәзер – кечкенә шәһәрдә. Ничек иялләштегез? Һәм сезгә кайда күбрәк ошый?

– Балачагым Буада узса да, бирегә мин сирәк кайта идем: әти вафат булгач, әнине Казанга алып киттек. Бирегә эшләргә кайтырмын дип уйламаган да идем. Баштарак, әлбәттә, күнегергә, иялләшергә кирәк булды, гәрчә туган шәһәрем булса да. Кешеләр үзгәргән, шәһәр башка. Әмма хәзер инде мин үземне янәдән өемдә кебек хис итәм. Бирелә иркенлек бар, яшәү рәвеше мегаполистагы кебек түгел: тынычрак, талгынрак. Бирелә табибка күренергә яки кибеткә барып кайтыр өчен, ярты көн вакыт кирәк түгел. Балалар өчен, минемчә, Буа – бик кулай шәһәр. Бервакыт безгә Дәүләт Думасы депутаты Илдар Гыйльметдинов килде, сәләтле балалар мәктәбенең чыгарылыш сыйныф укучылары белән очрашты. Мәскәүдә дистә елдан артыграк яшәү дәверендә андагы шау-шудан, ыгы-зыгыдан туюы турында сөйләгән иде. «Инфраструктурасы үсештә, кинотеатрлары да, спорт заллары да, табигате дә булган шәһәрдә яшәүнең нинди могҗиза икәнен сез хәтта күз алдына да китерә алмыйсыз. Сез бирелә яшәвегез белән бәхетле!» – дигән иде ул.

Чыннан да, безнең шәһәр бик уңайлы урынга урнашкан. Бирелә автомобильләр юлы бар – аэропортка ике сәгатьтә барып җитеп була. Балаларга теләсә кайсы үсеш юлын сайлау мөмкинлеге бар. Мәктәптән тыш шөгыльләнү өчен үзәк, төрле түгәрәкләр, секцияләр эшли. Максатым – Буа балаларының тормышын зур шәһәрдәгедән дә уңайлырак итү. Без даими рәвештә ата-аналардан балалар өчен тагын нәрсә кирәк дип сораштырып торабыз. Нәфис гимнастика телиләр икән – эзләргә кирәк. Кыйммәт, әлбәттә. Келәмен генә дә 700 мең сумга санап чыгардылар. Мин кайдандыр акча табарга тиеш. Ярар, табылыр да. Тренер табарга кирәк бит әле – анысы проблема. Хәл итәчәкбез. Ата-аналар балалары өчен брейк-данс та сорый – аның да педагоглары кирәк. Эзлибез. Барысы да балаларның киләчәге өчен эшләнә бит. Парклар, скверлар, хоккей тартмалары... Боз сараебыз да бар, урамдагы шугалакка утлар куйдык, динамиклар элдек, кайнар чәй бар. Җәй көне анда тигез бетон җәеп, роликлар өчен җайлыйсы килә

БАЛАЧАК УРЫННАРЫНА – БАЛАЛАР БЕЛӘН БЕРГӘЛӘП

– Буада балачак урыннарыгыз калдымы?

– Менә шикәр заводы паркы, мәсәлән. Бәләкәй чакта мин анда таганда атынырга, тауларда шуарга йөри идем. Мин бала чакта шуып уйнаган ул тауларны быел гына алдык әле. Зәңгәр төсле, металлдан эшләнгән, исегездәме? Бу территория минем өчен бик кадерле, андагы һәр кирпечне мин дизайнерлар белән үзем сайладым. Парк матур килеп чыкты.

Без барысын да исәпкә алырга тырыштык, әниләрнең теләкләрен дә. Манзаралы күренеше

1 Аджика белән уабыз!

2 Кисеп-кисеп чыгабыз!

3 Сарымсак кыстырабыз!

4 Угычтан уабыз!

5 Борыч сибәбез!

6 Җиңсәгә салабыз!

7 Мичкә озатабыз!

8 Алабыз!

булган кафе эшләдек, ул балалар уйный торган мәйданчыкка карый. Шикәр заводында эшләүчеләр белән, укытучылар белән очраштык – аларның фикерләрен дә проектка керттек. Хәзер анда йөгерү өчен резина түшәлгән юл, скейтларда, роликларда йөрер өчен шомартылган бетон бар. Спортчылар өчен тренажерлар...

Моннан тыш, Буа IV Бөтенроссия кече шәһәрләрдә һәм тарихи җирлекләрдә уңайлы шәһәр мохите булдыру буенча иң яхшы проектлар конкурсында җиңеп чыкты. Ә бу 2021 елда үзәк паркны үзәк мәйдан белән бергә реконструкцияләячәкбез, дигән сүз.

– Төзелешләр бигрәк зур күләмнәрдә алып барыла. Барысын да үзем контрольдә тотам, дисез. Ничек барысына да өлгерәсез?

– Иртә тору һәм соңрак яту – һәр җитәкче өчен универсаль режим. Ял көннәрендә олы балаларымны үзем белән объектларга алып чыгам – аларга, мәсәлән, ишегалларының ничек итеп үзгәрүен күзәтү кызыклы. «Безнең ишегалды» программасы буенча ун ишегалдына ремонт ясалды да инде (план буенча 5 елга – 50 ишегалды, елына 10 ар). Чүп савытлары, эскәмияләр куйдык. Асфальт түшәдек, тротуарлар ясадык. Шушы көннәрдә таганнар китерергә вәгъдә итәләр. Халык бу программага бик рәхмәтле. Көз һәм яз көннәрендә резина итекләрсез үтеп булмый торган ишегаллары бар иде. Кешеләр үзләре белән икешәр аяк киемнәре йөртә иде: ишегалдына кайтып җиткәч, ботинкаларын салып, резина итек кияләр. Шушы программа нәтиҗәсендә, Буада хәзер андый ишегаллары юк.

Иске гаражларны сүтәбез. Яңгыр сулары ага торган чокырлар ясыйбыз, ишегалларына кадәр тротуарлар сузабыз, ишекләрне алыштырабыз... Яшелчә бакчаларын һәм агачларны сакларга тырышабыз, ташландык участокларны барлыйбыз, алар белән нәрсә эшләп була, шуны уйлашабыз. Әлбәттә, каршы төшүчеләр дә табыла. Аңлашабыз, уртак тел табабыз. Бигрәк тә иске сарайлар проблемалы: аларга инде ун ел берәүнең дә кергәне булмаска мөмкин, аны чүп баскан, тутыккан, ләкин барыбер булып торсын, диләр.

Буага кергәндә 600 җир участогы булган бакчачылык ширкәте бар. Ул участоклардан, күп дигәндә, 20 кеше файдаланадыр. Мин әбиләргә анда 15 минут саен автобус йөриячәк, дип вәгъдә бирдем. Ягъни маршрутның озынлыгын арттырдык. Бакчачылык ширкәтенең активы белән очрашып сөйләштек. Киләсе елга анда су үткәрмәкче, ут сузмакчы булабыз. Яктырткычларны диодлы лампочкаларга алыштырырга, юл төзергә ниятлибез. Әгәр дә бакчачылык ширкәтен шушындый коммуникацияләр белән тәэмин итә алсак, бакчачылар анда кайтачаклар.

КИЛӘЧӘК ПОРТРЕТЫ

– Буаны тагын ун елдан соң нинди итеп күрәсез? Һәм ул киләчәк портретына туры килсен өчен, нәрсәләр эшләргә уйлыйсыз?

– Матур йортлары, тирә-ягы яшеллек белән әйләндереп алынган, тигез юллары, якты тротуарлары, һәркем теләп йөри торган биналары булган шәһәр итеп. Безнең кафе һәм рестораннар бүгенге көндә, нигездә, мәҗлесләрдә генә эшли. Көн саен эшләсеннәр иде алар. Без Казанда яшәгәндә, ял көннәрендә гаилә белән ресторанга барырга ярата идек. Ул безнең гаилә традициясе иде. Ә монда алай булмый. Балалар Буаның Казан түгеллеген аңламый. «Әти, бүген ял көне бит, ресторанга барыйк әле», – диләр. Андый объектлар һәр көнне эшләсен, анда пешкән ризыклар иң тәмлесе булсын да, Буага чакырып торсын иде – Буага, шул исәптән тәмле ашар өчен генә дә килерлек булсын.

Безнең балалар иң акыллысы булсын иде. Аларга иң яхшы белем алу мөмкинлеге бирелсен. Яшь укытучылар кирәк – көчле физиклар, математиклар, химиклар, инглиз теле, информатика укытучылары. Аларга шартлар тудырырга кирәк. Безнең укучылар иң югары балл җыйган фәннәр бар. Мәсәлән, Регина Хәйбуллина йөз балл җыйды. Андый укучыларны да, укытучыларны да, директорларны да һәрвакыт күрәбез, хөрмәтлибез. Аларның дәрәҗәсе тагын да артсын иде.

Мәктәпләрнең ихтыяҗларын директорлар аша түгел, ә укытучылар аша белергә тырышабыз. Кайдыр реагентлар алабыз, кемгәдер – химия дәресләре өчен лаборатория шкафлары, туплар, кемгәдер тәрәзә алыштырырга кирәк, кемгәдер – идәннәрен... Күптән түгел мәдәният учреждениеләрен карап чыктым, һәр кабинетка кердем – кайдадыр караңгы, кайдадыр җылләтү системасы юк, балалар бии торган бүлмәдә идәннәр тузган. Идәннәрне тәртипкә китерделәр – шомарттылар, буядылар. Объектив картинаны күзаллау өчен, үз күзләрең белән күрү кирәк шул.

Тагын ун елдан соң Буада төрле өлкәләрдә югары квалификацияле белгечләргә – табиблар (алар өчен без арендага торак төзергә планлаштырабыз), инженерлар, укытучылар, төзүчеләргә кытлык бетсен иде... Дубай премьер-министрының сүзләре истә калган, ул болайрак дигән иде: «Минем кешеләрем БҮГЕН яхшырак яшәсен, алар БҮГЕН иң яхшы белемне алсын, алар БҮГЕН сәламәт булсын, ничәдер елдан соң түгел...» Менә мин дә БҮГЕН булсын дип телим. Һәм моның өчен барысын да эшлим. Ә моның өчен яшьләрнең өметләренә һәм омтылышларына таянырга кирәк, алар белән эшләргә. Безнең балалар үзләрен биредә – Буада кирәк итеп хис итсен, үзләренең максатларын һәм хыялларын монда тормышка ашырырлык мөмкинлекләре булсын. ■

ҖИРДӘГЕ ИҢ ШӘП УРЫН

БУА: БУ ШӘҺӘРДӘ БЕЗНЕҢ КИЛӘЧӘК ҮСӘ

Республика шәһәрләре һәм авыллары буйлап сәяхәт иткәндә, «Татарстан» һәрвакыттагыча җирдәге иң шәп урынга тап булды – ул Буа шәһәре һәм аның тирә-ягы. Зур булмаган, уңайлы, заманча шәһәр җыйнак тыкрыклары, матур парклары, чисталыгы белән генә түгел, үзенең кечкенә балаларга карата аерым мөнәсәбәте белән таң калдырды ул. Бу районда балалар өчен тудырылган шартлар зур шәһәрләрдә яшәүче безләрнең төшенә дә кергәне юк. Нәниләр бакчага әкияткә барган кебек йөри, алар анда үзләрен чыннан да әкияттәге кебек хис итәдер. Мәктәпкә дә рәхәтләнеп баралар, ә башкалада укучы студентлар, түземсезләнеп, практикаларын көтәләр – Буага кайтыр өчен, ә инде югары белем алгач, туган шәһәрләренә эшкә кайтырга атлыгып торалар.

– Минем максат – Буа балаларының тормыш шартларын зур шәһәрдәгегә караганда яхшырак итү, – ди район башлыгы Рәнис Кәмәртдинов.

Һәм итә дә. Аңа республика һәм федераль программалар ярдәмгә килә. Район җитәкчелегенә таянып, буалыларның туган якларына мәхәббәтен кушып, әлеге программалар Буаны яшисе, эшлисе, балалар, оныклар үстерәсе килә торган шәһәр – җирдәге иң шәп урынга әйләндерә.

БУА:
КҮЗ САЛ, СИН ЯШӘГӘН ДӨНЬЯ НИНДИ ГҮЗӘЛ!

Фото: Александр Ефремов

АКВАРЕЛЬКИ

БУСИНКИ

Щенок
Песи

Н-А=НА
Н-О=НО

Рахим итегез! Добро пожаловать!

Добро
Рэхим Итегез!

Молодежный
парк






БУИНСК





www.protatarstan.ru
Поиск...
РУС / ТАТ
Подписка!
ТАТАРСТАН
Иҗтимагый-сәяси басма
Где купить журнал "ТАТАРСТАН"
Әһәмиятле
Игелекле
Мәңгелек
Музейлар артык булмый
Татарстан музейлары
Сайттагы яңалык
Яңалыклар
17 ноября 2020
16 ноября 2020
13 ноября 2020
12 ноября 2020
Мостай Кәрим — таш өстендә гөлләр үстергән шагыйрь
Үзенчәлекләр өчен балалар бакчасы
Казандагы Габдулла Тукай әдәби музее
Тукай: тормышы һәм язмышы. Кадерле ядкәрләр кайда саклана
Реклама 16+

Мәңгелек кыйммәтләр

Мәңгелек кыйммәтләр

Акыллы гамәлләр

Игелекле эшләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Татарның яңарыш идеологы **кем** булган

Казанда иң үзенчәлекле музей **кайда** урнашкан

Акбүре авылы **нинди** тарихка ия

ЯҢАРЫШ ИДЕОЛОГЫ: ИСМӘГЫЙЛЬ ГАСПРАЛЫ



Автор: Илдус Заһидуллин

Муса Бигиев аны «мөхтәрәм остазым», Фатих Әмирхан «олуг милләтче», Садри Максуди «рухи остазым», Фуад Туктаров «җәмәгать хадиме», Йосыф Акчура «бөек мөгаллим вә мөхәррир» дип санаган, ә XX гасыр башы татар матбугаты олы хөрмәт белән «баба» дип атаган.

Бу сүзләр барысы да кырымтатар халкының бөек улы, мәшһүр нашир, җәмәгать эшлеклесе, төрки халыкларның яңарыш концепциясе идеологы һәм аны тормышка ашыручы Исмәгыйль Гаспралы (1851–1914) турында.

ГЫЙЛЕМ ТУПЛАУ ЮЛЫНДА

Исмәгыйль Гаспралы 1851 елның 8 мартында кырымтатарлары Мостафа (чыгышы руханиларга барып тоташа) һәм Фатыйма (морза нәселеннән) гаиләсендә дөньяга килә.

Подпоручик дәрәҗәсенә ия әтисе дворян сословиесенә язылгач, улына рус уку йортларының ишекләре ачыла. Бакчасарайдагы мәктәптән соң, Исмәгыйль Симферополь гимназиясендә укый башлый (1861–1863). Әтисе, улын офицер итеп күрергә теләп, ике елдан Воронеждагы хәрби мәктәпкә җибәрә, аннан 1864 елның февралендә Мәскәүдәге икенче хәрби гимназиягә күчерә. Яшүсмер ике ел публицист-славянофил, «Московские ведомости» газетасы редакторы М.Н. Катков гаиләсендә яши. Йорт хуҗасының рус халкына мәхәббәт һәм милли рух белән сугарылган мәкаләләрен укый, күренекле рус язучылары Н.И. Чернышевский, Д.М. Писарев, А.И. Герцен, В.Г. Белинский әсәрләре белән таныша, рус телен камил үзләштерә.

Чит мәдәният даирәсендә уку-аралашу татар малаена җиңел булмагандыр. Госманлы дәүләте составындагы Крит утравында баш күтәрү башлангач, хәрби гимназия укучылары арасында төрекләргә каршы дошманлык көчәя. 17 яшьлек Исмәгыйль, кырымтатарларыннан булган укучы иптәше белән, төрекләргә ярдәм итәргә барабыз дип, 1867 елның җәендә Одессага юнәлә. Тик качакларны паспортлары булмау сәбәпле тоткарлыйлар.

Туган ягына кайткач, егет Бакчасарай һәм Дәрикое авылы мәдрәсәләрендә рус теле укыта. Ләкин яшь укытучының карашлары мөгаллимнәрдә дә, укучыларда да ризасызлык тудыра.

1874 елда Гаспралы Австро-Венгрия империясе башкаласы Венага юнәлә, анда христианнар һәм мөселманнар тормышын чагыштыру мөмкинлеге ала. Аннары вакытлыча Парижда «төпләнә». Акчасызлык аны ни белән генә шөгыльләндерми: «Ашат» реклама агентлыгында көнчыгыш телләреннән текстлар тәрҗемә итә, Мәскәү, Санкт-Петербург матбугатына француз теленнән тәрҗемә

Фотолар автордан алынды

итеп мәкаләләр юллый, үзе дә каләм тибрәтә, күпмедер вакыт рус язучысы И.С. Тургеневның шәхси сәркатибе сыйфатында аның русча текстларын французчага тәрҗемә итә, хатларын яза һ.б.

1875 елда Истанбулга барышлый Гаспралы Франция колониясе Алжирда, шулай ук Туниста, Мисырда була. Мөселман шәркый дөньясындагы уку-укыту системалары белән якыннан таныша, ислам илләренең көнбатыш Европа моделе буенча яңарыш кичерүен күзәтә. Көнбатыш Европада ул, дөнья үсеше баскычына күтәрелү өчен, үз ватанының нинди озын һәм катлаулы юл үтәргә тиешлегенә төшенә.

1860–1863 елларда Кырым ярымутравы мөселманнарының өчтән ике өлеше Госманлы дәүләтенә күченә. Әтисенең абыйсы Сөләйман да күченүчеләр арасында була. Исмәгыйль Истанбулда туганы гаиләсендә яши. Биредә мөһаҗирләрнең тормышы җиңел түгеллеккә шаһит була.

Истанбул хәрби мәктәбенә гариза бирә. Әмма Россиядән килгәннәрне дикъкать белән күзәтеп торган рус илчесе граф Н.П. Игнатьев гозере буенча баш вәзир Исмәгыйльне хәрби колледжда укырга рөхсәт бирми. Гаспралы Бакчасарайга кайта.

Ул ватанына, Сорбонна университетында дәресләр алып, француз, гарәп һәм төрек мәдәниятләре белән якыннан танышып, акыл һәм тәҗрибә туплаган тәрҗемәче һәм журналист булып кайта. 1870 нче еллар уртасында төрки халыклар арасында мондый дәрәҗәдә тирән белемле шәхес булмый әле.

УРТА ГАСЫРДАН ЯҢА ЗАМАНГА КҮЧҮ КОНЦЕПЦИЯСЕ

Исмәгыйль Гаспралы мөселман илләрендә яңарыш мөмкин икәнен үз күзләре белән күрә. Ул ислам дөньясы бары тик мәгърифәт ярдәмендә генә күтәрелә ала дип саный. Россия мөселман җәмгыятен Европа юлы белән, милли-дини традицияләрне саклаган хәлдә үзгәртүне дөрес, дип таба.

Көнбатыш Россияне Шәрык буларак кабул итә. Димәк, аның үсеш дәрәҗәсе татарлар өчен үрнәк була алмый, ул бары тик бер этап төсен ала. Шулай карамаганда, алар киләчәктә дөньяда барлык мөселманнарның үсеш-үзгәрешен әйдәп баручыга әйләнә алмаслар, дип яза ул.

Яңа идеолог татарларны һәм башка халыкларны, үз милләтләрен үстерү максатында, булган хокуклардан файдаланырга, балаларына туган телне һәм дин нигезләрен милли мәктәптә өйрәткәч, рус-татар мәктәпләренә бирүдән курыкмаска чакыра. Мөселманнар рус телен Европа дәрәҗәсенә күтәрелүдә файдаланырга тиешләр, дип белдерә. Аныңча Россия мөселманнары өч телне – туган телен, дәүләт телен һәм дөньякүләм аралашу телен – француз телен белергә бурычлы.

Бу заманда Россиянең мөселман халкы үз традицияләренә генә табынып, искелекне – диндарлык, яңалыкны – динсезлек дип, рус йогынтысыннан качып һәм һәртөрле яңалыкны, шул исәптән файдалы һәм прогрессивларын да читкә этәреп көн күрә. Гаспралының бу эшчәнлеген Фатих Кәрими бер адәмнең, дин кардәшләре өчен дошманга әйләнәсен белә торып, мәйданга чыгып, милләткә: сез – караңгылыкта, авыру, сезгә яктылык, дәва кирәк, дип мөрәҗәгать итүенә тиңли.

Гаиләсе белән. Уңнан сулга: Зөһрә Гаспралы, Исмәгыйль Гаспралы, Фатыйма ханым (әнисе), балалары Рифат һәм Шәфыйка. 1890 ел.

Бу вакытта Идел-Урал татарларының 95% авылда иген игә, дәүләт салган авыр салымнарны түли. Дворяннары – азсанлы һәм ярлы, буржуазия вәкилләре нигездә сәүдә белән шөгыльләнә. Гаспралы тәкъдим иткән яңалыкларны тормышка ашыру һәм татарны алдынгы, һичьюгында башкалардан калышмый торган милләткә әверелдерү өчен, матди ресурслар кирәк була. Бу исә, үз чиратында, белемле, һөнәрле һәм бай булу мәсьәләсен көн тәртибенә куя.

Гаспралының «телдә, фикердә һәм эштә берлек» шигаре Россия мөселманнарының 1905 елдан соң оешкан «Иттифак әл-мөслимин» партиясе өчен ныклы нигез була. Риза Фәхретдин язганча, Гаспралы «Тәрҗеман»да ил мөселманнарын «татар» исеме белән атап килеп, 1906 елдан аларны «төрек» дип йөртә башлый. Ягъни шушы вакыттан башлап, төркичелек (пантюркизм) теориясен тормышка ашыру өчен тырышлык куя. Ул Россия мөселманнарында бердәм әдәби тел булдыруны максат итә. Ләкин алга таба яшь татар зыялыла-

Бер төркем татар зыялылары. Түбән Новгород шәһәрендә III мөселман съезды үткәрелгән көннәр. Сулдан уңга (утыралар): икенче – Габдулла Бубый, Тимерша Соловьев, Исмәгыйль Гаспралы, Габдулла Әхмәров. 1906 елның августы.

ры (аерым алганда – Гаяз Исхакый) Исмәгыйль Гаспралының бу чакыруына колак салмый, милли матбугат Казан татарлары теленә йөз тотып оештырыла. Һәр яңа ачылган басма Гаспралының бердәм тел концепциясен җимерә бара. Империя хакимияте 1905 елны татарларга ана телләрендә вакытлы матбугат ачарга мөмкинлек биргәч, «Тәрҗеман» элекке йогынтысын югалта.

ХӨКҮМӘТ БЕЛӘН ХЕЗМӘТТӘШЛЕК

1881 елда басылган «Русское мусульманство. Мысли, заметки и наблюдения мусульманина» исемле хезмәтендә Гаспралы, иң беренче чиратта, дин кардәшләренең рус дәүләтенә сәяси лояльлеген ислам тәгълиматына нигезләп аңлатырга омтыла, аларның дәүләт белән хезмәттәшлеккә әзер булуларын, түрәләрнең мөселманнардан шикләнүләренең нигезсез икәнлеген раслый.

Гаспралы хөкүмәткә рус булмаган халыклар алдындагы җаваплылыгы турында аңлата. Дәүләтнең бөеклеген ул төрле халыкларның тигез хокуклы булуында күрә. Мөселман мәктәпләренә дөньяви фәннәр керткәндә дәүләткә зыян салынмый, бу мөселманнар арасында яңа белемнәр таралуга юл гына ача, бигрәк тә төрле хорафатлар тәэсирендәге мөселман руханиларының һәм урта катлам вәкилләренең аң дәрәҗәсен күтәрергә мөмкинлек кенә бирә, дип саный мәгърифәтче. Хакимиятне басма эшен җиңеләйтергә, көндәлек тормышта кирәкле белемнәрне тарату өчен, төрле телләрендәге басмаларга ярдәм итәргә чакыра.

Бу елларда либераль реформалар йогынтысындагы империя структуралары мөселман руханиларының «фанатиклыгын» киметү, илдә барган үзгәрешләргә игътибар итмичә, элеккечә йомылып яшәп яткан төрки халыкларны рус мәдәниятенә якынайту сәясәтен тормышка ашыра. Шуңа күрә Исмәгыйль Гаспралы әйткән фикерләр ул елларда империя хакимияте белән бер юнәлештә бару кебек кабул ителә.

МИЛЛИ ДӨНЬЯВИ МӘКТӘП ТӨЗҮ ЮЛЫНДА

Төрки халыклар арасында башлангыч мәктәп реформасын башлап җибәрүдә Гаспралының 1884 елда дөнья күргән «Хуҗаи сыйбъян» әлифбасы зур роль уйный. Яңа методика башлангыч мәктәпкә искиткеч күп яңалык алып килә. Беренчедән, моңарчы шәкертләргә ана теле укытылмый. Ә аваз аша, сүзнең һәм җөмләнең мәгънәсен аңлап, бер үк вакытта укырга да, язарга да өйрәнү мәктәптә туган телгә һәм матур әдәбиятка игътибарны арттыра. Гаспралы үзе дә, уку-укыту методик эшчәнлеген дәвам итеп, 1885 елда рәсемнәр белән бизәлгән «Балаларга һәдия» исемле уку китабы бастыра. Икенчедән, бик тиз укырга өйрәнү башлангыч мәктәптәге дини предметларны яхшы итеп үзләштерергә мөмкинлек бирә. Ягъни дин нигезен, догаларны өйрәнүдә алгарыш күзәтелә. Өченчедән, шәкертләр 3–4 еллык программаны 1–2 айда үзләштерә башлагач, «артып калган» вакытта өстәмә фәннәр укыту яки моңарчы укытылган предметларның эчтәлеген тирәнәйтү һәм киңәйтү мәсьәләсе туа.

Гаспралыга, милли дөньяви уку йорты дип, яңа мәктәп ачасы булмый. Яңарыш иске мәктәпмәдрәсә кысаларында бара, шуңа да яңалык өчен көрәш кискен төс ала.

Аваз ысулы белән укыту беренче нәүбәттә шәһәр татар җәмгыятьләре тарафыннан кызыксынып кабул ителә. Ләкин эш кадрлар булмауга барып тоташа. Татар байлары теләге булганнарны Гаспралы тарафыннан Бакчасарайда «Зынҗырлы» мәдрәсәсе каршында оештырылган курсларга җибәрә башлый. Гаспралы курсларга килгән мулла һәм мөгаллимнәрдән хак сорамаган, ләкин һәрберсеннән мәктәбенә кайткач ике укытучы әзерләү турында вәгъдә сүзе алган.

Ел саен диярлек Түбән Новгородтагы Мәкәрҗә ярминкәсенә килеп, татарлар арасында яңа фикер тарата. 1887 елда Ханкирмәнгә (Касыйм) махсус укытучы җибәреп, ысулы саутия буенча үрнәк мәктәп ачтыра. Нәтиҗәдә Түбән Новгород, Тамбов, Пенза татарлары арасында яңача укыта башлауга күчәләр. 1893 елда Сәмәркандка барып, татар миллионеры Габделгани Хөсәенев өендә яңача укыту мәктәбен эшләтеп җибәрә. Мондый фактлар фикер иясенең иҗтимагый активлыгы турында сөйли.

1899–1901 елларда Сәет бистәсендә бертуган сәүдәгәр Хөсәеновлар яңача укыту буенча мөгаллимнәр әзерләү курсларын оештыра. Хөкүмәт тыйганга кадәр аларны 300дән артык педагог тәмамларга өлгерә.

Сәүдәгәрләрнең тырышлыгы һәм матди ярдәме белән күп кенә авылларда да яңача укыту керә башлый. Бу кадимче муллалар ягыннан каршылыкка очрый. Соңгылары дини белем бирү системасында бернинди үзгәрешләр булырга тиеш түгел дип саный.

Исмәгыйль Гаспринский Йосыф Акчура белән Гарзуфта. 1908 ел.

Мәктәп, уку-укыту мәсьәләләре XX гасыр вакытлы матбугатында көнүзәк темага әверелә. Гаспралы башлангычы җәдитче мөгаллимнәр тырышлыгы белән яңа уку әсбаплары язу һәм милли дөньяви башлангыч мәктәп системасын төзү рәвешендә дәвам итә. Реформа муллалар әзерли торган мәдрәсәләргә таралып, уку программаларына, бер яктан, яңа дини уку предметлары, икенче яктан, дөньяви фәннәр кертелү аша тормышка ашырыла. Татарларда төрки халыклар арасында беренче булып дөньяви урта мәктәп формалаша. Габдулла һәм Гобәйдулла Бубилар төзегән мәдрәсә, Оренбургтагы «Хөсәения», Уфадагы «Галия» шушы яңа төр дөньяви уку йортларының иң танылганнары була.

МИЛЛӘТ МӨГАЛЛИМЕ ҺӘМ ЮЛБАШЧЫСЫ

Исмәгыйль Гаспралы 1876 елда Кырымга кайткач, типография дә сатып ала, «Тонгуч» (Беренче бала), «Шәфәкъ», «Камәр» (Ай), «Йолдыз», «Гөнәш» (Кояш) кебек мәгърифәтчелек фикере белән сугарылган җыентыклар бастыра.

1883 елның 10 апрелендә Бакчасарайда «Тәрҗеман» газетасының беренче саны дөнья күрә, ул рус һәм татар телләрендә басыла.

Газета Кырымда, Әстерхан, Самара, Саратов, Оренбург, Уфа, Казан һәм Пермьдә, Дагыстанда, Урта Азиядә һәм Төркестанда тарала. Шулай итеп, газета моңарчы бер-берсе турында хәбәрдар булмаган мөселман халыкларына мәгълүмат юллый. Атнага ике, соңрак бер тапкыр чыгып килүче «Тәрҗеман» төрки халыкларның уртак матбугатына әверелә, ә аның теле җәдитчеләрнең язу теленә әйләнә.

Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Г. Баруди, М. Акъегетзадә, Ф. Халиди, Г. Баязитов, Р. Фахретдин һәм башкаларны яңа китаплары белән котлап, мөхәррир аларга тәбрикләр юллый. Татар байларының иганә бирүләре хакында, җәдит мәктәбе укытучылары, яңа мәктәпләр турында хәбәрләр биреп бара. Мөселман дөньясында яңа хәрәкәт башланганы тоела.

1881 елны Сембер губернасы фабриканты Әсфәндияр Акчуринның кызы – Зөһрә Акчуринага (1862–1903) өйләнгәч, ул Идел буе татарларының көнкүреше һәм гаилә традицияләре белән якыннан таныша. Үзенең проектларын гамәлгә ашыру өчен матди ярдәм таба, татар сәүдә элитасы белән аралаша һәм аларның дөньяга карашына тәэсир итә башлый.

МӨСЕЛМАН ЛИБЕРАЛЛАРЫ ҖИТӘКЧЕСЕ

«Тәрҗеман»ның юбилейлары уңаеннан Бакчасарайда уздырылган мәҗлесләр татар җәмәгать эшлеклеләрен туплауда, зураеп баручы иҗтимагый көчне танытуда мөһим роль уйный. Беренче шундый юбилей уңаеннан оештырылган киңәшләшү мәҗлесе 1893 елда була. Анда Россиянең төрле төбәкләреннән килгән милләт вәкилләре үзара танышалар, аралашалар. Бу очрашу вакытында милли мәдәниятне үстерү юллары һәм хөкүмәтнең руслаштыру сәясәтенә каршы тору турында ачыктан-ачык сөйләшү була.

1903 елда «Тәрҗеман»ның чыга башлавына 20 ел тулу уңаеннан ил күләмендә олы мәҗлес оештырыла. 100 дән артык кунак чакырыла. Бу эшкә, Гаспралы киңәше белән, ике татар студенты – Садри Максуди һәм Йосыф Акчура алына. «Тәрҗеман»ны котлап, төрле төбәкләрдән һәм чит илләрдән 200 ләп котлау телеграммасы, 300 ләп тәбрик килә. Кайбер тарихчылар фикеренчә, әлеге мәҗлестән Россиядә мөселман либерал хәрәкәте оеша башлый.

1905–1906 елларда мөселманнарның беренче, икенче һәм өченче Бөтенроссия съездларын уздыруда Исмәгыйль Гаспралының роле зур була. Яңарыш идеологы үзенең абруе белән төрле төбәкләрдән килгән мөселман җәмәгать эшлеклеләре өчен иҗтимагый лидер һәм аларны берләштерүче шәхес ролен үти. «Иттифак әлмөслимин» партиясенең Үзәк комитетына әгъза итеп сайлана, туган ягында партиянең Кырым бүлекчәсен оештыруга зур көч куя.

Аның вакытсыз үлеме дә, ахыр чиктә, иҗтимагый эшчәнлеге белән бәйле була. 1914 елның февралендә Санкт-Петербургка баргач нык авырый. Кырымның шифалы һавасы да, табибларның дәвалавы да нәтиҗә бирми. 11 сентябрь дә Гаспралы вафат була.

Үлеменә ике көн кала, 9 сентябрьдә, ул болай дип әйтә: «63 ел ярым яшәдем, бу хәятнең 35 елын мөселманнарның уянуы, тәрәккыйсе, тәгалисе (үсүе) вә тәкямеле (камилләшүе) өчен сарыф иттем. Милләтемнең сәламәтлеге вә сәгадәте өчен кулымнан килгән һәр нәрсәне эшләдем!»

Автор: Алсу Троицкая

ТАТАРСТАН ЭЧКЕ ЭШЛӘР МИНИСТРЛЫГЫ МУЗЕЕ

ИҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ

Бу музей үзенчәлекле баттл кебек. Бер яктан – анда полиция турында, икенче яктан – аның дошманнары, хокук бозучылар турында сөйли торган экспонатлар. Тегесе дә, монысы да – даими күргәзмә. Әмма җиңү, әлбәттә, һәрвакыт игелекле көч ягында...

БЕРАЗ ГЫНА ТАРИХ...

Полиция Казанда 1733 елның язында императрица Анна Иоанновна указы нигезендә оештырыла. Ул вакытта урыннарда җирле гарнизон офицерлары арасыннан билгеләнә торган полицмейстерлар вазыйфасы кертелә, канцелярияләр булдырыла. Полицмейстерлар хәрби губернаторларга буйсына. Әмма Казанда полиция оештыру юнәлешендәге беренче җитди адымнар XVIII гасыр ахырында гына ясала, ул чакта император Павел I нең 1797 елның 19 декабрендә имзаланган «Казан шәһәрендә полиция оештыру турында» указы белән квартал надзирательләре оешмасы гамәлгә кертелә.

Ул заманда Казан полициясен полицмейстер җитәкли, аңа 200–250 йорт-хуҗалык өчен җаваплы приставлар буйсына. Аның эш көне иртәнге сәгать 8 дә кул астындагылар – өлкән городовой, околоток надзирательләре, пристав ярдәмчеләрен җыюдан башлана һәм төн уртасында гына тәмамлана. Баштарак Казан идарәсе Покровская (хәзерге Карл Маркс) урамында урнашкан була. Соңрак шәһәр полициясе, полиция һәм янгын частьләре Воскресенская (хәзерге Кремль) урамындагы алпавыт Родионова йортына күчерелә. Бу бина шәһәр тарафыннан шушы максатта кулланыр өчен махсус сатып алына.

XIX гасыр урталарында император Николай I фәрманы белән, «Себер тракты юнәлешендә» булуын күздә тотып, Казан губернасына Оренбург һәм Урал казак гаскәрләреннән атлы отрядлар юллана.

XIX гасыр ахырында полиция хезмәткәрләре акчаны яхшы ала: околоток надзирателенә – 400 сум, кече городовойга 144 сум түләнә. Чагыштыру өчен, өйдәге хезмәтчеләр айга 1 сум алган, ә бер пот дуңгыз ите 4 сум торган.

Автор фотолары

ЭЧМӘСЕН ДӘ...

Элекке инструкцияләрдә: «Полицейский аек һәм әхлаклы тормыш рәвеше алып барырга тиеш», – дип язылып куелган була. Чынына, дәрәҗәсенә бәйсез рәвештә. Барысына да иң катгый таләпләр билгеләнә. Хәтта тышкы кыяфәт мәсьәләсендә дә. Әйтик, кече городовой вазыйфасына эшкә алганда, аның буен да, гәүдә авырлыгын да карыйлар. Әле зирәклек, өлгерлек һәм халык күңеленә хуш килү кебек сыйфатлар да таләп ителә.

БИЛГЕЛӘР БУЕНЧА ТАНЫРГА

Полицейскийлардан зирәклек һәм җитезлек таләп итү бәлки ул чорда Россия паспортларында хуҗасының фотосурәте ябыштырылмавы белән дә бәйледер. Документта фото 1937 елга кадәр булмый әле. ЭЭМ музеенда революциягә кадәрге Россия паспорт кенәгәләрен күрергә мөмкин. Аларда фото юк, ләкин кешенең тулы тасвирламасы бирелгән. Буе, күз, чәч төсе, аерым билгеләре, дине – барысын да язганнар.

Чая извозчиклар, фәхеш йортлары (ул чакта фахишәлек рәсми рәвештә рөхсәт ителә), чәркәханәләр һәм сәрхушләр, башка урынга күчерелә торган җинаятьчеләр.. – боларның һәммәсе дә полиция карамагында була.

ГАСЫР ҖИНАЯТЕ

1904 елның 29 июнь төнендә Казанда булган вакыйга православие вәкилләрен бүгенгәчә тынычлыкта калдырмый. Казан Богородица хатын-кызлар монастыреның төп соборыннан акча һәм ике тәре (икона), шул исәптән Мәрьям ана сурәте ясалган могҗизалы тәре дә урлана.

– Мин ул урлану тарихы турында да, Казанның могҗизалы тәресен күп еллар эзләү турында да сөйләп тормыйм, бу хакта әдәбият һәм фаразлар күп, – ди музей хезмәткәре Людмила Мещерякова. – Теләгегез булса, табып укый аласыз. Моның узган гасыр башында иң зур шау-шу куптарган җинаять икәнен генә әйтеп узам. Казан полициясе инде 3 июльдә үк каракларның эзенә төшә.

Полицейскийлар бик оператив эш йөртә һәм 3 июльдән 4 сенә каршы төндә үк сәүдәгәр Павел Шевлягин йортының беренче катында урнашкан фатирда тентү уздыра. Бу фатирда җинаятьтә шикләнелгән Федор Чайкин яшәгән була. Тик тәрене барыбер таба алмыйлар.

Людмила Алексеевна укып үтә: «Матбугатта хәбәр ителгәнчә, хөкем карарын игълан иткәннән соң, «тамашачылар суд залыннан бик төшенкелек хәлендә чыкты».

Аңлашыла ки, дин тотучылар өчен гаепләләрнең тиешле җәза алуы түгел, ә тәреләрнең, бигрәк тә Мәрьям ана сурәтлесенең, язмышы мөһим була.

ИҢ ЯХШЫ ПРЕМИЯ – КОСТЮМЛЫК ТУКЫМА

Патша полициясе урынына 1917 елның 10 ноябрендә яшь Советлар иле тарафыннан оештырылган милиция... Форма урынына атаклы күн пальтолар



Муравей – кесә карагы
Мухомор, будник – агент, милиционер
Знать музыку – караклар жаргонын аңлау...
(«Блатная музыка» сүзлегеннән)

һәм кызыл бәйләвечләр... Ул чакта хезмәткәрләре оперлар түгел, ә агентлар дип йөртелгән Җинаятьчеләрне эзләү бүлекчәсе барлыкка килү...

Яшь милиционер урам буйлап велосипедта бара, тик аның милиция хезмәткәре булуын берни дә күрсәтеп тормый. Кесәдә Николай Голубятниковка төнге уникедән соң Казанда һәм шәһәр яны урамнарда йөрү хокукы бирә торган рөхсәт кәгазе генә бар. Велосипедның җинаятьчеләрне эзләү бүлекчәсенеке икәнлеген һәм беркайчан да конфискацияләнергә тиеш түгеллеген белдергән мандат та кесәдә. Монысы ярый әле, ә бит җинаятьчеләрне эзләү хезмәткәрләренең вакыйга урынына кул астында ни бар, шуның белән, хәтта извозчик яллап барып җиткән чаклары да була. Ә заманасы бик болгавыр һәм куркыныч – сәнәкчеләр



фетнәләре, ачлык-ялангачлык. Ач бәндәләр яңа каберләрне ачмасын, урламасын, мәетләрне ашамасын өчен, милиционерларга ул чакта хәтта зиратларны да сакларга туры килә.

«Бандитизмга каршы актив көрәш өчен» үзенчәлекле бүләкләр дә карала. Шәхси корал белән бүләкли алганнар, премия рәвешендә постау чалбар, күн тужурка яки костюмлык тукыма да биргәннәр.

Милициягә килгән эшче егетләр һәм кызлар кайвакыт хәтта укый-яза да белми – алар өчен наданлыкны бетерү түгәрәкләре оештырыла. «Милициягә эшкә кергәндәге тантаналы вәгъдә формуласы» дип аталган язуны укып, ант бирү таләп ителә. Вәгъдә ахырында яшь хокук сакчылары: «Формула текстын миңа

Төрмә эшләре бүлеге полиция составына бер кертелә, бер чыгарыла, шуңа да карамастан, ЭЭМ музеенда чын төрмә камерасын да күрергә мөмкин. Монда көндез стенага күтәреп элләктереп куела торган сәке дә, түшәм биеклегендә диярлек уелган форточка да бар. Сүз уңаеннан, элек музей урынында изолятор булган. Бүген тикшерү изоляторы Япеев урамында, Казанның элекке төрмә бинасында урнашкан. Кремль янында әле башка урынга күчерелә торган җинаятьчеләр төрмәсе дә булган. Мәскәү яки Санкт-Петербургтан сөрелгәннәрне Себергә каторгага алып барганда, юл, һичшиксез, Казан аша узган. Биредә алар бераз хәл җыйган да, богауларын шыгырдата-шыгырдата, авыр сәфәрләрен дәвам иткән.

укыдылар. Мин аның белән килешәм», – дип әйтә торган була. Ант текстын алар укый алмаган.

«МӨГАЕН, СТАЛИННЫ АЛДЫЙЛАРДЫР...»

Ул лагерьдан хатынына әнә шулай дип язган. Автотранспорт бүлеге башлыгы, Казанда беренче бензозаправка станциясе ачылуга, Бауман һәм Чернышевский урамнары чатында беренче светофор куюга, СССРда беренчеләрдән булып автомобиль һәм юл хезмәте техникумын булдыруга тырышлык куйган Филипп Рудольф үзе белән булган хәлгә гомеренең ахырына кадәр ышанмый.

1937 елның көзендә аны кулга алалар һәм фашистлар Германиясе шпионы дип игълан итәләр. Тикшерү ике ел бара. СССР Эчке эшләр халык комиссары карамагындагы Махсус киңәшмә карары нигезендә, 1940 елның 17 гыйнварында Рудольфны биш елга төзәтү-хезмәт лагерена озаталар. Җәза срогын утәү өчен, аны Коми АССРгә җибәрәләр. Газаплаулар әзсез үтми, һәм 1940 елның сентябрендә Рудольф вафат була.

«КӨН-ТӨН ХЕЗМӘТТӘ»

Купшы сумка тоткан хатын-кыз дуслары белән эштән соң өенә кайтып бара. Бизәнгеч савытыннан бераз гына зуррак бу сумкада пистолет ятканын, ә ханымның балалар сукбайлыгы белән көрәш

төркеме инспекторы икәнен берәү дә белми. Кичкә кадәр эшләп, бераз ял итеп алгач, Любовь Новосёлова янә эшкә чыгачак һәм өенә бары иртән генә кайтачак...

Сугыштан соң ул истәлекләре белән уртаклаша: «Гадәттән тыш хәлләр килеп чыкмаса, һәр көн шулай булды. Ләкин икешәр тәүлек, кайчак аннан да күбрәк вакыт өйгә кайта алмаган чаклар бар иде. Арасың, таласың, шундый йокы килә. Ә НКВД клубында төнге өченче яртыда кино күрсәтәләр – анда да эләгергә тырышасың. Ә балалар күп. Аена бишәр-алтышар йөз яшүсмер тоткарлана. Меңләгән сукбай бала, ач, ярым-ялангач, бетләп беткән. Ашыйсы килгәнгә урлаша. Бер малай үзенә «җинаять коралы» – бер очы кадаклы таяк ясаган. Энесен ашату өчен, ул базарда сатучыларның бәрәңгесен шул таяк белән үз сумкасына төртеп төшерергә өйрәнгән».

Әлеге атаклы фотографиядә 1945 елның май ае. Җиңү! Бранденбург капкалары янында совет солдаты Михаил Миронов гармун уйный. Сугыштан соң ул ТАССР Эчке эшләр министрлыгына килә һәм монда күп еллар хезмәт куя.

Татарстанның эчке эшләр органнары фронтка 500 гә якын хезмәткәрен озата. Аларның бишесе Советлар Союзы Герое исеменә лаек була. Милиция хезмәткәрләренең тылда ничек эшләвенә музейда аерым лекция багышланган.

«МОСГАЗ» ЭШЕ

Беренче канлы җинаятен Владимир Ионесян 1963 елның декабрендә Мәскәүдәге Балтыйк урамындагы фатирда кыла. Мосгаз хезмәткәре буларак, ул йорттагы берничә фатирга кереп чыга һәм 12 яшьлек малайны үтерә. Баланың җанын кыеп, Ионесян аның свитерын ала, 60 сум акчаны, «Шипр» одеколонын һәм пляж күзлеген эләктерә. Ул беркайчан да үз җинаятьләрен алдан планлаштырмый. Мәскәүлеләрнең күпчелегеннән аермалы буларак, җинаятьче бүрек колакчынын өскә түгел, ә баш артына бәйләп куя торган була – бердәнбер тышкы билге. Бу үзенчәлекне берничә ел элек «Мосгаз» телесериалын төшергән кинематографистлар да куллана. Ә Владимир Ионесян кинодагы җинаятьченең прототибына әйләнә.

Аның җинаять юлы Казанда кулга алыну белән тәмамлана, вокзалда ул өйдәш хатынын каршы алырга тиеш була. Әмма ул хатын урынына Татарстанга грим салынган МУР хезмәткәрен җибәрәләр. ТАССР җәмәгать тәртибен саклау министры Салих Япеев операция белән шәхсән үзе җитәкчелек итә. «Мосгаз» кушаматлы үтерүчене вокзал перронында ук җиңел генә кулга алалар.

ӨМЕТ СҮНМИ

Музейда мондый детектив тарихлар – дистәләгән, йөзләгән. Инкассаторларны талау, «Тяп-ляп» һәм Пустовит бандалары, «Казан феномены», кеше ашаучы Суклетин, 90 нчы елларның канлы бәрелешләре, «Һади Такташ» җинаятьчел берләшмәсе, наркодилерлар, финанс пирамидалары, ялган акча ясаучылар...

Эчке эшләр министрлыгы музеенда сезгә ачылмый торган җинаятьләрнең булмаганлыгы турында сөйләрләр – нинди генә катлаулы, буталчык булмасыннар, алар барысы да бервакыт ачылачак. Күп дин әһелләре дә, бүгенгәчә дога кылып, Казан Мәрьям ана тәресе табылыр дигән өмет белән яши. Югыйсә яхшылыкның иртәме-соңмы явызлыкны җиңәчәгенә ничек ышанырга, ди?

Автор: Татьяна Вафина

СОЧИДАГЫ КРАСНАЯ ПОЛЯНАДА «МИНЕМ РОССИЯМ» ЭТНОПАРКЫНЫҢ «КАЗАН» ПАВИЛЬОНЫ

ИҢ ОНЫТЫЛГАН, ИҢ ТАШЛАНДЫК

Әгәр Сочига кунак булып барсагыз, тау һавасы сулап, канат юлында йөреп карар, табигать һәм кеше ясаган могҗизаларга сокланыр өчен, сезне, һичшиксез, Красная Полянага, Россиянең иң эре тау курорты «Роза-хутор»га җибәрәчәкләр, бәлки әле хөрмәтләп илтеп тә куярлар, ни дисәң дә, 2014 елгы кышкы Олимпиада башкаласы буларак, тарихка кереп калган гаҗәеп матур урын бит! Күп тырышлык салынган җир һәм шул тырышлык нәтиҗәсендә калкып чыккан корылмалар һәм яңа манзаралар тупланмасы да ул. Бирегә кунаклар бөтен дөньядан килә!

«Минем Россиям» этнопаркы Сочи кунакларын колач җитмәс зур һәм шундый төрле илебезнең мәдәнияте һәм гореф-гадәтләре белән таныштыруны максат итеп куя. Шуңа күрә Россиянең төрле шәһәрләре һәм өлкәләренә музей һәм сувенирлар урыны итеп бирелгән павильоннар (монда аларның иң зурлары, иң күзгә ташланып торганнары унике) кызыксыну уятмый калмый, түргәрәк кереп карыйсы килә. Безне дә кызыктырдылар.

Автор фотосы

КАН ТАРТУ

Кавказ, Суздаль, Үзәк Россия, Краснодар крае, Мәскәү, Россия төньягы, Санкт-Петербург, Урал, Себер, Бурятия... Һәм менә ул – җанга иң якын «Казан» павильоны – этнопарк картасында 9 нчы номер белән билгеләнгән. «Минем Россиям» этнопаркына гадәти кешеләр кебек алгы яктан түгел, ә экспозициянең ахырыннан, чыгу тарафыннан керергә булдык – никтер өчпочмак ашыйсы килеп китте, кан тарта, күрәсең...



МОНГОЛ-ТИБЕТ БУРЯТИЯСЕ

Паркка сәфәрне «Бурятия»дән башладык – ул павильон күзгә иң бәрелеп торганы һәм үзенчәлеклесе булып чыкты. Өч йөз елдан артык элек Петр I боерыгы белән Бурятия рус дәүләте составына керә. Әмма Россия төбәге буларак, еллар, гасырлар узса да, павильоннан монгол һәм бераз тибет рухы бөркелеп тора. Ул дацан – Будда монастырь-университеты рәвешендә төзелгән. Бүген дацан – ул төбәкнең гомумтанылган символларыннан берсе санала. «Бурятия»дә бик матур. Кунакларны музей-сувенир экспонатлары, фотосессияләр өчен кызыклы урыннар җәлеп итә, сез фотога төшкәндә, кемдер берәү башка кидереп куя торган милли бүрекләрне үлчәп карый. «Сагаан дали» дип аталган яшьлек, матурлык һәм сәламәтлек бирә торган тылсымлы чәй дә кызыктыра, мондагы милли кухня тәкъдим ителгән кечкенә генә ресторанда ул чәй белән бик тәмләп сыйлыйлар...

СЕБЕР ТӨРМӘСЕ ҺӘМ УРАЛ ПЕКАРНЯСЫ

«Себер» павильоны да һич калышмый, төрмә рәвешендә бизәлгән булса да... Янәшәдә генә селфи яратучылар бик үз иткән гильотина бастырып куелган, шунда ук такталардан бик оста итеп ясалган ак аю сыны да бар. Һәм, әлбәттә инде, «Пилмәнле» ашханәдә кунакларны себер пилмәннәре көтә. Ләкин Татарстан патриотлары, тугрылык саклап, пилмәннәргә күз йомып узды. Кызыл кирпечтән, сәнәгый бина итеп, пекарня рәвешендә ясалган «Урал» павильонынннан яңа пешкән ипи исе тарала, ләкин татарстанлылар аяктан егарлык ошбу тәмле хуш исне дә сизмәскә тырышты. Чөнки алда Сөембикә манарасы һәм Казан Кремленең бер өлеше шәйләнә – анда безне туган ягыбызның бер кыйпылчыгы һәм, өметебез чынга ашса, тансыклаган өчпочмаклар көтә...



Татарстанда туып-ускән Гүзәл Дасаева һәм Румия Хәсәнова «Казан» павильонының милли йөзе турында хыялланалар.

ЕЛЫЙ КҮҢЕЛ, ӘРНИ ЙӨРӘК

– Бөтен булганы шул, – дип кулларын җәеп җибәрә һөнәр палатасы остасы, бер уңайдан безнең экскурсоводыбыз да булган Гүзәл Дасаева. – Күңел елый, йөрәк әрни. Җан сызлый, – ди ул. – Барлык төбәкләр дә үз мәдәниятләрен, гореф-гадәтләрен, үз павильонын иң яхшы итеп күрсәтергә тырыша, ә туган ягым Татарстан (мин тумышым белән шуннан, монда 2016 елда гына күчтем), әйтерсең лә, бу урынның барлыгын да белми. Ә бит ул – төрле шәһәрләрдән һәм илләрдән килгән кунаклар каршында үзенә күрә визит карточкасы. Аларның бит Россия халыклары, шул исәптән Татарстан турында беләсе килә. Татарстаныбыз футбол белән генә танылмаган бит! Бигрәк тә «Бурятия» белән чагыштырганда без бик хәерче күренәбез – аларда нинди мавыктыргыч һәм экспонатларга ничек бай икәнен карагыз әле!

Гүзәлнең җаны «үз ватаны өчен оялу» хисеннән телгәләнә.

– Хәзер «Казан» урынын «Мирас» күргәзмә үзәге җитәкчесе Ирина Гуилли арендага алды, аның монда тагын берничә павильоны бар – әйтик, шәраб ясау тарихы турында... – Гүзәл Иринаның бетмәс-төкәнмәс энергиясе бәрабәренә нәрсә дә булса үзгәрер, боз кузгалыр, дип өметләнә. Татарстан ягына таба гына була күрсен.

ТУГАН ЯК КЫЙПЫЛЧЫГЫ

Тик, ни кызганыч! Өчпочмаклар көтмәгән икән. Бурятларның мул музей-сувенир байлыкларыннан соң, «Казан» павильоны безне ниндидер онытылганлык, ташландыклык хәлендә каршы алды. «Казан Кремле кыйпылчыгы»ннан нәкъ менә шундый тәэсир алдык. Казан, Татарстан белән бәйле бернәрсә дә юк... Һичкем кермәгән буш залларда күзләр уфалы татар рәссамы Шамил Зөбәйдуллин ясаган футболчылар портретларында гына бераз туктарлана ала иде. 1942 елда Киевта фашистлар белән җирле «Динамо» арасындагы атаклы «үлем матчы» турында интернеттан алып бастырып чыгарылган тарихи сәхифәләр Шамил Зөбәйдуллин картиналарын бераз «сыеклатып» җибәрә. 2018 елгы мундиальнең шәп голларын сурәтләгән киндерләр арасында, дивардагы кадакта, мескен Казан сәламе – «Рубин» командасы логотибы төшерелгән шарфка гына урын табылган. Андыйны Казан җанатарлары стадионда болгарга бик ярата. Рәссамның милләте һәм «Рубин» шарфы – «Казан» павильонын Казан белән бәйләгән нәрсәләр шуның белән вәссәлам! Бик өтек, фәкыйрь килеп чыккан шул. Ә бәлки, берәр кайда тагын нәрсәдер бардыр?



БАШТА ШӘРАБ БУЛГАН...

Без шәраб ясау тарихы музеена юнәләбез. Ирина Гуилли экскурсияне шәхсән үзе үткәрә, анда без 2003 елда ябылган Адлер шәраб заводыннан аның төрле шәраб сортлары кәгазе бобиналарын коткару кебек уңышлары турында беләбез. Югыйсә, халык бу сирәк этикеткаларны башка беркайчан да күрмәс иде. Адлер шәрабының «Улыбка» (андыйны хәтерлисезме) кебек мәшһүр сортларының исемнәре онытылып, үзләре дә тарих чоңгылында югалыр иде. Хәзер исә күз явын алырлык чибәркәй – РСФСРның атказанган артисты Евгения Белоусова сурәте төшерелгән «Улыбка» этикеткасын музейга килүчеләргә истәлеккә биреп җибәрәләр – һәм бу гадәтне кунаклар бик ошаткан.

Без башка тарихи фактларны да өйрәнәбез: баксаң, ул заводтагы мичкәләрне сугыш кичкән иске совет танкларыннан ясаганнар икән. Эчке яктан «мичкәләр имән такта белән каплана, лимон кислотасы белән юыла» – Ирина әйтүенчә, «җимерелүгә дучар ителгән» мәшһүр заводның технологиясе әнә шундый булган.

– Татар павильоны инде җиде елга якын эшләп килә. Тик сезнең тараф – Татарстан ягыннан аңа бернинди игътибар да юк, – ди Ирина Гуилли.

1968 елда Адлер шәраб комбинатының вестибюлен бизәгән фрескалар турында да мавыктыргыч тарихны тыңлап үттек.

– Без бу фрескаларның тарихын төшенергә теләп, төрле урыннарга мөрәҗәгатьләр, гаризалар яза һәм бу эштә катнашкан кешеләр белән аралаша башлагач, шул ачыкланды... Бу – Церетелиның курс эше икән ләбаса! Барысы да шуңа ишарәли, – ди Ирина һәм ул карашыбызны музей диварларын бизәгән рәсемнәргә юнәлтә, аларның һәрберсенең мавыктыргыч һәм гыйбрәтле сюжеты бар, ләкин иң мөһиме – аларның барысы да... йөзем сосласына шәраб кушып ясалган.

Шунда ук кызыклы экспонатка күз төшә. Мондый махсус алъяпкыч мәҗлестә аның башлыгын, тост әйтү остасын аерып торырга булышкан.

Без шәраб бөкесе барлыкка килү турында кызыклы хикәят һәм Кудепсттагы бөке урманы – кайчандыр шәһәр бюджетын тотып торган, тик соңыннан юкка чыгарылган предприятиенең аяныч тарихын тыңлыйбыз. Ул урманны 30 нчы елларда атаклы Абрау Дюрсо өчен утырткан булганнар. Тик бервакыт, имеш, Хрущев килгән дә бөке җитештерүне тыярга кушкан. Шулай итеп, бөке имәннәренә хуҗасыз үсәргә генә калган...



ФУТБОЛ ГЫНА ТҮГЕЛ

«Шәраблы» экскурсиядән соң «Казан» павильонына кайтабыз һәм Ирина безне шунда ук чыбыклый башлый.

– Татар павильоны инде җиде елга якын эшләп килә. Тик сезнең тараф – Татарстан ягыннан аңа бернинди игътибар да юк, – дип өскә баса ул. – Минем алга 20 көн эчендә алты павильон, шул ук вакытта миңа бөтенләй ят өлкә – шәраб ясау тарихы музеен ачу бурычы да куелгач, ни бар, шуңа таянып эш итәргә карар кылдым. 2018 елда, мундиаль вакытында, дөньяда бердәнбер футбол тубы музее ачылды, анда тиңсез коллекция тупланган иде. Безнең алда ул вакытта «Казан» павильонын ачу бурычы тора иде, ә ачылыш вакытында искиткеч татар рәссамы – Шамил Зөбәйдуллин озата йөрде – футбол музее әнә шулай туды. Әлбәттә, мондый урында республиканың халык һөнәрчелеге үрнәкләре булса да әйбәт, ләкин ул вакытта кул астымда татар рәссамының күргәзмәсе генә бар иде, без шуны тәкъдим иттек тә. Һәм нәкъ өстенә бастык! Шундый ватандашыгыз белән горурлана аласыз дип саныйм, ә без исә аның картиналарының бездә генә булуы белән горурланабыз. Өстәвенә, үзе бүләк иткән генә түгел, футболчылар сатып алганнары да бар. Мундиаль вакытында Сочида сигез җыелма команда уйнады, һәм бу сигез җыелма команданың барысын да сурәтләрдә чагылдырдык. Без голларны да рәсемгә төшердек: 11 гол – 11 эш. Бәлки, хәзер бу бик актуаль түгелдер, тик ул вакытта без әлеге музей белән яхшы таныйлдык – дөньяның стадионга килгән барлык телеканаллары «Казан» павильонына кагылып чыкмыйча калмады. ФИФА каналының генераль продюсеры да килеп чыкты. Без матчларны төшердек һәм аларның сурәтләрен ясадык. Тегесен дә, монысын да ике миллиард тамашачы карады!

Тик дөнья чемпионаты тәмамланды, ә алга таба нәрсә? Аннары без Бөек Ватан сугышы вакытындагы футбол турында картиналар ясый башладык, күбесендә билгесез вакыйгалар һәм сюжетлар урын алды. Сугыштан соңгы чорда андый картиналарны берәү дә ясамаган: концлагерьлардагы футбол, Ленинград блокадасы вакытында «Тормыш матчы», Киев «Динамо»сы белән нацистларның «үлем матчы» – әлеге сугыш темасы туристларны да җәлеп итте.

Моя Россия
культурно-этнографический комплекс
«Казань»
Казань - город с тысячелетней историей, столица Татарстана - самобытного региона, вошедшего в состав России в середине XVI века. Исторические и географические факторы обусловили расположение Татарстана на стыке двух крупных цивилизаций: восточной и западной, что объясняет многообразие его культурного богатства.
Древнейшая часть Казани - Казанский кремль, история которого начинается с первых деревянных построек X-XII веков. После осады Казани Иваном Грозным в 1552 году крепость лежала в руинах. Для строительства нового белокаменного кремля царь призвал псковских зодчих, однако только в XVII веке происходит окончательная замена деревянных стен на каменные, тогда же возводятся новые башни и храмы. С расширением российского государства Казань утверждается в роли административного и культурного центра Поволжья. Это отразилось и на архитектурном облике кремля.
Общепризнанным архитектурным символом Казани стала Башня Сююмбике.
Сегодня Казанский кремль является Государственным историко-архитектурным и художественным музеем-заповедником и включен в Список Всемирного культурного и природного наследия ЮНЕСКО.
1. Башня Сююмбике, Казань, 1777 г.
2. Преображенская башня кремля, Казань, XVI век

НЕДІЛЯ 9 СЕРПНЯ
СТАДІОН „ЗЕНІТ"
КЕРОСИННА, 24.
НЕДІЛЯ 9 СЕРПНЯ
ФУТБОЛ
РЕВАНШ
СТАРТ
FLAKELF
Трусевич
Клименко
Свиридовський
Сухарев
Балакин
Гундарев
Гончаренко
Чернега
Комаров
Коротких
Путистин
Мельник
Тимофеев
Тютчев
В ПОСИЛЕНОМУ СКЛАДІ
STADION „ZENIT"
FUSSBALL SPIEL
REVANCHE
ПОЧАТОК МАТЧУ О 5" ГОД.
ЦІНА КВИТКА 5 КРБ.

Моя Россия
КАЗАНЬ
Павильон
«КАЗАНЬ»
Pavilion
«KAZAN»

«Минем Россиям» Мәдәни-этнография үзәге картасы.

ТИЗДӘН – КАЗАНГА!

– Әлбәттә, бу күргәзмә билгеле бер вакытка, вакыйгага гына бәйле, – дип дәвам итә Ирина. – Бервакыт безгә Татарстаннан югары дәрәҗәле делегация килде, һәм мин аларга үземнең борчу-кайгыларымны җиткердем: без ерак арага ялгыз йөгерә алмыйбыз. Татарстан ерак, ләкин ул безнең «Казан» павильонында лаеклы күрсәтелсә, дөрес булыр иде. Әлегә сезнең яктан фикерләр вә тәкъдимнәр юк икән, әмма без тәвәккәл һәм алдынгы фикерле бит! Үз алдыбызга бурыч куйдык һәм тиздән үзебез Казанга барып чыгарбыз дип уйлыйм. Аннан һични килмәгәч, тегеннән үзебез берәр нәрсә белән... кайтырбыз әле... Ничектер кулга-кул тотышырга кирәк бит, дуслар!

Әлегә Ирина ахыр нәтиҗәне күз алдына да китереп бетерә алмый.

– Иң мөһиме – Казандагы кебек булсын, – дип саный ул. – Минем анда беркайчан да булганым юк бит. Менә барып кайтырмын һәм, бәлки, безнең җиде ел тик торган бу эшебез үле ноктадан кузгалыр. Үз көчебез нәрсәгә җиткәнне павильонда күрдегез инде. Анда һәрвакыт бер татар рәссамының экспозициясе тора алмый, гәрчә ул әлеге темага беренче һәм бердәнбер күргәзмә булса да. Безгә үсәр урын бар, шуңа күрә, әйдәгез, көчләрне берләштерик. Безгә ярдәм итәргә, Казанны күрсәтергә, башкалагызда сездән үзләштереп, монда күчереп куярлык кызыклы, артефактлы ни-нәрсә барлыгын төшендерергә кирәк. Турысын әйтәм: җай килгәнен көтеп тору мине дә ялкытып җибәрде. Шәхси тырышлык таләп ителгәнен аңлыйм. Башка республикалар белән барысы да көйләнгән, ә монда исә туктады да калды. Ә бит экспозицияләр бар, иманым камил. Бәлки, һөнәрчеләр монда килеп, үз товарларын тәкъдим итәргә теләк белдерер. Чәкчәкле чәй йортын ачып җибәрү бик әйбәт булыр иде... Тагын нинди тәм-томнарыгыз бар?

– Өчпочмак...

– Менә-менә. Күңел нindидер үзенчәлекле мохит, милли колорит, төрле төслелек тели, ә без монда аның барысын да каян алыйк, ди?

ТУГАН ЯК ТӘМЕ

Шулай да өчпочмак белән чәй эчтек без. «Суздаль» павильонында. «Казан» павильоны татар рухлы булсын өчен төп көрәшне алып баручы Гүзәл Дасаева балчыктан төрле эшләнмәләр ясау буенча осталык дәресләрен нәкъ әнә шунда уздыра. Өчпочмакларны да ул пешергән. Тау кадәр өеп... Шулай итеп үз Татарстан «өлеше»н без барыбер татыдык. «Өчпочмак» исенә җыелып өлгергән «суздаль»лыларга, «себер»-леләргә һәм «бурят»ларга туган ягыбыз сыеның тәме бик ошады. Гүзәл Сочи технопаркы хезмәткәрләрен Татарстан белән кулинария ярдәмендә кызыксындырып торган арада, Татарстанга да бу эшкә рәсми рәвештә һәм киң колач белән кушылырга вакыт. Чөнки «Минем Россиям» – Кавказ, Суздаль, Үзәк Россия, Краснодар крае, Мәскәү, Россия төньягы, Санкт-Петербург, Урал, Себер һәм Бурятия генә түгел. Анда әле Казан да бар – 9 нчы номерлы павильон!

P.S.

Номер басмага әзерләнгәндә, Ирина Гуилли көтмәгәндә генә тугызынчы павильонны арендалау белән саубуллаша. Ә «Казан»ның үзенең шулай ук тиздән «мәсьәлә хәл ителәчәк» диган өмете пәйда була – редакциягә «Минем Россиям» этнопаркында Татарстан намусы өчен төп көрәшче Гүзәл Дасаевадан шундый хәбәр килде.

НАИЛ ЯҺҮДИН: «БАР БУЛМЫШЫМ БЕЛӘН ТӨЗҮЧЕ МИН»

Татарстанның төзелеш һәм нефть-газ химиясе тармагы зур уңышларга ирешкән компанияләр һәм югары класслы белгечләр эшләгән куәтле комплексны тәшкил итә. Инженер, җитештерүче, эшкуар, техник фәннәр докторы, Россиянең табигать фәннәре академиясе әгъзасы, ТРның атказанган төзүчесе Наил Яһүдин – шундыйларның берсе. Ул КАМАЗ төзелешендә, Чернобыль һәлакәте һәм Спитакта җир тетрәү нәтиҗәләрен бетерүдә катнашкан, хәзерге вакытта Татарстанның кара алтынын үзләштерү эшендә ярдәм итә.

«Мин беркайчан да бу тормышта кем буласымны сиземләмәдем, әмма ниндидер зур эш өчен туганымны белә идем».

Джон Рокфеллер

Наил Яһүдиннең тормышы вакыйгаларга, мөһим ачышларга һәм кыю адымнарга бик бай. Сүзне Казан химия-технология институтының яшь студенты студентларның төзелеш отрядлары хәрәкәтенә кушылган вакыттан ук башлыйк әле (сүз уңаеннан, ул хәзер дә яшьләргә теләктәшлек белдереп тора, ике тапкыр Бөтенроссия студентлар отрядлары слетында катнашкан). Вуздан соң ул ВЛКСМның Татар өлкә комитетына җибәрелә. Хезмәт юлында киләсе адым 1974 елда КАМАЗның генераль дирекциясенә Казанга вәкил итеп билгеләнү була. Шушы елларда Яһүдин зур төзелеш барган автогигантның мәнфәгатьләрен хакимият структураларында яклый, Дәүләт планы, Дәүләт тәэминаты белән элемтәдә тора, төзелешне оештыру өчен территорияләрдәге вәкиллекләрнең эшчәнлеген координацияли. Алга таба СССР тарихындагы иң олы – бөтен илдән комсомол юлламалары белән меңнәрчә яшь кешеләрне үзенә туплаган КАМАЗ һәм Яр Чаллы шәһәре төзелешенең Бөтенсоюз алдынгы комсомол штабында башлык вазыйфаларын алып бара.

1979 елда перспективалы башлык Тукай район советы халык депутатларының башкарма комитеты рәисе урынбасары итеп сайлана. Тәҗрибәле җитәкче КАМАЗның һәм Автошәһәрнең шәһәр яны зоналары мәсьәләләрен хәл итү белән шөгыльләнә, эшче коллективларны азык-төлек белән тәэмин итү өчен масштаблы инфраструктура булдыра – кошчылык фабрикалары, җылылык комбинатлары, элеваторлар, бистәләр, юллар төзелә. КАМАЗның беренче фидакарь төзүчесе соңыннан унҗиде ел «Төзелешне механикалаштыру идарәсе» Ябык акционерлык җәмгыятен җитәкли. Наил Габделхәй улы торак йортлар, социаль-мәдәни билгеләнешле объектлар, автомобиль юллары төзи, шулай ук Чернобыль АЭСы һәлакәтеннән һәм Әрмәнстанның Спитак шәһәрендәге җир тетрәүдән соңгы эшләрдә катнаша. 2000 елларда «ТатРИТЭКнефть» нефть-газ чыгару идарәсе белән җитәкчелек итә, «НОЙЛ-холдинг» Ябык акционерлык җәмгыятенең генераль директоры итеп сайлана.

Фәнни эшчәнлек – героебыз тормышының аерым бер өлеше, ул – монографияләр авторы һәм фәнни язмалар сериясе, патентлар авторы. Эшләгән елларында ул Казан финанс-икътисад институтында икенче югары белем ала. Әйтергә кирәк, үзенең кандидатлык эшендә Яһүдин юл төзелеше буенча җиһазлар, техника, җайланмалар уйлап чыгарып, яңа ысуллар тәкъдим итә. 2005 елда докторантураны тәмамлый һәм Губкин исемендәге Россия нефть һәм газ институтында докторлык диссертациясе яклый.

– Мин төзүче булып туганмын. Без нефть тармагында инновацион ысуллар кулланабыз, нефть сервисы хезмәтләрен күрсәтәбез. Шулай ук мине Татарстан нефтенә ярдәм итә алырдай фән, яңа ачышлар һәм технологияләр кызыксындыра, – ди Наил Габделхәй улы.

Бүгенге көнгә ул җитәкләгән «НОЙЛ-холдинг» ЯАҖ табигать һәм техник фәннәр өлкәсендә фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык эшләре алып бара һәм алдынгы технологияләрне җитештерүдә куллану белән уңышлы шөгыльләнә. «НОЙЛ-холдинг» ЯАҖ пластларның нефть бирүен күтәрү өлкәсендә кулланыла торган забой яны зоналарын термогазлы кислоталы эшкәртү технологияләренә патент алган. Технология, үзендә термочыганакны газогенерацияләп, яна торган материалны кулланып, тозлы һәм (яки глинкислота белән) термогазлы кислоталы эшкәртүне берләштерә, ул югары нәтиҗә бирә һәм аз чыгымлы булуы белән аерылып тора. «НОЙЛ-холдинг» ЯАҖ башта ук Татарстан Республикасында кече диаметрлы скважиналарны бораулау буенча алдынгы технологияләрне киң куллануда катнаша, бүген әлеге технологияләр ТРның нефть компанияләрендә кулланыла. Турыдан-туры Наил Яһүдин тарафыннан грунтлы бетон җитештерү инновацияле технологиясе уйлап табыла. Грунтлы бетон – ул нефть эшкәртү калдыкларын, бораулау эретмәләрен балчык һәм ком кушып ясалган юл түшәмәсе.

Яһүдиннең актив эшчәнлеге бервакытта да җитештерү белән генә чикләнми, ул даими рәвештә татарстанлыларның тормышын яхшыртуны тәэмин итүгә юнәлтелгән. Аның җитәкчелегендә Нурлат, Аксубай һәм Яңа Чишмә районнарында күп кенә торак пунктларга автомобиль юллары салына. Аның тырышлыклары белән Аксубай районының Яңа Тимошкино авылында чишмә комплексы төзелгән, Казан, Чаллы шәһәрләрендә, районнарда социаль өлкә объектлары төзекләндерелгән, боларның барысы да башкаланың һәм республиканың нефть районнарының инфраструктурасы үсешенә уңай йогынты ясый. Ышанычлы партнер, даны еракларга таралган белгеч, чын төзүче, акыллы җитәкче, зыялы һәм ярдәмчел кеше – Татарстанда һәм Россиядә аны шундый, дип беләләр.

Реклама. Фотолар «НОЙЛ-холдинг» ЯАҖ матбугат хезмәтеннән алынды

Автор:
Руфия Фазылова

ЯҢА АВЫЛНЫҢ ЯКТЫ ЮЛЫ

Могҗизага тиң язмышлар була. Яңа Чишмә районының Акбүре авылына баргач, шундый тарихларны ишетеп, тетрәнү дә, соклану да кичердек...

Фото: Александр Ефремов

ИКЕ АВЫЛ АРАСЫНДАГЫ НИЗАГ

Акбүрегә егерме алты яшь. Юк, авылны түгел, исемен әйтүем. 1994 елга кадәр ул «Татар Волчьясы» булып йөргән. Аннан аны татарчалаштырганнар. Тарихлы, атаклы авыл. Бүген биредә 162 хуҗалык бар, 442 кеше яши. Мәктәбе, балалар бакчасы, мәдәният йорты, ФАПы булган төзек авыл ул.

Авылның оешу тарихы үзенчәлекле. Бу хакта Акбүренең «Буыннар мирасы» музее җитәкчесе Вәсил Вәлиуллин сөйләде:

– Безнең бабайлар 1756 елда башта Рус Волчьясы авылына килеп урнашкан. Исеменнән үк күренгәнчә, анда руслар яшәгән. Беренче татар гаиләсенең Гомәр Кармышев дигән кешенеке икәне билгеле. 1764 елда тагын берничә татар гаиләсе килеп урнаша. Шуны әйтим: татар гаиләләренең барысы да солдатлар була. Архив документларында бу турыда язулар бар. XIX гасыр башында Рус Волчьясында 24 татар гаиләсе яши. Авыл зурая бара – рус, татар гаиләләренең саны арта. Шулай тыныч кына гомер иткәндә, бер рус егете татар кызына өйләнә. Яшьләр чиркәүгә баралар, кәләш христиан динен кабул итә. Бу хәлдән соң татарлар ярсый. Авылның аксакаллары җыелып сөйләшә. «Болай булса, руслар белән кушылып бетәбез», – диләр. Һәм уртак фикергә киләләр: татарлар үзенә бер авыл булып аерылып чыгарга тиеш. Шуны сорап, югарыга хатлар язалар. Нәтиҗәдә, теләкләренә ирешәләр – Волчанка елгасы буйлап, ике чакрым ераклыкка китеп утыралар. Кызганыч, аның төгәл датасын белмибез, XIX гасырның беренче чиреге була бу.

Яңа авылга Татар Волчьясы исеме бирәләр. Әйткәнемчә, шул исемдә авыл 1994 елга кадәр йөри. Кайчандыр авылга нигез салган солдатлар тиз арада авылның данын еракларга тараталар. Якын-тирәдә Татар Волчьясын белмәгән кеше булмый... Авылның «Буыннар мирасы» музеен карап чыкканнан соң, әнә шулар хакында белдек. Ул Яңа Чишмә районы Туган якны өйрәнү музееның филиалы булып дәүләт статусында эшли икән. Дүрт заллы, заманча мондый музейларны авылларда сирәк очратасың.

– Бик зурлап, музейны 2015 елда ачтык, – диде Вәсил Вәлиуллин. – Бу бинада элек райпо кибете урнашкан иде. Хөрмәтле авылдашыбыз – «Татмелиорация» Траст компаниясе» Ачык акционерлык җәмгыятен җитәкләгән Әнвәр Залаковның туган төбәгенә бүләге ул. Дөрес, Әнвәр Мәхмүтовичтан кала, тагын башка күп кенә кешеләрнең көче керде монда. Әмма эшнең башында ул торды.

Музей авылның йөзек кашы, дисәм, арттыру булмастыр. Килгән кунакларны да иң беренче бирегә алып киләләр. Мәктәп балаларының да яраткан урыны икән бу. Һичшиксез, Акбүредә авыл тарихына зур игътибар бирәләр, җирле халык үзенең нәселен, ата-бабаларының кәсебен белә.

КАЙТУ...

Сүз башында язмышлар дигән идем. Акбүренең «Буыннар мирасы» музеенда Бөек Ватан сугышында катнашкан барлык авылдашларының исем-фамилияләре, фотосурәтләре дә бар. Шулар арасында бер солдатның язмышы аеруча йөрәккә үтеп керде.

...1920 нче еллар. Идел буе төбәгендә – коточкыч ачлык. Ибәтуллин Харис белән Хәдичә уллары – ун яшьлек Минвәли белән яшүсмер Вәгыйзьне хәер сорашырга чыгарып җибәрә, чөнки алар ачлыктан шешенә башлый. Ничек кенә авыр булмасын, ата-ана гаҗизлектән:

– Чистайга барыгыз, хәллерәк кешеләр очраса, исән калырсыз, – диләр.

– Бик зурлап, музейны 2015 елда ачтык, – диде Вәсил Вәлиуллин.

Минвәли абыйның бердәнбер кызы Мәгъбүлә апа бүген исән-сау. Гомер иткән карты белән улы, килене тәрбиясендә яши.

Эзтабарлар Ибәтуллин Минвәли Харис улының солдат медальонын тапканнар.

Абыйлы-энеле ике туган туган йортларыннан чыгып китә. Йөри торгач, вокзалга барып чыгалар. Вәгыйзь белән Минвәли шунда кыргызлар белән таныша. Алар хәлле була, малайларны ашаталар. Кыргызлар Минвәлине аеруча ярата. Абыйсына: «Син безгә бу малайны бир, без сиңа акча түлибез», – диләр. Вәгыйзь ризалаша. Моны энесен ачлыктан коткаруның иң дөрес юлы дип саный. Шулай итеп, ун яшьлек Минвәлине Кыргызстанга алып китәләр. Абый кеше кире Акбүрегә әйләнеп кайта. «Энем үлде, шунда җирләп калдырдык», – ди өйдәгеләргә.

Ә Минвәли кыргыз далаларында, ат иярләп, таза егет булып үсеп җитә. Яңа ата-анасы аңа әйбәт мөнәсәбәт күрсәтсә дә, үсмер малай үз эти-әнисен сагына. Тиздән аны килеп алырлар дип көтә. Тик җәйләр уза, көзләр җитә... Минвәли артыннан килүче булмый. Минвәли барыбер кәефсезләнми – үскәч, мин аларны эзләп табам, дип уйлый. Яңа гаиләгә килүгә, ак биткә «Яңа Чишмә. Татар Волчьясы» дип язып куя, чөнки үзенең шуннан икәнен белә. Бу язуны ул гел яңартып, икенче биткә күчереп тора. Унсигез яше тулгач, Минвәли солдатка китәргә тиеш була. Кыргыз әтисе, берничә атын сатып, улының итек олтанына акча сала:

– Кирәге чыгар, балам...

Минвәли военкоматка бара, документларны тутыра. Һәм, һава суларга чыккач, ишек ачык икәнен күрә... Ике дә уйлап тормыйча, вокзалга чыгып йөгерә. Вокзалда булган кешеләргә ничә еллар түш кесәсендә йөрткән кәгазьне күрсәтә. «Яңа Чишмә. Татар Волчьясы, кайда бу җир?!» Бәхетенә, шунда балалы бер хатын Татар Волчьясының кайда икәнлеген белә булып чыга.

– Татарстанда ул, мин дә шуннан. Туган ягыма кайтырга дип чыктым, тик кесәмдә бер тиен акчам юк, – ди.

Минвәли менә шулай, теге хатынга ияреп, могҗиза белән туган авылына кайтып ирешә. Сигез ел элек эти-әнисе белән печән чапкан болыннарны исенә төшерә. Шунда тәгәри-тәгәри ауный... Аннан туган йортын эзләп таба. Көпә-көндез була бу хәл. Әнисе өйдә ялгызы гына бәрәңге әрчеп утыра.

– Инәй, - дип, килеп кереп, әнисен кочып ала Минвәли.

Тик ана кеше улын танымый:

– Бик таза, матур егетсең. Тик минем улым үлде шул, йөрәк ярамны кузгалтма, – ди.

Өйдәге тавышка Минвәлинең апасы килеп керә. Ул энесен танып ала... Киң кыргыз далаларында уйнап үсеп, ничә еллар сагыну әчесен йөрәгендә йөрткән егет бу вакыт сулкылдап елый...

Минвәли төп нигездә озак яшәми – армиягә алалар. Аннан кайткач, егет өйләнә. Аңа колхоз атларын тапшыралар. Авылда аннан да оста ат өйрәтүче булмый. Гүя ул атлар телен белә.

Ләкин матур гына яшәп ятканда Бөек Ватан сугышы башлана – Минвәлине сугышка алалар. Бергә яшәүче әнисен, хатынын, өч яшьлек кызын калдырып, утыз яшьлек ир сугышка китә. Өч айдан соң, үлгән хәбәре килә...

...Тик язмыш язган хикәя шуның белән генә бетми. 2008 елда Акбүре авыл җирлегенә хәбәр килә. Эзтабарлар Ибәтуллин Минвәли Харис улының солдат медальонын тапканнар. Мәрхүм солдат үз кулы белән туган җирен, әнисенең һәм хатынының исемен язып куйган...

Шулай итеп, Минвәлинең сөякләрен туган ягына алып кайтып җирлиләр. Исән чагында кендек каны тамган җиргә йөрәге, күңеле белән тартылса, мәрхүм булгач та, рухы, җаны, күрәсең, тагын туган ягына тарта. Гаҗәп язмыш...

Минвәли абыйның бердәнбер кызы Мәгъбүлә апа бүген исән-сау. Гомер иткән карты белән улы, килене тәрбиясендә яши. Аның да янында булып, аралашып чыктык.

– Әни, әбием (әтинең әнисе) белән үстем мин, – диде ул. – Әтине әби сөйләгәннәрдән генә беләм. Әти бик җор телле кеше булган.

– Улы бер «үлеп терелгәннән соң», яңадан кайтыр, дип көттеме әбиегез? – дим.

– Көтте. Әби дә, әни дә. Сугыштан фәлән кеше кайтты дигән саен, күңел җилкенеп куя иде. Тик барыбер кайтты бит. Әтинең сөякләрен әби, бабай, әни янына җирләдек. Бик зурлап, хәрбиләрне күмгәнчә, залплар биреп җирләдек үзен. Шул чак башта яңгыр яуды, аннан кояш чыкты. Алланың бер хикмәте бу...

КРЕДИТСЫЗ ТОРМЫШ

Һәр авылда диярлек фермерлар бар хәзер. Әйе, тәвәккәлрәк, тырышрак кешеләр үзләренә эш ачарга тырыша. Акбүредә дә ике эре фермер бар. Шуларның берсе – Нуруллиннар. Хатыйп абый белән Рузалия апа бер ул тәрбияләп үстергән. Ильяс механик һөнәрен үзләштерә икән, Казанда укый.

– Өченче курста инде. Кулына диплом алгач, авылга кайта, – диде әти кеше.

Хатыйп абый белән Рузалия апа үзләрен бәхетле кеше дип атады, чөнки кредитлары юк. Башта бу сүзгә бик игътибар бирмәдем. Нуруллиннар бер ел эчендә ферма салып, утызлап бозау, яңа трактор алган. Һәм дәүләттән грант та, банктан кредит та алмаганнар (!). Иң гаҗәбе – ир белән хатынның төп эш урыны юк, дөресрәге үзләренең хуҗалыкларыннан тыш, бүтән җиргә барып хезмәт куймыйлар.

– Барысына да акча каян алдыгыз? – дип кызыксынам, гадәттә зур эшләр башлаганда эшмәкәрләргә акчалар җитеп бетми бит.

– Мин үземне белгәннән бирле маллар янында, – диде Хатыйп Нуруллин. – Совхозда атлар җиктем, хатыным да фермада эшләде. Совхоз таралгач, фермалар да бетте. Ә яшәргә кирәк бит, эш юк дип торып булмый. Шулай итеп дистә елдан

Хатыйп абый белән Рузалия апа үзләрен бәхетле кеше дип атады, чөнки кредитлары юк.

Минхәеров Шәйхетдин абый белән Минҗиһан апа икесе дә Акбүредә туып-үскән, шунда гомер иткән кешеләр.

бирле мал асрыйбыз. Элегрәк савым сыерлары тоттык. Сөттән акча керә, бозавын үстереп тапшырасың. Шулай акрынлап мая тупладык. Берне сатасың, икене аласың. Әле менә заманчарак кыланып карарга уйладык.

Әйе, Хатыйп абый заманадан калышмый: узган көз Оренбург өлкәсеннән Герефорд токымлы ундүрт баш тана алып кайткан. Алар февральдә бозаулый икән. Герефорд – итле токым. Сыерларны саварга кирәк түгел, чөнки сөтне бозаулар имә. Максат – сөт алу түгел, ә тизрәк бозау үстерү.

– Мондый сыерлар бик кызык: бозаулагач та унсигез көннән яңадан буазлана, – диде хуҗа кеше. – Дүрт-биш айлап бозавын имезгәч, ял итеп тора – җиленен үстерә. Аннан янә бозау китерә.

Хуҗа язын Герефорд токымлы үгезләр дә алып кайткан. Шулай итеп хәзер Нуруллиннар ихатасында гел кызыл төстәге үгез, таналар гына.

Хатыйп абый атлар ярата икән. Дүрт аты бар, шуның берсе нәселле чабышкы аты. Аның белән төрле ярышларга да йөри.

– Чабышкы ат, ярый, анысы аңлашыла, әмма гади атларыгыз да өчәү икән. Алар бит ашарга сорый, җигү өчен өч ат нәрсәгә сезгә? – дим.

– Шәкүр карак әйткән ди: «Эх, егетләр, белмисез сез ат урлауның тәмен». Ә мин: «Ат асрауның тәмен», – дияр идем. Атлар бик акыллы җан ияләре. Һәм алар безгә техника урынына да хезмәт итә. Җәй буе болында печән чабабыз. Безнең җирләр юк. Хайваннарга еллык азыкны үзебез әзерлибез. Минем әле ат җигү кирәк-яраклары, арба, чанам да ике комплект. Хатын да, малай да ат йөртә...

Ир белән хатын икесе дә аралашу өчен ачык кешеләр. Никадәр хезмәт, югыйсә, бер зарланып карасыннар. Киресенчә, маллары турында балалары кебек яратып сөйләделәр. Бердәнбер проблема – яңа салынган фермада су юк. Авыл башында урнашканлыктан, су торбалары фермага кадәр килмәгән. Ә кое казыту шактый зур суммага чыга икән. Әлегә гаиләнең андый мөмкинлеге юк.

«ТАЯККА ЭШЛӘМӘДЕК»

Акбүре халкы үзен бәхетле дип саный, чөнки совет чорында мул тормышта яшәгәннәр. Башка авыллардан аермалы буларак, аларда совхоз булган. Чираттагы геройларым әнә шулай дип саный.

Минхәеров Шәйхетдин абый белән Минҗиһан апа икесе дә Акбүредә туып-үскән, шунда гомер иткән кешеләр. Әбигә – җитмеш алты, бабайга сиксән бер яшь.

– Унсигез яшемнән кияүгә чыктым. Бабайны башка кызлар әләктермәсен, дидем. Бик чибәр иде ул, тырыш та, – дип көлеп сүз башлады Минҗиһан апа. – Илле җиде ел бергә яшибез. Аллага шөкер, тормышыбыз матур. Өч бала – ике малай, бер кыз үстердек. Малайлар Яр Чаллы шәһәрендә яши, кызыбыз – Казанда, табиб. Өчесе дә гаиләле, мул тормышта яшиләр.

Минҗиһан апаны авылның яше-карты белә, чөнки тынгысыз кеше ул. Авылда узган төрле чараларга чигүле яулыкларын бәйләп килеп, үзе иҗат иткән шигырьләрен укый икән. Моның өстенә чигә, бәйли, юрганнар, тагын әллә ниләр ясый...

– Ун яшемнән казан янына басып, аш пешерә, унбер яшемнән бәйли, чигә башладым, – диде Минҗиһан апа. – Без тугыз бала үстек. Шәл дә бәйләп саттык, совхозда да эшләдек. Ничек тә яшәргә тырыштык. Аллага шөкер, Шәйхетдин дә тырыш булды. Колхозга кергән авыллар таякка эшләсә, без акчага эшләдек. Шуңа да Акбүредән халык китмәде, ябышып яттылар. Менә совхоз беткәч кенә, авылдан яшьләр китә башлады.

Минҗиһан апа ит бәлеше пешергән иде. Түгәрәк өстәл артында бергәләп сыйландык. Шунда җирле шагыйрә үзенең шигырьләрен укыды. Гомер иткән иренә багышлап та шигырьләр иҗат иткән. Аларны укыганда Шәйхетдин абый күз яшьләрен сөрткәләп утырды... Ярты гасырдан артык бергә яшәгән ир белән хатынның бер-берсенә булган мөнәсәбәтен күреп, шуңа инанасың: һичшиксез, бу яшьтә дә мәхәббәтнең нурын, җылысын саклап була.

... Авыллардан һәрвакыт диярлек күтәренке кәеф белән кайтыла. Җирле халыкның тырышлыгын, мул тормышта яшәүләрен күреп сөенәсең. Шундый тормышны ташлап чыгып киткән яшьләргә гаҗәпләнәсең... Акбүредән кузгалганда да башка шундыйрак уйлар килде.

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН

Вәсил Вәлиуллин, Акбүренең «Буыннар мирасы» музее җитәкчесе:
– Безнең төбәк тарихы искиткеч бай. Кызганыч ки, әле яхшылап өйрәнелмәгән. Шулай да бу өлкәдә шактый эшләр бара. Авыл җирлегендә еш кына сугыш кораллары, көнкүреш кирәк-яраклары табыла. Мин аларны Казанга археологларга җибәрәм. Җир астыннан XIII гасырга караган предмет калдыклары да чыкты. Димәк, шул чорда ук биредә халык яшәгән дип фаразлап була.
Безнең бабайлар 1756 елда башта Рус Волчьясы авылына килеп урнаша. XIX гасырның икенче яртысында Татар Волчьясы булып аерылып чыгалар. Авылның исеменә килгәндә, аның берничә варианты бар. Беренчедән, бу урында куе урманнар үскән. Шулай булгач, бүреләр дә яшәргә бик мөмкин. Икенчедән, Рус Волчьясына нигез салган русларның күбесе «волчий билет»* белән килеп утырган. Бу турыда документлар бар. Өченчедән, XVII гасырда Рус Волчьясы «кайнар нокта» булып саналган. Кораллы солдатларны махсус бер җиргә җыйганнар. Аларга, күпме теләсә, шуның кадәр җир биргәннәр. Тирә-як авылларда яшәүчеләр Рус Волчьясын «бүре өне» буларак кабул иткән.

* «Волчий билет» – тарихи атама. Аны сөрелгән җинаятьчеләргә яки хәрбиләргә бирә торган булалар. Гадәттә бирәр ярамаган эштә тотылган офицерларга. Мондый затлар башка дәүләт хезмәтенә алынмаган, аларга аерым бер шәһәрләрдә (әйтик, Мәскәүдә, Санкт-Петербургта) яшәргә рөхсәт ителмәгән. Нинди дә булса оешма яки клуб әгъзасы булып, бурычка батучыларга да бирелергә мөмкин булган «волчий билет».





БЕРЕНЧЕ ДУЛКЫН ТАРИХТА КАЛДЫ

Пандемиянең иң беренче күңелсез мизгелләре, Аллаһка шөкер, хәзер истәлек булып кына калды. Алар бүтән кабатланмас дип өметләник. Битлекләрне киябез дә, тиешле дистанцияне исәптә тотып, саклык чараларын күреп, «ТАТМЕДИА» АҖ нең коронавирус белән көрәшкә багышланган «Беренче дулкын. Өметләр, куркулар, хисләр» дигән күргәзмәсенә юнәләбез.

29 мартта Россиядә үзизоляция режимы кертелде. Кешеләргә иң якын кибеткә һәм аптекага гына чыгарга рөхсәт ителде, ә пенсионерлар гомерләренә куркыныч янаган очракта гына өйләреннән чыга алдылар.

«Татар-информ» МА фотографлары Covid-19 пандемиясе башланган чакны теркәп калдырганнар – бушап калган урамнарда, кешеләр тулып торган хастаханәләрдә, полицейскийлар һәм волонтёрлар хезмәтендә. Фотографлар Михаил Захаров, Владимир Васильев, Салават Камалетдинов һәм Рамил Галинең иң тәэсирле 28 фотосында – әле генә узып киткән, әмма бүген инде тарихка әверелгән кичәге көн.

«Нибары ярты гына ел үткән, ә махсус рөхсәтләр һәм чикләүләр белән бәйле ул беренче дулкын форматы инде тарихка әверелде, – дип, экспозициягә аңлатма бирде «ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры Шамил Садыйков. – Без бу күргәзмәне күчмә итәргә планлаштырабыз. Аның белән авыр вакытта эшләгән кешеләргә рәхмәт белдерәсебез килде».

12+ Михаил Захаров, Владимир Васильев, Салават Камалетдинов һәм Рамил Гали фотолары

ТАССРНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА
БАГЫШЛАНГАН УНИКАЛЬ ОТКРЫТКАЛАР КОЛЛЕКЦИЯСЕН ҖЫЙ

Казан Ратушасы.
2020 ел.
Александр Эшкинин фотосы.

ТАССРНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

БАГЫШЛАНГАН УНИКАЛЬ ОТКРЫТКАЛАР КОЛЛЕКЦИЯСЕН ҖЫЙ

Үзәк коммунистик клуб.
1925 ел. «Путь Ильича» журналында (бүген – «Татарстан» журналы) Быков гравюрасы.